# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2025 1 (45)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

*Журнал «Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен*
*һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы*
*кысаларында 2014 елдан нәшер ителә.*
*Елына кәгазь һәм электрон форматта 4 сан чыгарыла.*

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр*
*һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча*
*федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы*
*таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе

► **РЕДКОЛЛЕГИЯ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
редколлегия рәисе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МИҢНЕХАНОВ Р.Н., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХАЛИКОВ И.И., филология фәннәре кандидаты (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ МӨХӘРРИР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
НАДЫРШИНА Л.Р., ГЫЙНИЯТУЛЛИНА Л.М. (җаваплы сәркатип)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият),
ДӘҮЛӘТШИНА Л.Х. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
АБДУЛЛИНА Н.Т., ЧУГУНОВ А.С.

Редакция адресы: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһ., К. Маркс ур, 12.
ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Тел.: (843) 590-61-11
E-mail: f_tatarstan@mail.ru
Сайт: https://ft.antat.ru/

**БУ САНДА**

**ТЕЛ БЕЛЕМЕ**

*Мирхәев Р.Ф.* XIX гасыр – XX гасыр башы татар әдәби телендә сүзтезмәләрнең стилистик кулланылыш үзенчәлекләре . . . . . . .7

*Булатова М.Р.* Татар теленең хвалын, карсун, мәләкәс сөйләшләре үзенчәлекләре *(йола фольклоры текстлары мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . .17

**ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ**

*Надыршина Л.Р.* 1930 еллар татар поэмасының тематик һәм сәнгати төрлелеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .26

*Габидуллина Ф.И.* Сугыштан соңгы еллар татар әдәбиятында герой концепциясе чагылышы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .35

**ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 140 ЕЛЛЫКНЫ КАРШЫЛАП**

*Заһидуллина Д.Ф.* Фатих Әмирхан: татар халкы өчен янып яшәү. .43

*Зәйниева Г.Н.* Фатих Әмирхан публицистикасын барлаганда . . . .65

**ХАЛЫК ИҖАТЫ**

*Мөхәммәтҗанова Л.Х., Мөхәммәтҗанова А.Ә.* «Күр углы» дастаны сюжетында вариантлылык, тарихилык, традицияләр яшәүчәнлеге. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .78

**ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ**

*Заһидуллин И.К.* Татарстан мөселманнарының мәдәни мирасы буларак хәзерге заман мәчетләре тарихын язуның кайбер мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .90

*Хәмидуллин Б.Л.* Казан ханлыгы халыклары – Александр Гваньининың «Европа Сарматиясе хроникасы»нда . . . . . . . . .98

**МИЛЛИ МӘГАРИФ**

*Туктамышов Н.К.* Татар телендә математикадан уку материаллары булдырырга йогынты ясаучы факторлар турында . 106

**СӘНГАТЬ**

*Алекберова А.Ю.* Азәрбайҗанда мәдәни туризмны үстерүдә ачык һавадагы музейларның роле . . . . . . . . . . . . . . . . . 113

*Җәләлиева А.К.* Татарстанда нәфис керамика сәнгате үсешенең төп тенденцияләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120

*Брусков Э.В.* Билбауның мәгънәсе һәм кулланылыш үзенчәлекләре. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127

**ФӘННИ ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН**

*Усманов В.М.* Бөгелмә төбәгенең ташъязма ядкәрләре . . . . . . 135

**КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТУУЫНА 200 ЕЛ**

*Сибгатуллина Ә.Т.* «Аңа татарлар һәм татар теле кадерле иде» *(В.А. Гордлевский Каюм Насыйри турында)* . . . . . . . . . . . . 140

*Миңнеханов Ф.Г.* Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле хакында Гали Рәхим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Кадирова Э.Х.* Диалектолог галимә *(Зидә Садыйкованың туувына 90 ел булу уңаеннан)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152

*Әюпова Г.Р.* Совет иленнән килгән илче . . . . . . . . . . . . . 158

**ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР**

*Вахитов Н.Р.* Тифлистән төшкән мәгърифәт нуры... . . . . . . . 164

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Галиева Л.Ш.* Фатих Әмирхан әсәрләре яңа басмада *(алты томлы академик басманың 1 нче томы басылу уңае белән)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Мирхаев Р.Ф.* Особенности стилистического употребления словосочетаний в татарском литературном языке XIX – начала XX века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

*Булатова М.Р.* Особенности хвалынского, карсунского, мелекесского говоров татарского языка *(на примере текстов обрядового фольклора)* . . . . . . . . . . . 17


### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Надыршина Л.Р.* Тематическая и художественная разнообразность татарской поэмы 1930-х годов . . . . . . . . . . . 26

*Габидуллина Ф.И.* Отражение концепции героя в татарской литературе послевоенных лет . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35


### К 140-ЛЕТИЮ ФАТИХА АМИРХАНА

*Загидуллина Д.Ф.* Фатих Амирхан: жизнь во имя татарского народа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43

*Зайнеева Г.Н.* Публицистика Фатиха Амирхана: новые материалы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65


### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Мухаметзянова Л.Х., Мухаметзянова А.А.* Вариативность, историчность и живучесть традиций в сюжете дастана «Кур углы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78


### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Загидуллин И.К.* Некоторые вопросы написания историй современных мечетей в качестве культурного наследия мусульман Татарстана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90

*Хамидуллин Б.Л.* Отражение истории и культуры народов Казанского государства в «Хронике европейской Сарматии» Александра Гваньини . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98


### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Туктамышов Н.К.* О факторах, влияющих на разработку учебных материалов по математике на татарском языке . . . . . 106


### ИСКУССТВО

*Алекберова А.Ю.* Роль музеев под открытым небом в развитии культурного туризма в Азербайджане. . . . . . . . . . . . . . . 113

*Залялеева А.К.* Искусство художественной керамики Татарстана: от истоков до современности . . . . . . . . . . . . . . . . . 120

*Брусков Э.В.* Семантика и назначение пояса . . . . . . . . . . . 127

## ПО СЛЕДАМ НАУЧНЫХ ЭКСПЕДИЦИЙ

*Усманов В.М.* Арабописьменные эпиграфические памятники Бугульминского района . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135

## 200 ЛЕТ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ КАЮМА НАСЫРИ

*Сибгатуллина А.Т.* «Ему дороги были татары и татарский язык» *(В.А. Гордлевский о Каюме Насыри)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140

*Миниханов Ф.Г.* Гали Рахим о биографии Каюма Насыри . . . . 145

## ПЕРСОНАЛИИ

*Кадирова Э.Х.* Диалектолог Зида Садыкова *(к 90-летию со дня рождения)*. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152

*Аюпова Г.Р.* Посол из страны советов . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Вахитов Н.Р.* Свет просветительства из Тифлиса . . . . . . . . . 164

## НОВЫЕ КНИГИ

*Галиева Л.Ш.* Произведения Фатиха Амирхана в новом издании *(в связи с выходом первого тома шеститомного академического издания)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.145

*Р.Ф. Мирхәев*

# XIX ГАСЫР – XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНДӘ СҮЗТЕЗМӘЛӘРНЕҢ СТИЛИСТИК КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена изучению стилистических особенностей употребления словосочетаний в татарском литературном языке второй половины XIX – начала XX века. Они, как и другие языковые единицы, играют важную роль в формировании выразительности и стилистической окраски текста, а также в достижении определенного эмоционального фона. Актуальность работы определяется недостаточной разработкой в татарском языкознании проблемы их исследования в диахроническом аспекте. Несмотря на то, что синтаксическая структура татарского языка указанного периода в той или иной степени рассматривается в грамматиках и учебниках татарского языка, составленных в то время, в татарском языкознании она до настоящего времени не становилась объектом исследований исторической направленности.

**Ключевые слова:** татарский литературный язык, синтаксис, стилистика, словосочетания, стилистические функции синтаксических единиц.

The article is devoted to the study of stylistic features of the use of phrases in the Tatar literary language of the second half of the XIX – early XX century. They like other linguistic units play an important role in shaping the expressiveness and stylistic coloring of the text, as well as in achieving a certain emotional background. The relevance of the work is determined by the insufficient development in Tatar linguistics of the problem of their research in the diachronic aspect. Despite the fact that the syntactic structure of the Tatar language of this period is more or less considered in grammars and textbooks of the Tatar language compiled at that time, it has not yet become the object of historical research in Tatar linguistics.

**Keywords:** Tatar literary language, syntax, stylistics, phrases, stylistic functions of syntactic units.

Мәкаләнең актуальлеге һәм яңалыгы XIX гасыр – XX гасыр башы татар әдәби теле синтаксик төзелешенең системалы һәм җентекле рәвештә өйрәнелмәве белән билгеләнә. Аның турында мәгълүмат билгеле бер дәрәҗәдә бу вакытта төзелгән грамматикаларда һәм дәреслекләрдә чагылыш тапса да [11: 19–27], бүгенге көндә синтаксик берәмлекләр һәм аларның стилистик үзенчәлекләре тарихи яссылыкта, аерым алганда, күрсәтелгән чор кысаларында, әле өйрәнелмәгән.

Хәзерге татар тел белемендә сүзтезмә исеме астында ике яки берничә мөстәкыйль сүзнең төгәлләүле мөнәсәбәткә керүе нәтиҗәсендә ясалган һәм төгәлрәк төшенчәне белдерә торган төзелмәләр карала [11: 57]. Ияртүче кисәкнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, алар җиде зур төркемгә бүленә: фигыль сүзтезмәләр, исем сүзтезмәләр, сыйфат сүзтезмәләр, сан сүзтезмәләр, алмашлык

сүзтезмәләр, рәвеш сүзтезмәләр, хәбәрлек сүзле сүзтезмәләр. Әлеге синтаксик берәмлекләрнең ияртүче кисәкнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, тагын берничә төрен аерып чыгаралар. Мәсәлән, исем сүзтезмә исемле исем сүзтезмә, сыйфатлы исем сүзтезмә, фигыльле исем сүзтезмә дигән төрләргә бүленә һ. б. [11: 60]. Стилистик планда сүзтезмәләр төрле үзенчәлекләргә ия булулары белән характерланалар. Алар билгеле бер дәрәҗәдә XIX гасыр – XX гасыр башы татар поэзиясе һәм мәгърифәтчелек әсәрләре телендә дә чагылыш таба.

**Исем сүзтезмәләрнең стилистик кулланылышы.** Текстларда әлеге төр синтаксик берәмлекләрдән аерым стилистик үзенчәлекләргә ия булулары белән исемле, сыйфатлы һәм фигыльле исем сүзтезмәләр характерлана.

XIX гасыр – XX гасыр башы татар поэзиясе әсәрләрендә исемле сүзтезмәләр, жанр таләпләреннән чыгып, рифма тудыру чарасы буларак кулланылалар:

*Белми үзсүзле мәрыйз имләт дигән* ***сүз кадрене,***
*Аңламас беткән сәфил гыйззәт дигән* ***сүз кадрене.***
*Белми хайваннар да инсият дигән* ***сүз кадрене,***
*Һәм тупаслар белми шигърият дигән* ***сүз кадрене*** [13: 132].

Шуның белән бергә алар биредә катлаулы метафоралар тудыруда катнашалар:

*Диңгез якасында торып, без сусамыйк, –*
***Хөрриятнең диңгезләре*** *ташыйимде* [12: 55];

*Мәзлүмнәргә якты, нурлы көннәр килде, –*
***Азатлыкның кояшы*** *тугды имди* [12: 55].

Мәгърифәтче язучылар әлеге синтаксик берәмлекләр нигезендә барлыкка килгән катлаулы метафораларны, үз чиратында, персонажларны тасвирлаганда файдаланалар: ***Ләтафәтнең күбәләге*** *улган Сәлимә туташдан Самарда ихтыярсыз аерылачак идем* [15: 36]; ***Фиракың уты*** *яндырадыр да, шуңа мәҗбүр уларак аглыйурым!* [16: 41].

Алга таба алар, образлы мәгънә төсмерләренә ия булып, катлаулы стиль чараларын (метонимия, метафора, гипербола һ. б.) барлыкка китерүдә катнашалар. Исемле исем сүзтезмәләр нигезендә барлыкка килгән катлаулы метонимияләргә авторлар аерым персонажлар турында сүз барганда мөрәҗәгать итәләр: *Бу дәфга мәзкүр* ***арыслан күз*** *Хисаметдин илә Әбүзәр мирзайа бакыб, сүзләрене динләр иде* [1: 42].

Мондый метонимияләр текстларда билгеле бер күренешләр, аерым алганда җинаятьләр, кешенең үлем хәлендә ятуы, хәерчелек һәм эчкечелек турында сүз барганда да җәлеп ителәләр: *Менә, абыстай, әйтдем ич, карт гомреңдә* ***Себер эшләре*** *кыласын, диб* [3: 30]; *Әнкәңез агыр мәразъда улыб,* ***әҗәл ясдыкындадыр*** [3: 62]; *Ачлыкдан, ялангачлыкдан,* ***кеше капысындан*** *сезе саклудым* [4: 24]; *Бичара адәм! Кәнденең сәламәтлегене,* ***хатынының күз яшене, балаларының ризыкларыны*** *эчәдер!* [16: 29].

Исемле исем сүзтезмәләр нигезендә барлыкка килгән катлаулы метафораларны мәгърифәтче язучылар, нигездә, иҗтимагый характердагы күренешләр турында сүз алып барганда файдаланалар: *Киләчәк заманда корылачак* ***мәгыйшәт бинасының*** *нигезене та сабый вакытларындан мөхкәм корыб варырлар* [15: 66]; *Ходай даимән гаделдер, у* ***мәхәллә җәһилләренең фетнә йипләрене*** *кисде* [4: 29]; *Мәшһүр Зәрафшад нәһере дә Аму-Дәрья нәһеренә табиг улыб, Сәмәрканд, Бохара тарафларыны* ***дөнья җәннәте*** *кеби идән бер нәһердер* [4: 57].

Алга таба текстларда әлеге стиль чарасы аерым персонажларга һәм затларга бәя биргәндә кулланыла: *...Сәлимә туташның* ***гыйлем диңезе*** *идегенә канәгать итдем* [15: 53]; *Багдад, Картабә, Гарната, Мисыр, Бәсра, Дәмәшк, Хәлеб, Мәдинә, Мәккә шәһәрләрендә йитешкән мәшһүр хатынлар ошбу* ***иҗтиһад агачларының йимешләредер*** [15: 66–67]; *...бу* ***«Дарвин» маймүнләре*** *кайдан килеб, кайда вармакдалар иде?...* [16: 61].

Моннан тыш мондый метафораларга авторлар тикшерелә торган чорда татар тормышында мөһим урын торткан аерым иҗтимагый институтлар турында сүз алып барганда (а) һәм персонажларның психологик халәтен тасвирлаганда (ә) мөрәҗәгать итәләр:

а) *Шагыйрьләремезнең* ***«дөнья оҗмахы»*** *дия тәусыйф итдекләре мәдрәсә почмагында улган урынымдан биздем, вә башымны алыб бер тарафка кидәргә карар вирдем* [15: 7];

ә): *Аллаһы Тәгаләнең бәгзы бер бәндәләре энҗегә гарк улдыгы хәлдә, икенче берләре бер кисәк кара икмәкгә мохтаҗ улыб башыны таш өстенә куйыб җан вирдегене хәтерләб,* ***хыял дәрьясына*** *батыб хәйран улмакда идем* [15: 39–40].

Исемле исем сүзтезмәләр нигезендә барлыкка килгән чагыштыруларны язучылар, нигездә, персонажларның аерым сыйфатларын тасвирлаганда җәлеп итәләр: *Чөнки аның үзенең дә зиһене* ***үрмәкүч оясы кебек*** *чуалыб беткән* [10: 71]; *Май кеби йомшак,* ***сандугач сайравы мисаллы*** *моңлы вә мөлаем давышлары таң йиле рәвешендә җанымны рәхәтләндерә иде* [15: 32]; *Зирә абыстайнын дәрес ысулы,* ***курай давышы кеби*** *гүзәл тавыш илә көйләмәкдән гыйбарәт иде* [16: 47].

Әлеге синтаксик берәмлекләрдән оешкан градацияләр текстларда пейзаж картиналарын тудырганда кулланылалар: *Кояш баткан соң, төрле якдан ишеделенәчәк* ***курай давышларыны,*** *көтүчеләрнең чыбыркы шартлатуларыны, чабыб варган юлчыларның* ***кыңгырау давышларыны, сандугач сайрауларыны*** *дыңлаб ләззәтләнәчәк көнләрем вар идегене фикерләб, балалар мисалында сәвенә идем* [15: 8].

Алга таба исемле исем сүзтезмәләр нигезендә барлыкка килгән антитезалар ярдәмендә мәгърифәтче язучылар тикшерелә торган чорда татар җәмгыяте алдында торган көнүзәк мәсьәләләрне (а) һәм персонажларның аерым ситуацияләрдәге психологик халәтен (ә) ачып бирәләр:

а) *Көнләремез* ***гафләт көнләре*** *дәгелдер. Шу гасыр* ***куршун, хәнҗәр гасыры*** *да дәгелдер. Гасырымыз* ***голүм вә мәгариф гасырыдыр, идарә, сәясәт мәйданыдыр*** [4: 59];

ә) ***Кайгы хәбәрене*** *ишетмәкгә нисбәт әйләдекдә,* ***шадлык хәбәрене*** *ишетмәк агыр һәм гүч улдыгыны белдем* [15: 78].

Сыйфатлы исем сүзтезмәләргә килгәндә, XIX гасыр – XX гасыр башы татар поэзиясе әсәрләрендә алар катлаулы эпитетлар тудыруда катнашалар:

*Җәй көнен яздым бераз; язмыйм әле кыш, көзләрен,*
***Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле*** *кызларын* [12: 183].

Шуның белән бергә әлеге синтаксик берәмлекләр нигезендә биредә катлаулы метонимияләр дә барлыкка килә:

*Һәммәсе кяфергә охшашлы бу* ***тар чалбарларың****;*
*Нә мөселманлыкка анларда шәбаһәт бар иде* [12: 257].

Әлеге синтаксик берәмлекләрне мәгърифәтче язучылар беренче чиратта персонажларның портретларын тудырганда җәлеп итәләр: *Әмма бер көлешендә* ***кып-кызыл дудаклары*** *вә* ***ак энҗе дешләре*** *менланың күзендән качмады* [1: 10]; *Ахунд хәзрәтләренең өстендә* ***яшел чапан****, башында* ***биек ак чалма****, кәндесе* ***зур буйлы нечкә кеше*** *иде. Йитмеш яшьләренә йитешмеш, зур* ***ак сакаллы,*** *мәһабәтле вә шөҗәгатьле кемсәнә иде* [2: 39].

Моннан тыш авторлар аларны геройларның мораль йөзен һәм социаль статусын ачып биргәндә файдаланалар: *Гали бай бу вилаятьдә* ***бөек вә мәшһүр төҗҗар*** *иде* [1: 12]; *Ул Ягъкуб Галиев бик* ***мордар кеше****, ул кызны да бик җәбер кылган иде* [3: 22].

Югарыда күрсәтелгән стилистик вазифалар йөкләнгән сыйфатлы сүзтезмәләр текстларда еш кына образлы төсмерләргә ия булалар һәм геройларның портретларына билгеле бер дәрәҗәдә тасвирлык өстиләр: *Бу* ***нәзек бил вә җәмилә кыз*** *менланың күзенә тәмамән күренде* [1: 9]; *Мөселманлар фәкать таҗир адәмләр улмаенча, мабәенләрендә нечкә вә зәгыйфь,* ***соры вә нурлы йөзле яшь-яшь адәмләр*** *дә мәүҗүд иде* [2: 36]; *Җөмлә җәмг улынмыш мөселманлар, руслар ахунд хәзрәтләренең* ***мөнәүвәр йөзенә*** *бакмышлар иде* [2: 39]; *Ул бик яхшы* ***кеше*** *һәм бик* ***үткен, булган****...* [6: 46]; *Капы ачылдыкда, кулына кечкенә бер лампа тоткан Фатыйма туташ ай кеби* ***нурлы йөзе*** *илә караңгы бүлмәнең эчрүсен яктыртды* [10: 94].

Шуның белән бергә әлеге синтаксик берәмлекләргә авторлар үз чордашларында күрергә теләгән һәм, киресенчә, күрергә теләмәгән сыйфатлар турында язганда мөрәҗәгать итәләр: *Бикбау агай да төрле гәзитәләр вә яңа рисаләләр вә романнар укыб,* ***иске фикердән****, күгәргән, сөрсегән игътикадларыннан пакьләнгән иде* [5: 16]; *Ул үзенең тәхетен* ***надан мөдәррисләргә, ялган ишанларга*** *алтын медальләр, ефәк чапаннар биреб кенә саклады* [7: 4–5]; ***Гүзәл холык*** *әдәб, гыйффәт, сабыр, тәхәммелдән гыйбарәтдер* [15: 5]; *Милләт димәк* ***ба-***

***сыйратлы картлар, тәүфыйклы егетләр****, яки* ***гафиф вә тәдбирле ирләр*** *вә* ***тәрбияле хатуннар*** *илә каим улыр* [16: 67].

Аерым очракларда сыйфатлы сүзтезмәләр нигезендә катлаулы метонимияләр барлыкка килә: *Иртәйә сиңа да, Ибраһим Галиевкә дә – икеңезгә дә* ***«акчасыз фатир»*** *вирерләр* [3: 46]; *Углыңны мулла итә белмәсәң, тик* ***тар балак*** *булыб йөрсен* [5: 18]; *Студент боларны сөйләгән вакытта безнең* ***яшел чапан*** *берлән* ***ак җиләннең*** *авызлары берәр карыш ачылыб, утырган җирләрендә катыб калдылар* [10: 47]; *Шунда яхшы кызыб кына бәлеш ашаганда, сүздән сүз чыгыб, Сәлимҗан хәзрәт белән сабынчы Мусаның зимләзиядә (гимназия) укыган* ***тар балагы*** *мәдрәсәләр хакында бәйләнешеб китеб, мәҗлеснең ямен, бәлешнең тәмен җибәрделәр* [14: 79].

Моннан тыш әлеге синтаксик берәмлекләр персонажларның билгеле бер ситуациядә кичергән психологик халәтләрен ачып бирү чарасы булып торалар. Аларны мәгърифәтче язучылар персонажларның кайгы-хәсрәт кичергән вакытларын, боек чакларын тасвирлаганда аеруча еш кулланалар: *Гыйлаҗ бай да* ***сынык күңел*** *илә: «Рәхмәт, рәхмәт, Аллаһы Тәгалә шәфкатен бирсен», – диб, калай савытны алыб, икенче бүлмәгә китде* [6: 52]; *...****татлы хыялларның*** *барысы да* ***ачы бер кайгы-хәсрәткә*** *әйләнәдер иде* [10: 82]; *Бунларның ләззәтле сохбәтләре илә* ***моңлы вә боек күңелемне*** *юатыр идем* [15: 50]; *Әсманың кара хәбәрләрене вә* ***хәсрәтле сәгатьләре*** *идегене шәкерд белер вә зиядә кызганыр, әгәр дә әлендән килер исә, кәнде җаныны фида идәрәк Әсманың ата вә анасыны кире дөньяга кайтарыр иде* [16: 53].

Аерым очракларда алар пейзаж тасвирламаларында да урын алалар: *Көн бик салкын иде, аз гына кояш яктысы улса да,* ***ачы суык җил*** *карны, очырыб, юлга сала бардыкдан, юл да бик агыр иде* [6: 4].

Сәяхәтнамәләрдә авторлар сыйфатлы исем сүзтезмәләрне сәфәр вакытында булган җирләрдә очрашкан аерым социаль төркемнәр һәм шәхесләр турында язганда кулланалар: *Һич аяк басаҗак йир юк,* ***кара мужик*** *халкы илә тулмыш* [8: 8]; *Һәм дә бу юлда гизәнләрең әксәры улдыкҗа* ***тәмиз вә кибар токымдан*** *улыйур* [8: 31]; *Кәндесе мөстәгыйд вә* ***ачык фикерле вә һәр шәйә мераклы бер гәнҗдер*** [8: 34–35]; *Шәркың* ***тәмиз йөрәкле, халис иманлы, саф калебле, садакатьле, итагать вә мәрхәмәтле, сададил вә мосафирпәрвәр адәмләрене*** *сәвмәйән кеше һич юкдыр* [9: 46].

Фигыльле исем сүзтезмәләргә килгәндә, аларны язучылар беренче чиратта укучының игътибарын персонажларга хас булган аерым сыйфатларга җәлеп итәр өчен мөрәҗәгать итәләр: *Бу ханә үзе кечек булса да, тахтадан башы, анбары вә мөхкәм сарайлары сахибенең иҗтиһадлы,* ***хезмәт сәвән адәм*** *идегене күстәрерләр иде* [1: 2]; *Хәнифә туташ үзе дә* ***укымыш кыз*** *иде* [1: 11]; *Гизлеҗә* ***бала тугыран хатуннар*** *ичүн тугырмайа* ***мәхәл вирән вә балалары тәрбия кылан*** *бөйлә* ***карт хатыннар*** *Казанда юк дәгелдер* [3: 19].

Аерым очракларда әлеге төр синтаксик берәмлекләрне авторлар үзләренең персонажларында күрергә теләгән сыйфатлар турында сүз алып барганда җәлеп итәләр: *Тәрбияле кызлар хатын улдыклары соңында бер өйне гакыл илә идарә кылырлар, баланы гүзәл тәрбия идәрләр, ирләренә ышанычлы вә* ***тугры гакыл вә киңәш вирүче, күңелләрене шадландыручы, серләрене һәм мөхкәм саклаучы ибдәш*** *улырлар* [15: 68]; *...кулларына тәсбих тотыб,* ***сүз почтасы йөртүче, төкереге илә биздерүче яки сәүдерүче картчыкларга*** *бәян идәрләр* [15: 69].

Алга таба алар әсәрләрдә пейзаж тасвирламаларында урын алалар: *Гүнәш нур вә эсселекне* ***чыбарланмыш каралара*** *сачмыш иде* [1: 53]; *Хәб шәһәр тирән уйкуйа далмыш, урамда* ***янан фәнәрләр*** *кызның күңленә аз хушнудлык вирделәр* [1: 53]; *Бу шәһәрнең биналары, урамлары,* мәсҗедләренең ***күккә чыкган манаралары*** *– җөмләсе мәхәббәтле күрелмәкдә иде* [15: 8]; *...**күккә аз гына йитмәгән таулар** күңелгә ләззәт китерә иде* [15: 22].

**Сыйфат сүзтезмәләрнең стилистик кулланылышы.** Әлеге төр синтаксик берәмлекләр текстларда, нигездә, персонажлар яисә аерым затларга хас булган билгеләрне атап, аларның портретларын тудыруда катнашалар: *Янә бер дәкыйка кичдекдән соңра ишекләр ачылды, ишекдән* ***урта буйлы, кара сакаллы, озын кара сачлы*** *бер рус керде* [2: 11]; *Егерме яшьләрендә хисаб улынан бу татар* ***гүзәл чәһрәле, тулгун вөҗүдле, кызыл йөзле, майлы күзле*** *мөлаем бер егет иде* [9: 12]. Үзе ***ачык йөзле, тугры сүзле*** *бер мужик булыб, һичбер вакыт кеше гайбәтен сөйләб вакыт кичермидер* [10: 74]; *Бер-берләрендән аерылдыклары вакытда Әсма* ***кечкенә вә ак йөзле, аз канлы, йомшак вә акрын сүзле*** *иркә бала улыб, Габбас мелла да кара сач вә* ***кара сакаллы*** *иде* [16: 128].

**Фигыль сүзтезмәләрнең стилистик кулланылышы.** Текстларда бу синтаксик берәмлекләр стилистик планда, нигездә, катлаулы метонимияләр барлыкка китерүдә катнашлар: ***Галиб улмак эстәйәнләр*** *бу хәдисне ишедеб вә менла Хисаметдин илә мөбәхәсәйә тәкатләре йетешмәдегене фәһемләб сөкүтә мәҗбүр улдылар* [1: 18]; *Хатынларымызның да* ***аракы вә башка мөскираты сәвәнләре*** *юк дәгел* [3: 6]; *Авыл вә карйә* ***имамлыкы җәһәтенә керәчәкләр*** *русча сүзләшмәйә вә укымайа белмәләре лязимдер* [3: 13]; *...**яшь гомердә тырышканлар** картлыкда рәхәт күрерләр* [15: 34].

Алга таба мәгърифәтче язучылар аларны персонажларның портретын биргәндә һәм аларга хас булган сыйфатлар турында сүз алып барганда файдаланалар: *Йөзендән дәрин* ***фикерә далдыгы беленер*** [1: 3]; *Янидән чыкмыш кечек сакалы вә мыеклары вә кечек сачы коңгыр* ***рәнкдә улыб*** *йөзенең гүзәллегене даха зиядәләшдererләр* [1: 4]; *Бүлмәнең идәненә бәһале ковёр дүшәлмеш, тәрәзәсендә хуш исле гөлләр вә башкача ив әсбабының яхшылыгы Әхмәди Хәмидевнең бай* ***адәм идегенә*** *дәлаләт кылалар иде* [2: 24]; *Йөзендә улган тир борчаклары* ***энҗеләргә ошаб*** *тезелеб торадыр иде* [15: 18].

Шуның белән бергә фигыль сүзтезмәләр пейзаж картиналарын тудыруда катнашалар (а) һәм вакыйгаларның тасвирламаларында да урын алалар (ә):

а) *Бер урамлы **авыл булыб,** урамы озын вә киңдер. Урамы узайыб, кыйбла тарафындагы **очында борылыб,** суга юл чыкадыр* [1: 2]; *Кырда юл **бәркарар улмайыб**, кар бераз ягмыш иде* [1: 7].

ә) *Маһруйның әнкәсе, бу сөалә җаваб вирмәйенчә, кечек балалардан зиядәрәк тавыш илә **кычкырыб җыгламайа башлады*** [3: 38]; *Буңа каршы уларак бән дә Хуҗа Насретдин **ләтыйфәләрене хикәят вә тәрҗемә идеб**, туташны көлдерер идем* [15: 51].

Текстларда әлеге синтаксик берәмлекләр бер-бер артлы кулланылып, сурәтләнә торган вакыйгаларның динамикасын арттыруда да катнашалар: *Яшь кыз йомшак **душәгендән торыб, әтрафа бакыб,** җөмләсе уйкуда улдыкларыны белдекдән соңра, **лампасыны яндырыб, каләм-кәгазь тапыб,** бөйлә мәктүб язды* [1: 37]; *Господин Шубин... кесәсендән бер кисәк **балавыз чыкарыб**, ...мәзкүр балавызга револьверның, дуласының **очыны басыб**, револьверның зурлыгыны, биеклегене үлчәб алды* [2: 58]; *Бу сөальдән соңра Маһруй... Ягъкубла беренче дәфга нә **тарик вә** нә **йирдә күрешдегене** вә әүвәл күрешдекдән соңра йиде ай бушка кичермәйән гомерене тәфсыйлән вә нә вакытда хамилә улдыгыны, вә йиде ай кичкәч, Ягъкубла мабәенләрендә зоһур идән намәхәббәт вә салкынлыкны вә соңра ике ай микдар **бер-берене күрмәдекләрене** вә мәгълүмеңез картчык ивендә ир **углан вөҗүдә килтердегене** вә... Ягъкуб Галиевкә хат языб, **картчыкдан ирсал кылдыгыны**, ...һәркаюсыны тәфсыйлән бәян кылды* [3: 25].

Аерым очракларда әлеге нигездә тасвирлана торган вакыйгаларның динамикасын арттыра торган градацияләр барлыкка килә: *Җиһангир, Маһруйны бу **кәйфиятдә күреб, мөтәхәйир вә мөтәфәккир улыб**, бер-ике секунд сөкүт соңда кесәсендән **пәке (пычак) чыкарыб, өстәл өстенә менеб, питлә җебене кисеб**, Маһруйны әҗәлдән хәлас кылды* [3: 41].

Авторлар тарафыннан мондый төр градацияләр геройларның хис-кичерешләрен һәм эчке халәтләрен ачып биргәндә дә файдаланылалар: *Кечек бала исә, үз **әткәсене таныб, фәрехләнеб, каршысына җөгереб килеб**: «Әткәй! Әткәй!» – дийү, кулыны вә муенындан кочаклаб, йөзене вә башыны үпмәйә башлады* [3: 38]; *Маһруй, атәш күзләре илә бүлмәнең стенасы (дивары)ны карарқән, кечек тәрәзәдә улан тимер **рәшәткәйе күреб,** гвоздь **зарур улмадыгыны белеб,** котырган **кеше кеби гаҗәлә кылыб,** җебне **кулына алыб** вә бүлмәдә улан кечек өстәлне тәрәзәнең **янына килтереб, өстенә менеб**, җебнең бер тарафыны **рәшәткәйә баглаб**, питләле тарафыны **муенына кийеб**, аягы илә **өстәлне орыб агдарыб**, әҗәлнең **кулына дөшеб,** гаять агыр мәшәкатьләр илә җан тәслим кылмайа башлады* [3: 41].

Текстларда фигыль сүтезмәләргә хас стилистик үзенчәлекләр аларның чагыштырулар буларак кулланылышында да чагылыш таба. Аерым алганда бу төр синтаксик конструкцияләр:

1) персонажларның психологик халәтен, аларның хис-кичерешләренең дәрәҗәсен ачып бирәләр: *...Гайшә ханымның йөзе, үлгән **адәм йөзе кеби агарыб**...* [2: 67]; *Хәдичә туташ да бу кеби гүзәл **мәслихәтне ишедеб,** тәхте каләмдә тәмам улмайачак кадәр шадланды* [2: 29];

2) башка эш-хәрәкәтләрнең үтәлү рәвешен ачыклап киләләр: *...аучы **куян вә үрдәкне өмид идеб сакладыкы кеби** бу да никахлар өмид идеб сакламакда иде* [1: 19]; *Муса әфәндейе мәхкәмәдән уле **кешейе чыкарган кеби** күтәреб чыкардылар* [2: 47]; *Үз **баламны тәрбия кылган кеби** тәрбия кылырмын* [3: 28]; *Бунлар гүя каты кычкырышмак **мөсабәкасы (ярышмак) идәр кеби** бер-берендән артык кычкырышырлар* [16: 59].

Алга таба фигыль сүзтезмәләр әсәрләрдә тасвирлана торган вакыйгаларның һәм процессларның ни сәбәпле башкарылуын ачып бирү чарасы буларак кулланылалар: *Бу сөале ишедеб, җәмгыятьнең чугысы вә хосусән Бикбулат менла вә Гали бай вә углы бу шәкерд **Хисаметдине хараб идәр дийү** батинән мәмнун улдылар* [1: 15]; *Казан байлары мабәйнендә мәшһүр вә мәгъруф бай Әхмәди Хәмидев Хәдичә исемле кызыны йөз мең сум көмеш **акча илә кияүгә вирдегендән** Муса Салихов Хәдичә туташны кәләшлеккә аладыр иде* [2: 9]; *Фәридә исә, әбкәсенең **җыглаганын күреб**, әүвәлгедән зиядә яшьләр дүгеб, әткәсенең муенына кочакланыб, җыгламайа дәвам итде* [3: 38].

Моннан тыш алар тасвирлана торган вакыйгаларның вакытын башка процесска мөнәсәбәттә конкретлаштырганда җәлеп ителәләр: *Җомга **намазыны укыдыктан соңра,** Хисаметдин менла атны чанайа йигеб, бәгъзы кирәк шәйләр алмак ичүн шәһәрә юлланды* [1: 7]; *Сибгатулла әфәнде исә **атасыйла хәбәрләшдекдән соңра,** үлек кеби агарыб, кайгы вә әфкяр дәрьясына батды* [1: 54]; *Бер сәнә мөкаддәм мән **Петербургга вардыкымда** «Татарский ресторан» исеме илә мәшһүр вә мөгътәбәр чәйханә вә номерләренең 8 нче номеренә дөшдем* [2: 21]. *Ягъкубның өстенә өч-дүрт тас кайнар **су салдыгымдан соңра**, «тәмам» идәйем дийү, агач шайкасы-ләгәнлә ике дәфга идәнгә егылмыш Ягъкубның башына ордым* [3: 26];

Публицистик чигенешләрдә фигыль сүзтезмәләр XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында татар җәмгыятендә күзәтелгән тискәре иҗтимагый күренешләрнең табигатен ачып бирә торган антитезалар тудыруда катнашалар: *Мондаен **сафсаталар белән гомер черетеб** тә, дөнья вә ахирәт өчен файдалы **гыйлемнәрне үгрәнмәгәнлегебез** өчен милләтебезнең хәленә бик шиддәтле тәәссеф иттем* [10: 35]; *Ун **еллар тәхсил идеб** дә һәм Казаның беренче дәрәҗәдә шөһрәт **мәдрәсәсендә тәрбияләнеб,** бер **кыз кадәр сүзләй алмадыгым** олуг гаеб вә бөек кимчелек иде* [15: 21]; *Безнең Казан байларының хатынлары, **ирләре үлгәндә үкереб-үкереб егълаб,** иртәге **көнендә көлә-көлә** яшь кияүгә кидәләр иде...* [15: 34].

Фәнни стиль катламында алар укучыларга этнографик, конфессиональ һәм тарихи характердагы мәгълүматны җиткерү өчен хезмәт

итәләр: *...Казанда йөз биңдән зиядә* ***җан хисабы улыб****, дүртенче өлеше әхле исламдыр. Мөселманлар җөмләсе сөнни вә Әбу Хәнифә* ***мәзһәбендә улыб****, делләре һәм төрекчәдер. Голәма вә шәкердләре* ***чапан вә чалма кийеб****, сәүдәгәре өстендә сукна бишмәт, чалбар, каракүл бүрек уладыр. Хатынлары* ***калпак, такыйа, читек, кәвеш кийеб,*** *урамга чыкдыкларында чапан бөркәнәләр* [15: 3].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, XIX гасыр – XX гасыр башы татар әдәби телендә сүзтезмәләргә йөкләнгән стилистик вазифалар беренче чиратта аларның рифма, катлаулы метафоралар, эпитетлар, метонимияләр, градацияләр тудыру чарасы буларак, образлы төсмерләр һәм иҗтимагый эчтәлек белән баетылып кулланылышында чагылыш таба. Шуның белән бергә әлеге синтаксик берәмлекләргә персонажларны тасвирлау, аларның рухи дөньяларын һәм психологик халәтләрен ачып бирү, пейзаж картиналарын тудыру, заман таләпләреннән чыгып, аерым социаль күренешләр һәм иҗтимагый институтларга бәя бирү, укучыларга этнографик һәм социаль-икътисади, конфессиональ һәм тарихи характердагы мәгълүматны җиткерү, аерым иҗтимагый күренешләрнең асылын ачып бирү кебек вазифалар йөкләнә.

**Әдәбият**

1. *Акъегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

2. *Бигиев З.* Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә. Роман. Казан: Тип. Г.М. Вечеслава, 1887. 77 б.

3. *Бигиев З.* Гөнаһе кәбаир. Роман. Казан: Тип. Г.М. Вечеслава, 1890. 72 б.

4. *Бигиев З.* Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр). Казан: Типолитогр. И.В. Ермолаевой, 1908. 108 б.

5. *Бикколов К.* Алтынбай агай. Авыл халкының көнкүрмешен тасвир иткән роман. Казан, 1908. 40 б.

6. *Бикколов К.* Бәдәлче. Казан: Типо-литография Н.М. Чижовой, 1909. 80 б.

7. *Бикколов К.* Хаҗи. Казан: Лито-типография «Братья Каримовы», 1912. 47 б.

8. *Кәрими Ф.* Яурупа сәяхәтнамәсе. Оренбург: Тип. «Вакыт», 1902. 191 б.

9. *Кәрими Ф.* Кырым сәяхәте. Оренбург: Тип. М.-Ф. Каримова, 1904. 116 б.

10. Фатих Кәрими. Морза кызы Фатыйма. Сайланма әсәрләр / [китапны төзүче, иске язмадан заманчага күчерүче, аерым сүзләргә аңлатма бирүче һәм кереш мәкалә авторы филол. фән. канд. М.В. Гайнетдинов]. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 414 б.

11. Татар грамматикасы: өч томда / [проект җит. һәм автор М.З. Зәкиев]. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2017. Т. III. 536 б.

12. *Тукай Г.М.* Әсәрләр: 6 томда. 1 т.: шигъри әсәрләр (1904–1908) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Р.М. Кадыйров, З.Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Н.Ш. Хисамов, З.З. Рәмиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 407 б.

13. *Тукай Г.М.* Әсәрләр: 6 томда. 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Р. Шәйхелисламов, Г.А. Хөснетдинова, Э.М. Галимҗанова, З.З. Рәмиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 384 б.

14. *Мөхәммәдев Ш.* Сайланма әсәрләр / [төз. М. Гайнуллин]. Казан: Таткнигоиздат, 1958. 408 б.

15. *Фәхретдинов Р.* Сәлимә, яки Гыйффәт. Гафил бән Габдулла әсәре улараk бер хикәятдер. Казан: Тип. Б.Л. Домбровского, 1899. 80 б.

16. *Фәхретдинов Р.* Әсма, яки Гамәл вә җәза. Оренбург: Тип. М.-Ф.Г. Каримова, 1903. 130 б.

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Мирхаев Рифат Фирдинатович,***
*доктор филологических наук, доцент, ведущий научный сотрудник отдела общей лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*mirhaev77@mail.ru*

УДК 811.512.145'28

***М.Р. Булатова***

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ХВАЛЫН, КАРСУН, МӘЛӘКӘС СӨЙЛӘШЛӘРЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
## (йола фольклоры текстлары мисалында)

Статья посвящена этнолингвистической характеристике хвалынского, мелекесского, карсунского говоров западного диалекта татарского языка. Она написана на основе конкретных материалов, собранных автором во время комплексной экспедиции, проведенной в 2017 г. Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ по татарским населенным пунктам Старокулаткинского, Мелекесского, Карсунского районов Ульяновской области. В текстах (образцах речи), содержащих материалы по обрядовому фольклору, традициям татар данного региона, рассматриваются языковые особенности хвалынского, мелекесского, карсунского говоров. Анализ ведется в сравнительном плане с литературным языком, а также с другими говорами западного диалекта татарского языка.

**Ключевые слова:** татарский народ, диалектология, западный диалект татарского языка, хвалынский говор, мелекесский говор, карсунский говор, обрядовый фольклор, народные традиции.

The article is devoted to the ethnolinguistic characteristics of the khvalyn, melekes, karsun subdialects of the western dialect of the Tatar language. It is written on the basis of specific materials collected by the author during a comprehensive expedition conducted in 2017 by the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan to Tatar settlements of the Starokulatkin, Melekes, Karsun districts of the Ulyanovsk region. The texts (speech samples) containing materials on ritual folklore and traditions of the Tatars of this region examine the linguistic features of the khvalyn, melekes and karsun subdialects. The analysis is conducted in a comparative manner with the literary language, as well as with other subdialects of the western dialect of the Tatar language.

**Keywords:** Tatar people, dialectology, western dialect of the Tatar language, khvalyn subdialect, melekes subdialect, karsun subdialect, folklore, folk traditions, national cultural heritage.

Ульяновск өлкәсе территориясе тарихи яктан төрле чорларда Идел буе Болгары, Алтын Урда, Казан ханлыгы составына кергән, ягъни татарлар монда борынгыдан ук яшәгән. 2021 елның статистик мәгълүматлары буенча, төбәктә татарлар саны 111 365 кеше тәшкил итә (1989 елда – 159 093, 2002 елда – 168 766, 2010 елда – 149 873 татар). Алар Ульяновск, Димитровград, Яңа Сембер, Барыш шәһәрләрендә һәм Базарлы Сызган, Барыш, Карсун, Мәләкәс, Николаевка, Яңа Малыклы, Яңа Спас, Павловка, Радищев, Иске Кулаткы, Чынлы, Чардаклы һәм башка районнарның 70 кә якын торак пунктында яшиләр [4: 268].

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, татарларның телен, әдәбиятын, халык иҗатын, музыкаль һәм тасвирый сәнгатен югары фән дәрәҗәсендә өйрәнә торган гыйльми-тикшеренү үзәге буларак, милләттәшләребез яшәгән төрле төбәкләргә фәнни экспедицияләр уздыра. 2009 елдан ул комплекслы рәвештә оештырыла башлый. Мондый юл белән эш алып барганда, төрле белгечләр тарафыннан татарларның тел үзенчәлекләре, халык авыз иҗаты, йола-гадәтләре, музыкасы, йорт-каралты бизәкләре, эпиграфик һәм археографик мирасы берьюлы өйрәнелә.

Ульяновск өлкәсе татар авылларында рухи хәзинәләрне барлау, тел үзенчәлекләрен өйрәнү XX гасыр урталарыннан ук башлана. Бу төбәккә оештырылган фольклор экспедицияләрендә Х.Х. Ярми, Х.Х. Гатина, И.Н. Надиров, Ф.И. Урманчеев, Х.Ш. Мәхмүтов халык иҗаты үрнәкләрен язып алып кайталар. 1950–1990 елларда Институтның тел белгечләре – диалектологлар Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Г.К. Якупова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова, З.Р. Садыйкова һәм Т.Х. Хәйретдиновалар да Ульяновск өлкәсенә махсус диалектологик экспедицияләр уздыралар; милләттәшләребезнең тел үзенчәлекләре, шулай ук тарихы, традицияләре галимнәрнең фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләрендә чагылыш таба [1; 5].

2017 елда, татар халкының милли-мәдәни мирасын туплауны дәвам итү максатыннан, Ульяновск өлкәсенә оештырылган комплекслы экспедиция төбәкнең Иске Кулаткы районы Муса (Мосеевка), Иске Атлаш (Старый Атлаш), Иске Мостяк (Старый Мостяк), Яңа Мостяк (Новый Мостяк), Яңа Терешка (Новая Терешка), Урта Терешка (Средняя Терешка), Киръявыл (Кирюшкино), Иске Зеленай (Старое Зеленое), Вязовый Гай, Зимичә (Зимницы), Иске Кулаткы (Старая Кулатка), Иске Яндука (Старая Яндовка); Карсун районының Нугай иле (Нагаево), Аксу (Татарская Голышевка), Сакускай (Уразово), Татар Гуринкасы (Татарские Горенки); Мәләкәс районының Атнагыл (Аллагулово), Мукшы Күле (Мордово-Озеро), Мөси (Моисеевка), Филип (Филипповка), Парау (Боровка) авылларында уздырылды.

Әлеге экспедиция вакытында безнең тарафтан мондагы татарларның җирле сөйләш үзенчәлекләре, шуның белән бәйле рәвештә халыкның көнкүреше, йолалары, гореф-гадәтләре һ. б. турында мәгълүмат тупланды. Җыелган материаллар фонетик, грамматик һәм лексик яктан тикшерелде [2; 3].

Милләттәшләребездән бала тууга (*бәби мае, акыйка корбаны* һ. б.), армиягә озату, йорт салып чыгуга (*урнаш җыю* һ. б.), яшьләр туена (*билге бирү, казык санау, бирнә бирү, кан'ишка төшү, тигәнә йыштыру* һ. б.), Яңа ел алды бәйрәменә (*фал ачу, кәрәләр көне* / *кәрә йөрү* һ. б.), яз айларында үтә торган (*нәүрүз бәйрәме, кызыл йомырка көне, аяк сынау* һ. б.), боз озатуга (*су багу* / *су ташу* / *су теләге, көймә җибәрү, сал җибәрү*), яңгыр теләп, корбан чалуга (*келәү үткәрү* / *келәү йыштыру, келәү пешерү* / *яңгыр боткасы*), яшьләрнең

кич утыру, вичер уздыруларына, балаларның уеннарына (*ашыктан, гөрләштән, шакшакыйдан, орчык, су агыш, алтыдан, кл'уктан, йезелеш, чижек, мәчтән, кул сугыштан, йөзек салыштан, машыктан* һ. б.), аш-суга, сабан туена, күзге сугымнарга (*каз өсте / каз өмәсе, чирукка булу* һ. б.) бәйле йолалар, бәйрәмнәр, шулай ук такмаклар, авыллар тарихы, легендалар, тормыш-көнкүреше турында бай материал тупланылды.

Ульяновск өлкәсенең без өйрәнгән авылларында татар теле көнбатыш диалектының өч сөйләше таралган: Иске Кулаткы районында – хвалын, Карсун районында – карсун, Мәләкәс районында – мәләкәс сөйләшләре. Түбәндә йола фольклоры текстлары үрнәкләрендә бу сөйләшләрнең көнбатыш диалектның башка сөйләшләре белән кайбер уртак билгеләре тасвирлана:

1. Фонетик яктан:

а) [а] авазын ачык итеп, иренләштермичә әйтү ([каз] – тат. әд. [қа°з], орф. каз һ. б.):

[САWЫМ ‘туйга алып барыла торган күчтәнәч, азык-төлек’. Саwымнар йасый идек. Туйга алып барасын каз, пирук, кош теле, чакчак. Ул саwым атала. Йегет йагы бал алып килә. Ә кыз йагы чакчак пешереб барабыз] (Мәләкәс районы Атнагыл авылында Гайнуллина Гөлҗиһаннан (1938 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

ә) [о], [ө] авазларын иренсезләштерү, ягъни [ы]~[о], [е]~[ө] ([тырмыш] – тат. әд. [тормош], орф. тормыш; [тен] – тат. әд. төн һ. б.):

[ЙЕЗЕЛЕШ. Йаз башында, йер кипкәчтән, тау башында йезелеш (йөзелеш < өзел(ү)+еш) ун'ий идек. Ике кеше вата ‘менә’ шулай басып тора и алында ‘алда’ бер кеше. Күп кеше икешәр кеше баса беррәттән. Арттан бер кеше йезеләләр дә йогыралар. Йезеләләр дә үзгә ‘башка’ белән кушылалар. Как йегете белән айырылып бергә китә инде – йезелә ‘өзелә’. Йегет кеше йугырта кемедер, йараткан кызы артынан йогора. Теге тыттырмаска тырыша. Тытса ‘тотса’, аннан алынга ‘алдагыга’ тытына. Шулай итеп пар'-пар'] (Карсун районы Татар Гуринкасы авылында Мусаллямова Фаиләдән (1933 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

[САБАНТУЙ була иде. Алашлар ‘атлар’ белән түәлеп, семйа-семйа, оланнар ‘балалар’, арба артына асылып бара идек. Сабантуй урман йанында бик кечле ‘көчле’ була иде. Анда бийү, җырлау, уйыннар терле-терле ‘төрле-төрле’: баганага менү, мишукта сикерү, керәшү ‘көрәшү’] (Иске Кулаткы районы Иске Зеленай авылында Бикбаева Илһамиядән (1938 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

б) *-өй* дифтонгы урынына [ү] монофтонгын әйтү ([кү] – тат. әд. көй; [үләнү] – тат. әд. өйләнү һ. б.):

[КАН'ИШКА ТЕШҮ ‘егет йортына килен булып төшү’. Кан'ишка тешкәндә, ат [д]җигеп, сондык белән килә идек. Анда үзеңә

әйберләрең: чашка, комган, кашыклар, кийемнәр. Нәнәйләр ‘әниләр’ үендә ‘өйөндә, орф. өендә’ нәрсәләр кийәсен, шуларны сондык түәп ‘төйәп, орф. төяп’ алып киләсен.

«Энә генәм, йеп кенәм
Калды сондык тебендә.
Рәхәт кенә, тыныч кынам
Калды анам йебендә/үендә».

«Кан'иш йорты – кабыктык,
Кабык булса да, тамыктык.
Анай йорты саламдыр,
Саламдыр да сарайдыр»,

дип такмакладык] (Карсун районы Нугай иле авылында Вәлиуллова Таибәдән (1942 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

в) *ай, әй, уй, үй, ой* дифтонгларын монофтонглаштыру һәм алардан соң килгән тартыкларны нечкәртү ([кан'ар] – тат. әд. [қа$^{о}$йнар], орф. кайнар; [кан'а] – тат. әд. [қа$^{о}$йнана], орф. каенана; [ат'а / әтә] – тат. әд. әйтә һ. б.):

[БИЛГЕ БИРҮ ‘кыз ягыннан егет йортына вәгъдә бүләге итеп бирелә торган әйбер’. Беренче көнне кан' ‘каената’ белән кан'а-га ‘каенанага’ билге бирәләр. Йә лаукадан ‘< рус. лавка – кибет’ алынган йәмне ‘матур’ шәлләр, йә башкасы. Күрешү, сүләшү була инде. Йахшы эстәл. Шунда сүләшәләр кач'ан ‘кайчан’ туй уздырырга. Билге биргәннән суң, никах була. Мулла йәшәләр ник'ахта. Кыз йаныннан да, ир йагыннан да $^{д}$җийылалар. Шунда бирнәне эләшеп чыга] (Карсун районы Аксу авылында Кафиятуллова Мәстүрәдән (1939 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

г) бер төркем сүзләрдә [у], [ү] авазлары урынына [о], [ө], [ө$^{Y}$] яки [ы] / [ы$^{о}$], [е$^{е}$], [э(е)] авазларын куллану ([орлау] – тат. әд. урлау; [төбә] – тат. әд. түбә; [ыл] – тат. әд. ул һ. б.):

[ТИГӘНӘ ЙЫШТЫРУ ‘тигәнә – киленнең булачак каената-каенана һәм аларның балаларына әзерләгән бүләге’. Кан'ага ти(е)гәнә йыштыралар ‘җыеп, әзерләп куялар’ иде. Тигәнә – намазлык, битсебергечләр ‘сөлгеләр’, эстәкерләр ‘< рус. скатерть’. Кан'га, кан'ага шындый ‘шундый’ көᵞлмәк ‘күлмәк’, намазлык. Тегәнә кан'ага и сим'йадагы кешеләренә бирелә. Сигез кеше сим'йада булса, сигезесенә дә көᵞлмәкләр. Кан'ага ыштан да көᵞлмәк, йаулык. Кан'га көᵞлмәк кенә куйыла. Минем ү$^{о}$ч кенә иде, көп тегел ‘күп түгел’ – кан'сеңлем дә кан'игачым. Аларга да әзерлибез] (Карсун районы Нугай иле авылында Вәлиуллова Таибәдән (1942 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

д) әдәби телдәге тирән тел арты [қ], [ғ] авазлары урынына тел арты [к], [г] авазларын куллану ([каз] – тат. әд. [қаз], орф. каз; [йылга] – тат. әд. [йылға], орф. елга һ. б.):

[БӘБИ МАЙЫ, АКЫЙКА КОРБАНЫ. Бәбәй майы булса, бәбәйгә акыйка корбаны чалдыралар. Малайга икене акыйкә корбаны суйырга, ә кызга берне. Анда куй суйалар. Карту ‘бәрәңге’, ит белән салма ботка. Коран уку була, дыва ‘дога’ кылалар. Чәй эстәленә майны беренче куйалар. Бал да була – баланың теле татлы булсын, йомшак булсын. Йарты метрлык, бер метрлык таwар китерәләр бәбәйгә] (Иске Кулаткы районы Иске кулаткы авылында Тимушева Розадан (1932 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

е) иялек килеше һәм фигыль кушымчаларында [н]~[ң] тәңгәллеге күзәтелү ([анын] – тат. әд. аның; [бардын] – тат. әд. бардың һ. б.):

[КЫЗЫЛ ЙОМЫРКА КЕНЕ. Йомырканы суган кабыгына кызарталар. Аны оланнарга ‘балаларга’, этиләргә, нәнәйләргә ‘әниләргә’ – барына да бүләләр. Кемгә йомырка күбрәк – ул бәхетле була имеш. Сынамыш кенне кемнен айагы җиңел – аны сыныйлар. Үгә беренче кеше кем керә, айагы җиңел булырмы, йукмы инде. «Җиңел айаклы» кеше беренче булып кабактан ‘капкадан’ керсә, йыл шул гаиләгә йахшы үтер, «аwыр айаклы» кеше керсә – йыл уңмый. Шуңа да, кичтән үк, җиңел айаклы кешегә ат'еп ‘әйтеп’ куйасын килергә. Кемдер белгәнен кертә, йә хозайка үзе чыгып керә. Йат кешенен айагы ниндидер булыр. Шул иртүк килгән кешегә чәй эчертәсен, кызыл йомырка биреп чыгарасын. Апрел' айында уздырыла] (Иске Кулаткы районы Иске Зеленай авылында Бикбаева Илһамиядән (1938 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017).

2. Морфологик яктан:

а) инфинитивның *-ырга/-ергә* кушымчалы формасының актив кулланылуы *(алырга, килергә), -малы/-мәле, -асы/-әсе* диалекталь формаларның табылмавы:

[КӘРӘ ЙЕРҮ / КӘРӘЛӘР КЕНЕ ‘Раштуа көннәрендә төрлечә киенеп, өйдән-өйгә кереп теләкләр әйтеп йөрү’. 23–25 декабер'дән ‘хәзерге 7 январь’ тытыналар йерергә кәрәне. Кәрәләр бар. Хәзер инде балалар гына йери, ә элке барыбыз да. Терлечәли кызык кийенәсен дә, керәбез кемдә ут бар. Капрон калготкины кийәсен дә, корыммы тертәсен, кызылын да сертәсен. Элкедән үк килгән кәрәләр. Безнен йакта бетмәде ул. Иремнен дусты гармун белән. Кәрәләр керә, йырларга тытыналар: «...сондыгында конфетың бар. Миңа бир», дип. Йукамы йә чигелдәк ‘бавырсак’ кебек нәрсә пешереп куйырга кирәк. Аны аларга да бирәбез. Аннары: «Әби, сау бул, Яңы йыл бәхет китерсен! Ызын үмерле бул!», дип әтеп чыгып китәләр. Кәрәләр булып олылар чыкты безнен дәwердә. Дайаркадан килеп, таң аткынчы, тен йери идек шулай]

(Иске Кулаткы районы Яңа Мостяк авылында Нажия Абдуллинадан (1959 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

ә) хәл фигыльләрнең *-гачтан/-гәчтән/-гәчтен/-гычтан* (тат. әд. *-гач/-гәч*), *-ганчык/-гәнчек, -гынчык/-гынчак/-генчәк* (тат. әд. *-ганчы/-гәнче*) кушымчалы формалары активлыгы:

[БЕЗЕЛЕК – йаз башын ‘язын’ кар киткәчтен ‘киткәч’, бозлар ташу wакытында, җир ачылгачтын ‘ачылгач’ да беренче уйыннар. Ул элгәредән килгән. Йегет-кызлар бер-берсен чакырышалар. Без, оланнар, кен ката ‘көн буе’ бактык. Утрау кебек җирләр, анда чәчелми дә. Малайлар учак йагып, карту ‘бәрәңге’ көмеп, ашапэчәләр иде. Картлар, кызлар теләк тели иде. Алар суга бәрәләр иде чоргап. Акканын бага – каа ‘кая’ да терәлмәсен. Без, йәшләр, кимәләр ‘көймә’ йасап бәрә идек. Кимә вата ‘менә’ кагыздан йасадык, шуны йебәрә идек. Кас'ының саулыгы йук – саулык сорый] (Иске Кулаткы районы Иске Зеленай авылында Бикбаева Илһамиядән (1938 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

[АРМИЙӘГӘ ЫЗАТУ. Элке салдатка (ы)затканда вичыр җийасын – йырлыйлар, бииләр. Малайны иртән (ы)затасын: ынга кулларын бастыралар, аннан әпәйне авызына каптырасын, арты белән ишектән чыгаралар. Ынны килеш урамга чыга. Әпәйне кибәргә куйалар. Аны ул кат'кынчык ‘кайтканчы’ саклап тотасын. Сондыкка салганнар йә киштәгә куйганнар. Армийәдән кат'качтан ‘кайткач’, шул әпәйне каптыралар] (Карсун районы Нугай иле авылында Хабибуллова Саниядән (1935 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

б) Ульяновск өлкәсе татарлары сөйләменә үзенчәлекле булган *вана* / *ван'а* < рус. вон – тат. әд. ‘әнә’, вата < рус. вот – тат. әд. ‘менә’ күрсәтү алмашлыклары хас:

[РАШТУА КЕНЕ. Чигелдәк ‘бавырсак’, кызыл йомырканы Раштуа кенне пешерәләр. Камырны вата ‘менә’ шулай ывак-ывак кисәбез и май эчендә пешерәсен. Йаңы йыл алдыннан Раштуа була. Шул кеннәрне йериләр, кийенешеп. Тирес туннарны әләндереп кийеп йериләр раштуада. Кылындыртып. Вата ‘менә’ шуларга шул пешергәннәрне бирсән, терлегең күп була, диләр. Аннан суң кызыл йомырка кенне бирсән дә, пасха кенне. Айак сыныйбыз – буйыйбыз йомыркаларны, кызыл йомырка кенне кем керә синең үеңә. Начар кеше керсә, терлегең кат'мый ‘кайтмый’, чебешләрең булмый, чыкмый. Йахшы кеше керсә, барысы да йахшы бара] (Иске Кулаткы районы Вязовый Гай авылында Юсупова Саниядән (1953 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017).

в) *әмән, сынны* ‘тат. әд. шикелле, кебек’ охшату-чагыштыру бәйлекләре дә очрый. *Әмән* сүзе теркәгеч ‘гүя, әйтерсең лә’ функциясен дә үти. Мисаллар: *Бу азыкны нәзек колак сынны ‘кош теле шикелле’ камырдан йасыйлар бит. Кара болыт зыйанлы – нәрсәдер әмән була инде.*

[КИЧ УТЫРУ. Кәнәфи бар иде. Аны бездә түр дип ат'ә иделәр. Артлы, йантыкларын төшерәләр әмән ‘әйтерсең лә’ мудалап инде. Артында да алында да такта иде. Элгәре, ‘кич утыру’ булганда, вата шул түргә утырып, кызлар кас'ы бәли ‘бәйли’, кас'ы чигә, кемдер йырлый. Йегетләре керә йаннарына. «Кусок ыштан» ун'ый иделәр: бер кеше бегелә, аның аркасына кулларын тезәләр. Кемнең кулы өстә. Рәсимәнеке. Анда минеке булмый әмән этийек. Белмәден, дийеп, аркасына тагын сугалар. Аннан, белсә инде, шул кеше йата өстәлгә, аны калдыралар иде. Кич утырганда картыраклар пешерә, ә йәшләр чигә иде. Кем запун чигә, кем йаулык вышиват' итә тамбу белән. Хозайка да үдә ‘өйдә’, безне ашата иде] (Иске Кулаткы районы Урта Терешка авылында Байбикова Рәсимәдән (1947 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017).

3. Лексик яктан. Уртак диалектизмнарның күп булуы (*алаша* – тат. әд. ат, *кабак* – капка, *олан* / *ылан* – бала, *кучат* – этәч, *кычык* – эт, *лаука* – кибет, *зыбын* – чикмән, *паңгы* – гөмбә, *айбагар* – көнбагыш, *чигелдәк* – бавырсак һ. б.) күзәтелә. Хвалын, карсун, мәләкәс сөйләшләре үзенчәлекле лексик берәмлекләргә дә бай. Текстларда чагылыш тапкан диалекталь лексиканы көнбатыш диалектның башка сөйләшләре белән чагыштырып карыйк, мәсәлән:

а) мәләкәс сөйләшендәге *кәлҗемә* ‘тат. әд. бөккән’ чүпрәле сөйләшендә – *кукыл',* стәрлетамак сөйләшендә – *сәмбүсә,* хвалын сөйләшендә – *сумса:*

[КӘЛҖЕМӘ. Сугымнар, каз өмәләре уздырабыз. Элгәредән тайнымы, үгезнеме, танамы суйалар – сугым ите була. Эцәкләреннән кәлҗемә, дибез. Баwырын мысаруфка аша цыгарып үwәләр, суганын, кишерен жарит' итәләр. Баwыр үзе коймак сынны ‘кебек’ гына пешә. Катлау-катлау кишере белән суганны куйасын да сертә барасын. Бу хутка кисеп-кисеп. Чече камырдан тәмне генә майда камырын да йасыйсын. Бәрәңге белә мысаруфка аша цыгарган эцәкне. Пешерәсен дә пирожки шикелле. Бездә ул кәлҗемә атала] (Мәләкәс районы Атнагыл авылында Гайнуллина Гөлҗиһаннан (1938 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

ә) карсун сөйләшендәге *битсебергеч* ‘тат. әд. сөлге’ шарлык сөйләшендә – *битйаулык,* мордва-каратай сөйләшендә – *битсебер,* чистай сөйләшендә – *битсөртөңгеч,* мәләкәс, байкыбаш, стәрлетамак сөйләшләрендә – *тастымал,* хвалын, кузнецк сөйләшләрендә – *йөслек* / *йөзлек,* чистай керәшеннәре сөйләшендә – *бистәр:*

[БИРНӘ БИРҮ. Бирнә ул айырым. Эләшәсен бирнәне бетенесенә дә. Бирнәгә катыннарга йаулыклар, ирләргә – битсебергеч ‘сөлге’. Бирнәне ник'ахта да бирәләр. Бирнә биргәчтән ‘биргәч’, сүләнгән сүз ышанычлы инде. Бирнә бирешкән, дир ‘дип’ бездә ат'әләр. Ә сондык белән үз әйберләреңне алып барасын – ул бирнә дип аталмый] (Карсун районы Нугай иле авылында Вәлиуллова Таибәдән (1942 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017);

б) хвалын, мәләкәс сөйләшләрендәге *әнәй / анай* ‘тат. әд. әни’ карсун, ләмбрә, сергач сөйләшләрендә *нәнәй* лексемасы белән бирелә. Чагыштыр: ‘әни’ мәгънәсен аңлаткан *нәнә(й)* варианты урта диалектның мамадыш, балтач сөйләшләрендә дә күзәтелә. Башкортстан татарлары сөйләшләрендә исә *нәнәй* сүзе ‘дәү әни’ мәгънәсендә генә кулланыла.

[ЙАХШЫ СҮЗ АЛЫП КИТҮ. Йегетләрнең атакай-нәнәйләре ‘әтисе, әнисе’ киләләр кызны сорарга. Риза булсалар, кызны бирсәләр, алар шунда «йахшы сүз алып китәләр», диләр. Бернәрсә бирәләр: йаулык йә битсебергеч. Бу йахшы сүз алып китү була. Аннан ник'ах] (Карсун районы Аксу авылында Кафиятуллова Мәстүрәдән (1939 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017).

[КАЧЫП ЧЫГУ (Бай кызы турында). Бер бай йәшәгән. Анын бер генә кызы, алты малайы булган. Кызны йахшы арбага гына утыртып урамда әләндерәләр ‘әйләндерәләр’. Аwылда бер бик матур йегет булган. Бай кызы белән бу йегет сүләшә башлыйлар инде. Читән аша гына сүләшү булган элке ‘элек’. Бай күреп калган: кыз бу йагында, йегет икенче йакта читәннен. Бай кызына ни әт'мәгән, узган да киткән. Әләнгән дә булачак кийәүне (йегетне) чыбык белән бик каты кинаган. Бу йегеткә бик обидны булган. Бу бабай үзе сүләгән. Бу кыз белән араны өзмәгән. Кыз белән озак сүләштереп тырган. Үзенә иләштергән ‘ияләндергән’, качып чыгарга ризалаштырган. Качып чыгулар булган элке. Кызга ат'кән: «Бүген килеп алам», дийеп.
Бер бик йәмсез генә йегет тә булган аwылда. Ул йарлы да, йәмсез дә, кемгә дә үләнә ‘өйләнә’ алмый – шундый булган. Матур йегет барган да ул йегеткә: «Брат, үләнәсенме?». «Миңа кем килсен?!» – дигән тегесе. «Шуның кызын аласынмы?». «Кит, ул миңа килмәс, мин аннан куркам», – дигән. «Аласынмы?». «Ну йарый, алам». Анын алашасы ‘аты’ булган. Килгәннәр теге кызны алырга. Тәрәзә тебенә теге бара да икән. Чыга да арбага-чанага утыртып, тымалап алып китә бай кызын. Иткәннәр ‘илткәннәр’ дә теге йәмсез йегеткә биргәннәр. Кыз йаратмый аны, теннә бармый да анарга. Бу бай кызы, шундый пачутлы кеше. Әтинен сеңлесе булган аларнын бер киленнәре. Ул килгән. Аны җибәргәннәр җиңгасын хал' белергә. Бабай ат'кән ‘әйткән’: «Бернәрсәгә дә бакмасын». «Алай-болай булса, үзе теләә(мә)сә, алам». Бу ат'кән: «Үзем теләп килдем», – дигән. Аннан соң анай ‘әни’ ат'ә: кибеп, корып койылып үлде кыз, ди. Йанып-күеп торган инде. Шундый хал'ләр булган элке. Кабактан ‘капкадан’ чыгарга йук иде, ди, анай ат'ә. Кабактан чыксаң, теннә орлыйлар ‘урлыйлар’. Тәртибе шул булган] (Иске Кулаткы районы Кирюшкино авылында Нурия Кысаевадан (1942 елгы) М.Р. Булатова язып алды, 2017).

Йола фольклоры текстлары үрнәкләрендә күрүебезчә, Ульяновск өлкәсе татарлары әби-бабалары тапшырып калдырган, милләтебезгә

хас йолаларны, гореф-гадәтләрне ихтирам итеп, халык авыз иҗаты әсәрләрен күңелләрендә саклап, туган телләрендә – матур татар телебездә – аралашып гомер кичерәләр.

Йомгаклап әйткәндә, татар теле көнбатыш диалектының башка сөйләшләрендәге кебек, хвалын, карсун, мәләкәс сөйләшләрендә дә авазлар системасы, сүз төркемнәре һәм аларның төп грамматик категорияләре, лексик-семантик системасы, нигездә, әдәби телдәгечә. Үзенчәлекле саналган морфологик билгеләрнең күпчелеге теге яки бу морфологик категориянең яки күренешнең төрле фонетик вариантлары булудан һәм иске татар язма әдәби тел нормаларына туры килгән күренешләрнең сакланып калуыннан гыйбарәт. Әдәби телдә очрамаган, сөйләшләрнең спецификасын тәшкил итә торган сүзләр (алынмалар, гомумтөрки сүзләр һ. б.) шактый гына булса да, төбәктәге сөйләшләрнең төп лексик составын татар әдәби теле белән уртак сүзләр тәшкил итә.

**Әдәбият**

1. Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья / науч. ред.: Н.Б. Бурганова, Л.Т. Махмутова; сост.: Н.Б. Бурганова, Л.Т. Махмутова (I т.), Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыкова, Т.Х. Хайрутдинова (II т.). Казань, 1989. + Прил.: Комментарии к Атласу. Казань, 1989. 300 с.

2. *Булатова М.Р.* Мелекесский говор мишарского диалекта татарского языка: морфологические и лексические особенности // Актуальные проблемы казахского языкознания: Материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 80-летию профессора Б.К. Калиева. Алматы: КазУМОиМЯ имени Абылай хана, 2019. С. 156–158.

3. *Булатова М.Р.* Татар теленең көнбатыш диалектының Ульяновск өлкәсендәге сөйләшләре һәм халык традицияләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Ульяновск өлкәсе татарлары. 2 нче басма. Казан, 2021. Б. 146–207.

4. Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник / отв. ред.: Л.М. Айнутдинова, Б.Л. Хамидуллин. Казань: ОП «Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ», 2016. 336 с.

5. Татар халык сөйләшләре: Ике китапта / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ. б. / Казан: Мәгариф, 2008. I китап. 463 б., II китап. 495 б.

***Булатова Миңнира Рәхим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Булатова Миннира Рахимовна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела ареальной лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*m.r.bulatova@mail.ru*

УДК 821.512.145

*Л.Р. Надыршина*

# 1930 ЕЛЛАР ТАТАР ПОЭМАСЫНЫҢ ТЕМАТИК ҺӘМ СӘНГАТИ ТӨРЛЕЛЕГЕ

В условиях революционных потрясений 1917 года татарская поэма поменяла векторы развития, проложенные в начале века, в период ускоренного развития национальной словесности: национальный идеал сменяется социалистическим, доминантой в структуре поэм становится противопоставление старого и зарождающего миров, активизируются поиски в области формы, лирическая поэма уступает место лирико-публицистической и др. При этом жанр поэмы в этот противоречивый период развивается не однолинейно: наряду с поэмами, созданными в рамках социалистических канонов, существуют и так называемые периферийные произведения, характеризующиеся усилением позиции романтического мировоззрения, тяготения к лиризации и философизации, актуализацией национальных, например, фольклорных, традиций. В статье проанализированы некоторые из таких поэм («Алсу», «Мәхәббәт тәүбәсе» («Исповедь любви») Х. Такташа, «Хат ташучы» (Письмоносец») М. Джалиля, «Ант» («Клятва») Х. Туфана, «Флейталар» («Флейты»), «Дала һәм кеше» («Степь и человек») А. Файзи, «Пар ат» («Пара гнедых») С. Хакима) и выделены ключевые тенденции в развитии жанра.

**Ключевые слова:** татарская литература, советская литература, поэма, жанр, жанровая трансформация.

In the conditions of the revolutionary upheavals of 1917 the Tatar poem changed the vectors of development laid at the beginning of the century during the period of accelerated development of national literature: the national ideal is replaced by a socialist one, the opposition of the old and nascent worlds becomes dominant in the structure of poems, searches in the field of form are being authorized, the lyrical poem gives way to the lyric-journalistic, etc. At the same time, the genre of the poem in this controversial period does not develop in a linear way: along with poems created within the framework of socialist canons there are also so-called peripheral works characterized by an increased position of the romantic worldview, a tendency towards lyricization and philosophization and the actualization of national, for example folklore, traditions. The article analyzes some of these poems (“Alsou”, “Confession of Love” by H. Taktash, “The Letter Bearer” by M. Jalil, “The oath” by H. Tufan, “Flutes”, “Steppe and Man” by A. Faizi, “Childhood of the Poet” by S. Hakim) and highlights key trends in the development of the genre.

**Keywords:** Tatar literature, Soviet literature, poem, genre, genre transformation.

1917 елгы вакыйгалар нәтиҗәсендә туган үзгәрешләр, әдәбиятны идеология коралы итеп карау, аның сәяси басымга дучар булуы милли сүз сәнгатенең гомуми барышын тамырдан үзгәртә. Күпгасырлык әдәби традицияләргә нигезләнеп үскән һәм XX йөз башында формалашып җитеп, кыска гына вакыт аралыгында татар сүз сәнгатенең яңарыш процессында әйдәп баручы жанрларның берсенә

әйләнгән татар поэмасы да яңа иҗтимагый-мәдәни вазгыять кысаларында үзгә үсеш сукмакларын барларга мәҗбүр була. «Инкыйлабка кадәрге мәдәниятнең «буржуаз» билгеләмәсе белән тамгалануы, әдәбиятның сыйнфыйлык һәм партиялелек принципларына нигезләнүе» [4: 146] сәбәпле, XX йөз башы татар әдәбиятында поэма жанрының формалашу һәм үсеш процессында әйдәп баручылардан булган Ф. Ибраһимов, Б. Мирзанов, Г. Сөнгати кебек шагыйрьләрнең модернистик юнәлешле әсәрләре онытылуга дучар ителә, Ф. Бурнаш, Н. Исәнбәт, М. Гафури һ. б. әдипләр исә иҗат мәсләген үзгәртергә мәҗбүр була.

Яңа вазгыятьнең беренче елларында поэма жанрындагы үзгәрешләр, нигездә, аңа кадәр формалашкан жанр-стиль хасиятләреннән артык читкә чыкмыйча, эчтәлеккә идеологик мотив кертеп җибәрү рәвешендә барса (мәсәлән, Ф. Бурнашның инкыйлабтан соң берничә елда язылган күпсанлы поэмалары моңа мисал була ала), 1920 елларның урталарында инде чор таләп иткән публицистик-патетик рухлы поэмалар беренче планга чыга.

Идеологик кануннарга буйсыну, әдәби традицияләрдән баш тарту, миллилектән ваз кичү кебек сыйфатлар, әлбәттә, жанрның эчтәлек һәм сәнгатьчә эшләнешендә нык чагыла: аларда социализмга дан җырлау, киләчәккә өмет, сыйнфый дошманга нәфрәт һ. б. мотивлар өстенлек итә. Шул ук вакытта, бу чор сүз сәнгатенә тулаем хас булганча, татар лиро-эпикасында да рәсми сүз сәнгатенә параллель рәвештә соцреализм кысаларын читләтеп үтәргә омтылып иҗат ителгән әдәби үрнәкләр күренә башлый. Бу исә, үз чиратында, тарихи-революцион тематикадан баш тартып, романтик эчтәлеккә һәм лиризмга йөз белән борылу, милли әдәби һәм фольклор традицияләрен яңарту, ил, халык һәм яшәеш турындагы фәлсәфи уйлануларга урын бирү рәвешендә чагылыш таба. Мәсәлән, «1920 еллар татар шигъриятендә шигырь төзелеше, поэтика өлкәсендәге эзләнүләрнең нигезен салган» [5: 167] Һ. Такташ поэмаларына 1920 елларның урталарында ук инде матурлык эзләү темасы килеп керә. Әйтик, шушы дулкында иҗат ителгән «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927) әсәрендә сюжет катламын барлыкка китергән Зөбәйдә һәм Мәхмүтнең сөю тарихы романтик эчтәлекле лирик чигенешләр белән тыгыз үрелеп килә. Поэманың лирик тармагын барлыкка китергән бу өзекләр яшьлек (Яшьлек, / Гомрең кыска синең, / Шундый кыска булып тоела, / Кичен чәчәк аткан була, / Ә таңында инде коела... [6: 186]), мәхәббәт (Мәхәббәт / Ул – үзе иске нәрсә, / Ләкин / Һәрбер йөрәк аны яңарта, / Тиле яшьлек ярты гомрен бирә / Аның хисе белән янарга... [6: 186] һәм акыл (Тәүбә иттем ул эшләрдән, / Азгын күңел күпкә басылды, / Ирке чикләнмәгән йөрәгемә / Башлык итеп куйдым гакылны [6: 186], ана булу (Ана – / Бөек исем, / Нәрсә җитә ана булуга! / Хатыннарның бөтен матурлыгы, / Бөтен күрке ана булуда... [6: 186] гүзәллеге хакында татар укучысы әлегә кадәр яттан сөйләп килгән тирән мәгънәле, тыгыз фикерле фәлсәфи сөземтәләр рәвешен ала. Яшьлек

елларының тиз үтүчәнлеген искәрткән рефрен строфалар, кабатлана-тирәнәя килеп, гомумән, вакыт агышы, яшәештә һәр нәрсәнең чиге булуы турындагы уйлануларга җирлек әзерли. Гомумән, «тиз уза торган яшьлек, гүзәл мәхәббәт, тормышка җиңел карау, ялгызлык, ятимлек темалары, үзара тоташып, катлаулы, симфоник табигатьле структура барлыкка китерә» [10: 214].

Шул рәвешле, әлеге чорда күпчелек поэмаларда хөкем сөргән революцион һәм публицистик пафослылыктан читкә китеп, бу әсәрендә Һ. Такташ төп героиняның күңел кичерешләрен һәм хикәяләүче-авторның лирик монологларын үз эченә алган лирик башлангычны беренче планга чыгара. Совет әдәбиятының шушы дәверендә кануни булган иҗат принципларыннан – геройларның социаль портретларын җентекләп торгызудан, иҗтимагый мәнфәгатьләрнең шәхси омтылышлардан өстенрәк булуын раслаудан, конфликт ясалмалылыгыннан, яңа җәмгыять идеалларына туры килмәгән геройларны кискен тәнкыйтьләүдән баш тартып, шагыйрь бөтен игътибарын Зөбәйдәнең рухи кичерешләренә юнәлдерә, өзелеп ярату, ышанган кешесенең хыянәтеннән газаплану, ана булу бәхете һәм шуңа бәйле үзгә бер сабырлык, тынычлыкка ирешү кебек хисләр дулкынында тибрәлгән гап-гади кызның күңел дөньясын бу чор әдәбиятында үзәктә торган бөек төзелеш, көрәш идеяләре белән бер югарылыкка күтәрә.

Һ. Такташның «Алсу» (1929) әсәре да чор поэмаларында өстенлек алган эпиклаштыру тенденциясеннән читтә тора: поэма үзегендә – автор тарафыннан «поэтик идеальләштерелгән, мәрхәмәтлелек һәм гармония нуры белән өртелгән» [2: 51] яшь кыз – гүзәл яшьлекнең үзе кебек күзалланган Алсу образы. Әсәрнең беренче карашка таркау тоелган лирик сюжетын рефрен юлларда кабатланган портрет тексты бер үзәккә җыя: Үзе матур, / Үзе сөйкемле, / Үзе усал, / Үзе болай бер дә / Усал түгел кебек шикелле... [6: 247]. Алсу образы совет чынбарлыгы белән генә чикләнмәгән, бәлки үзенең рухи дөньясы, эмоциональ-психологик кичерешләре, яшьлеккә хас ихласлыгы, гамьсезлеге белән теләсә кайсы чор укучысына таныш, якын образ буларак кабул ителә – әсәрнең, вакыт чикләрен үтеп, классик әдәби ядкәрләрнең берсенә әверелү сере дә әнә шунда.

Шул рәвешле, Һ. Такташ иҗатында совет чоры татар поэмасын идеологик кысалардан чыгару лириклаштыру, классик романтизм принципларын яңарту, мәңгелек темаларны фәлсәфи тирәнлектә ачу аша тормышка ашырыла, шагыйрьнең эчтәлек һәм форма өлкәсендәге эзләнүләре татар әдәбиятын югары кимәлдә иҗат ителгән лиро-эпик үрнәкләр белән баета.

1930 еллар шигъриятенең идеологик киртәләрне читләтеп үтәргә омтылышының тагын бер чагылышы – милли традицияләрне яңарту. Нигездә, бу – фольклор мотивларына мөрәҗәгать итү рәвешендә бара. Лирикада – Х. Туфан, Ә. Ерикәй, Ә. Фәйзи, М. Җәлил һ. б. иҗатында аеруча киң чагылыш тапкан әлеге үзенчәлек лиро-эпик әдәбиятка да сыйфат үзгәрешләре алып килә. Ш. Маннурның «Чиккән сөлге»

(1928), «Безнең авыл егете» (1941), М. Җәлилнең «Хат ташучы» (1938) кебек поэмалары – шуның ачык мисалы. Әйтик, һәркемгә таныш «Хат ташучы» поэмасында совет чоры әсәрләренә тулаем хас идеологик сызык (яшь белгечләрнең көндәлек хезмәте, социалистик төзелешкә керткән өлешен тасвирлаган сюжет линиясе) төп геройларның мәхәббәт тарихы белән тыгыз үрелеп-керешеп китә. Һәм әйтергә кирәк, романтик канат әсәрнең иң зур уңышы булып чыга да: совет чынбарлыгының схематик сурәте, шаблон вакыйгалар каһарманнарның бай күңел кичерешләре фонында бөтенләй тоныкланып кала.

Поэманың күп өлешен җыр текстлары алып тора. Татар халкының күпчелеккә мәгълүм җырларын яңарту һәм текстның шактый зур катламын халык җырлары тибында стильләштерү әсәрне үзенә хас бер көй-аһәң, музыкальлек белән баета.

Шул рәвешле, гашыйк яшьләрнең хисләрен ачып бирүгә буйсындырылган күпләгән сурәтләү чаралары, поэтик образлылык, күпсанлы эчке монологлар һәм җыр текстлары әсәр романтикасын көчәйтә, лириклаштыру тенденциясен нигезли. Кайнап торган яшәеш-хәят авазы буларак укылган күптавышлылык нинди генә иҗтимагый-сәяси вазгыятьтә, тарихның кайсы гына борылмаларында да яшәүнең дәвам итүе, кешелекне матурлыкка сизгерлек, сөйгән ярны, илне, тормышны ярату саклап калачагы турында уйландыра. Хикәяләүче-автор тавышы әнә шушы хакыйкатьне ассызыклап-раслап куя: Таң йолдызы төсле, яшьлек белән / Бергә туа сөю тойгысы. / Тормышыңа синең җан бирә ул, / Син үзең дә аны тоймыйсың. / Мин әйтәлмим: «Яшьлек үтте», – диеп, / Мин әйтәлмим: «Сөю бетте», – дип. / Бу йөрәктә сүнмәс ялкын калды, / Аны яшьлек шулай итте бит! [3: 199].

XX йөз башы татар лиро-эпикасында барган эчтәлек һәм форма өлкәсендәге эзләнүләр, модернистик тәҗрибәләр инкыйлабтан соң киселеп-югалып калса да, иҗат иреге кысылып, язучы-шагыйрьләр ясалма бер схемага нигезләнгән, бик чикләнгән эчтәлекле әсәрләр иҗат итәргә мәҗбүр булса да, совет әдәбияты берьяклы әсәрләрдән генә гыйбарәт, әдәби экспериментлардан азат дип әйтү, әлбәттә, дөреслеккә хилафлык китерү булыр иде. Рәсми идеологиягә буйсынган әсәрләр янәшәсендә күпкатламлы текст рәвешендә иҗат ителгән, хакыйкатьне яшерен эчтәлек аша ачып биргән үрнәкләр дә урын ала. Еш кына мондый «кысадан чыккан» әсәрләр җәмгыятьтә зур резонанс тудыра һәм, кагыйдә буларак, иҗат әһелен фаҗигалы язмышка дучар итә. Х. Туфанның «Ант» (1933) поэмасы – шуның мисалы. 1920 елларда әле революцион идеяләргә хилафлык китермәстәй лиро-эпик әсәрләр («Татарстанда», 1925; «Еллар итәгендә», 1925 һ. б.) иҗат иткән шагыйрь бу әсәрендә инде, идеологик нигезгә утыртылган дөнья сурәтеннән ваз кичеп, совет чынбарлыгының чын йөзен ачып бирә, мәңгелек кыйммәтләр турында уйлану юлына чыга.

Поэмада яктыртылган тарихи вакыйгалар яшерен эчтәлек белән тулыландырылып, коммунистик җәмгыятьнең асылын ачып бирә, катлаулы интертекстуаль бәйләнешләр исә тирән фәлсәфи

гомумиләштерүләр ясау мөмкинлеге тудыра. Мәсәлән, яшәешнең асылына төшенергә тырышып та, үзләренең көчсезлеген аңлаган Хәйям һәм Әбүгалисина кебек атаклы акыл ияләрен шушы яшәешне үзгәртергә тырышкан Маркс, Ленин кебек шәхесләр белән чагыштыру коммунистик идеологиянең коры сүз, буш патетика икәнен аңларга мөмкинлек бирә. Җәмгыятьне капма-каршы ике сыйныфка бүлү, «уңнар» һәм «суллар» тартышы да, автор раславынча, уйлап чыгарылган нәрсәдән гайре башка бер әйбер түгел. Әсәрдәге сүз сөрешеннән аңлашылганча, махсус тудырылган мондый каршылык яшәешнең гомуми кануннарына, катгый кысаларда яшәтү мөмкин булмаган кеше табигатенә һич сыеша алмый: Кайберәүләрдә хәзер ике мин бар, / Дигән идең, Такташ, / Тиң моңар: / «Кайберәүләрдә хәзер өчәү ул», – дип, / Бер искәрмә кертик без, туган... [7: 139].

Поэманың эчтәлеге күпсанлы ассоциатив-символик образлар аша тыгызланып, интеллектуаль укучыга аталган мәгънә катламнары күбәя, тирәнәя бара. Яшәеш караңгылыгын, чор фаҗигасын ачкан төн образы аша автор тоталитар системаның беркемне дә аямаячагын раслап бирсә (…Шул, үзенең / Озын хезмәтен үтәп, / Кемгә – мунча, / Кемгә – төрмә, – төн үтә... [7: 149]), Домна бабай авызыннан яңгыратылган әкият тексты – Нинин батыр турындагы бәян аша коммунистларның властька килүләренә һәм Гражданнар сугышына мөнәсәбәтен җиткерә (Ничек Нинин / Һәм җиде егет килеп, / Унҗиде мең ярлыга / Кылыч бирер... / «Ничек итеп / Унҗиде мең янарал / Унҗиде мең ярлыга / Сугыш ачар... [7: 148–149]), кояш, кобра, «кара мыек» образлары исә совет әдәбиятында Ф. Ницшеның «гадәттән тыш кеше» турындагы теориясенә туры килердәй итеп сурәтләнгән Сталин турындагы мифны җимерүгә хезмәт итә: Син ренегат, / Безгә таныш елан: / Безнең олы юлбашчыбызның / Шалашында яттың, өмет итеп / Буарга җай булмасмылыкны... / Син ренегат, / Күптән таныш кобра: / Тәүбә итеп ничә йөз тапкыр / ЦИКа тирәсендә шуыштың син... / Һәм ахырда / Кировны чактың... [7: 152].

Аерым лирик чигенешләрдә турыдан-туры татар халкының фаҗигалы язмышы турындагы сызлану үзәккә чыга. Үзен ата-бабалар хәтерен саклаучы дип таныган лирик субъект (Йөрәгемдә ята / Мең бабамның / Миллион еллык шатлык һәм зары... [7: 14]) милләтнең гасырлар буе изелеп яшәргә мәҗбүр булуын ассызыклый (Гүргә кереп яткан / Минем бабай, / Үз токымына / Мирас калдырып... / Ә мирасы... / Йөз гасырлык сагыш, / Буын-буын изелү кайгысы... [7: 141]). Текстка кертелгән җыр өзекләре дә татар халкының рухи һәм сәяси ирексезлектән туган бәхетсезлеге турында: Көн кояшлы, төн айлы да, / Бәхтем кара булган ла дип; / Богау алтын булса да шул, / Богау инде богаула дип... [7: 142].

Сәяси вазгыять һәм аның турыдан-туры шәхес һәм милләт язмышына йогынтысы хакында фикерләү яшәешнең экзистенциаль асылы турындагы фәлсәфи уйлануларга кадәр үстерелә. Икенче бүлеккә эпиграф итеп сайланган Сталин сүзләре дә шуңа ишарә итә:

...Дөнья борын-борыннан шулай төзелеп килде... [7: 140]. Юлбашчының сәяси чыгышыннан «өзеп» алынган бу гыйбарә тарихның кабатлануы, системаның һәрвакыт шәхеснең ирегән буу хисабына ныгуы хакында искәртү кебек укыла, гомумән, бәхетле җәмгыять төзү идеясенең тормышка ашмаслыгын тоемлау, язмыш каршында көчсезлекне аңлау әсәрнең лейтмотивына әйләнә. Шул рәвешле, текстның катлаулы структурасы, күпсанлы интертекстуаль бәйләнешләр, төп иҗат принцибы итеп сайланган шартлылык, дәшми калу һәм әйтеп бетермәү кебек стилистик алымнар поэманың фәлсәфи куәтен тагын да көчәйтә, яңадан-яңа фикер катламнарын эзләргә этәрә.

Төп вакыйгаларга янәшә килгән яшерен эчтәлек катламы Ә. Фәйзи поэмаларының да характерлы сыйфаты булып тора. Әйтик, автор үзе билгеләгәнчә, «вак буржуаз романтизмын – революциянең героик көндәлегенә, төшенкелек флейталарын революциянең яшәү һәм җиңү гөрелтесенә алыштырган таза йөрәкле интеллигенциягә багышланган», лирик геройның эчке монологы рәвешендә иҗат ителгән «Флейталар» (1933) поэмасы инкыйлаб дулкыннарын аерым шәхеснең күңел тетрәнүләре, психологик халәт күчешләре аша ачып бирүе белән үзенчәлекле. Мәсәлән, әсәрнең беренче өлешендәге яңа, әлегә таныш булмаган яшәешне аңлый алмаудан гаҗизләнү, өметне һәм тормыш мәгънәсен югалту мотивлары поэманың башламын экзистенциаль укылышка көйли: Яшьлегемне, дуслар, яшьлегемне, / Яшьлегемне җуйдым! / Минем өстән узды – яшьлек түгел, / Явар-яумас болыт. / Ә мин калдым кырда ялгыз... Чакрым / Баганасы булып. / Мин югалттым яшәү мәгънәсен – / Шушы көе, ялгыз... [9: 98]. Бу сызланулы халәт үстерелә килеп, яшь геройның революцион көрәштә абыйсы һәлак булуы турында хәбәр иткән хат алуы мизгелендә үзенең иң югары ноктасына җитә. Патетик эчтәлекле әлеге хатта якты киләчәк өчен җаныңны корбан итү, ил, халык өчен яшәү идеясе калка, яшь буынны да шуңа өндәү үзәктә тора. Хатны укыганнан соң, экзистенциаль халәт яшәү мәгънәсен аңлау, үз максатыңны билгеләү белән алмашына – бу күчеш поэмада яңадан туу мотивы аша җиткерелә (герой «Мин яңадан тудым» дип игълан итә), егетнең психологик кичерешләре дә капма-каршыга үзгәрә: Мин яшисем килә, моңа хәтле / Һич килмәгән кебек! / Мин шат... Бүген үкенеч игәве / Йөрәгемне кырмый. / Мин шат... Бүген үлүемне түгел, / Тууымны җырлыйм [9: 102].

Поэманың фәлсәфи катламында үзәктә торган яшәү мәгънәсе турындагы уйланулар, күренгәнчә, идеологик яссылыкта карала, үзең өчен гомер итүнең дөрес түгеллеге кире каккысыз хакыйкать итеп таныла (Мин – тилелек даһие – ертышканмын / Үз яшьлегемне яклап.../ Болай булгач, мин кем?.. Яңа нәсел / Эчендә мин – тутык... / Мин – ятышсыз чорга..., [9: 101]), ялгызлык, читләшү мотивлары шәхеснең үзен җәмгыятьнең, тарихи барышның бер өлеше итеп каравы белән алышына: Яраларны мин яшермим, дуслар. / Яшерәсем килми... / Авыруын яшергән үлә, диләр, / Мин үләсем

килми... / Мин бәйлисем килә сезнең белән / Калган гомерем җебен [9: 101].

Динамикада бирелгән эмоциональ күчешләр һәрвакыт флейта көе белән үрелеп бара: геройның психологик кичерешләренә бәйле, флейталар нидер сагынып көйли, иңри, нервылана, кабалана һәм, ахыр чиктә, тына: Флейталар иңрәп тына, узган / Гомер кебек чыңлап... / Алар тына, минем даулы йөрәгем / Симфониясен тыңлап... [9: 108]. Шул рәвешле, флейта көе тормыш мәгънәсен, үз асылыңны эзләү, яшәүнең чиклелеге, инкыйлабның кеше күңелендәге гамьне юкка чыгаруы кебек фәлсәфи мотивларны бер төенгә туплаган катлаулы образга әйләнә.

«Дала һәм кеше» (1936) поэмасында да җәмгыятьтәге үзгәрешләрне символик яссылыкта аңлату, яшерен катламнар аша хакыйкатькә ишарә итү күзәтелә. Әсәрнең төп вакыйгалар катламын барлыкка китергән кәрван юлы турында хикәяләү өлешен яшәеш кануннары хакында уйланулар белән бәйле лирик-фәлсәфи катлам тулыландырып килә, һәм поэманың үзәгендә торган вакыйгалар символик яссылыкта кабул ителә башлый. Шул рәвешле, кәрван – җәмгыять булып аңлашыла, ә юлчыларны коры далада көткән кыенлыклар кешелекне сагалаган авырлыкларга ишарә кебек укыла, дала исә сынау тулы яшәешнең үзе рәвешендә аңлана: Ком даласы. Эссе. Борчый торган / Бимазалы тынлык. / Ат һәм кешенең һәр адымыннан / Ясак сорый комлык [8: 278]. Кешелекнең бару юлы җиңел түгел, аны һәрвакыт сынау сагалый, хәят корбан сорый, һәм бу мәңге шулай булган – әсәрдәге фәлсәфи катлам әнә шушы идеяне үзәккә куя: Үз өстендә дала мең-мең еллар / Күп кешеләр күргән. / Алар аңа я су түләгән, / Йә гомерен биргән [8: 279].

Идеологик контексттан азат булмаса да (текстта феодаль җәмгыятьнең камил булмавына кат-кат ишарәләү, текстның рәсми патетика рухында тәмамлануы һ. б. шуңа дәлил), поэманың төрлечә укыла-аңлана ала торган ачык текст буларак уйлануы, күпсанлы ассоциатив-шартлы мәгънә бәйләнешләре табылу аны соцреалистик кануннардан читләшкән, жанр үсешен һәм гомумән татар әдәбиятын баеткан үрнәкләр рәтендә карарга мөмкинлек бирә.

Яшәешнең асылын аңларга омтылу, чынбарлыкны идеологик булмаган чаралар ярдәмендә гәүдәләндерү мөмкинлекләрен эзләү – С. Хәкимнең Тукай образын үзәккә куеп язган поэмаларына да хас үзенчәлек. Аның «Пар ат» (1938–1939) поэмасы Тукай образын лиро-эпик жанрда ачкан беренче үрнәк булып тора. Лирик геройның шәхси кичерешләрен үзәккә куеп, эчтәлеге, нигездә, Тукайны данлау-патетика белән бәйле булган лирик әсәрләрдән аермалы буларак, С. Хәким әсәрендә поэманың жанр хасиятләре татарның бөек шагыйрен детальлерәк сурәтләргә, аның язмышын халык тарихы белән янәшәлектә ачарга мөмкинлек бирә. Тукайның үз иҗаты белән интертекстуаль бәйләнешләр исә шагыйрь иҗаты һәм үз чоры совет әдәбияты арасында параллельләр табарга ярдәм итә. Шул ук

вакытта әле автор идеологик кысалардан артык читкә дә китә алмый: ул, чор таләп иткәнчә, Тукай иҗатының халыкчанлыгына һәм иҗтимагый әһәмиятенә ыграк игътибар бирә, аны «халык җырчысы» дип атый, ярлылар мәнфәгатен кайгыртучы буларак ача (Йөрәгенә җыеп ярлыларның / Аһ-зарларын, сагыш-моңнарын, / Пар атында шагыйрь уйлап барган / Алар турындагы җырларын [11: 146]), яңа социалистик җәмгыятькә дан җырлау, иске һәм яңа тормышны каршы кую кебек мотивларны киң чагылдыра. Шул ук вакытта гаҗәеп җылы эчтәлекле лирик тасвирлар әсәрнең поэтик куәтен арттыра. Лирик геройның туган ягының җанга якын сурәтләре, аның сагышлы җирсү хисе, әнисе белән җылы әңгәмәләре, гамьсез балачак хатирәләре – болар һәм авторның үзенә мөнәсәбәтлелеге анык тәгаенләнгән башка шундый сентименталь тезмәләр Тукай язмышы белән гаҗәеп тыгыз бәйләнеп-үрелеп киләләр, рәсми схематиклыкның тоныкланып калуына ярдәм итәләр.

Шул рәвешле, 1930 елларда бер төркем әдипләр, мәҗбүри тагылган иҗат принципларыннан читкә китү омтылышы белән, татар поэмасы үсешендә яңа тенденцияләргә нигез салалар. Жанр яңарышы лириклаштыру, милли традицияләргә мөрәҗәгать итү, текстны мәгънә катламнары, шартлылык, киная һ. б. алымнар ярдәмендә катлауландыру кебек юнәлешләрдә бара. Бу эзләнүләр жанр поэтикасында да чагылыш таба: 1920 еллар лиро-эпикасында әйдәп барган публицистик пафос, агитация рухы һәм риторика салмак интонация белән алмашына, авангард эзләнүләр сирәгәеп, традицион шигырь формасына өстенлек бирелә башлый.

### Әдәбият


1. *Галимуллин Ф.Г.* Эстетика һәм социологизм: 20–30 нчы еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәте. Казан: Мәгариф, 1998. 223 б.

2. *Галиуллин Т.Н.* Роль Такташа в становлении социалистического реализма в татарской поэзии // Хади Такташ – певец эпохи: (Материалы науч. конф.). Казань, 1982. С. 47–52.

3. *Җәлил М.* Әсәрләр: 5 томда. 3 т.: шигырьләр, поэмалар, тәрҗемәләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 368 б.

4. *Загидуллина Д.Ф.* Модернизм в татарской литературе первой трети XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 307 с.

5. *Ибрагимов М.И.* Творчество Х. Такташа в контексте татарской и русской поэзии 1910–1920-х гг.: проблемы поэтики // Научный Татарстан. 2011. № 1. С. 164–172.

6. *Такташ Һ.* Әсәрләр: 3 томда. 1 т.: шигырьләр һәм поэмалар. Төзәт. һәм тулыл. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 367 б.

7. *Туфан Х.* Әсәрләр: 5 томда. 1 т.: шигырьләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 479 б.

8. *Фәйзи Ә.* Флейталар: шигырьләр, җырлар, поэмалар, балладалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 320 б.

9. *Фәйзи Ә.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 431 б.

10. *Хәбетдинова М.М.* Һ. Такташ иҗатында табигать // Һ. Такташ: тәрҗәмәи хәле, истәлекләр, әсәрләр, анализ үрнәкләре, дәрес эшкәртмәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. Б. 220–224.

11. *Хәким С.* Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 2 т. 328 б.

***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Надыршина Лейсан Радифовна,***
*доктор филологических наук, старший научный сотрудник Центра письменного наследия Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*leysan_tatar@mail.ru*

УДК 82-1(=512.145)

***Ф.И. Габидуллина***

# СУГЫШТАН СОҢГЫ ЕЛЛАР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ГЕРОЙ КОНЦЕПЦИЯСЕ ЧАГЫЛЫШЫ

В статье исследуется тема войны и отражение концепции героя в татарской литературе послевоенных лет. Произведения Г. Абсалямова, Г. Баширова, М. Амира, Н. Давли, А. Еники анализируются в аспекте создания героев, в которых ярко выражены черты идеального героя поствоенной литературы. Исходя из характера национального героя и определяется их новизна для своего времени. В произведениях послевоенных лет типы литературных героев выделяются такими качествами, как мужественность, надежность, честь, чистота души. Определение характеров, верных национальным традициям, нравственным ценностям, способствует выявлению закономерностей идейно-эстетического развития татарской литературы данного периода.

**Ключевые слова:** татарская литература, военная тематика, концепция героя, нравственные ценности, художественное своеобразие.

The article explores the theme of war and the reflection of the concept of the hero in the Tatar literature of the post-war years. The works of G. Absalyamov, G. Bashirov, M. Amir, N. Davli, A. Eniki are analyzed in the aspect of creating characters in which the features of the Tatar mentality are clearly expressed. Based on the character of the national hero, their novelty for their time is determined. In the works of the post-war years, the types of literary heroes are distinguished by such qualities as masculinity, reliability, honor, and purity of soul. The identification of characters faithful to national traditions and moral values helps to identify patterns of ideological and aesthetic development of Tatar literature of this period.

**Keywords:** Tatar literature, military themes, the concept of a hero, moral values, artistic originality.

Сугыштан соңгы еллардагы татар әдәбиятының үсеше ил-халык тормышыннан, иҗтимагый-мәдәни хәрәкәттән аерылгысыз була. Ә ул исә гаять катлаулы һәм каршылыклы булып кала. ВКП(б) ҮК ның 1944 ел 9 август карары нәтиҗәсендә татар халкының Урта гасырлар тарихын өйрәнүгә киртә салына. Алтын Урда чоры әдәбияты, шул исәптән «Идегәй» дастаны әдәби хәрәкәттән алына. Шундый шартларда татар әдәбиятына идеологик басым көчәя. Аның бер чагылышы буларак, татар әдәбияты дәреслекләре тәнкыйтькә дучар була, цензура тагын да көчәя. 1946 елда «Ленинград» һәм «Звезда» журналлары хакында партиянең махсус карары чыга. Шуларга бәйле А. Ахматова һәм М. Зощенко иҗаты тәнкыйть итеlә һәм байтак вакытка әдәби хәрәкәттән төшереп калдырыла. Бу күренеш милли әдәбиятларга да тискәре йогынты ясый.

Иҗтимагый-мәдәни тормыштагы авырлыкларга карамастан, татар әдәбияты үсеш-үзгәрешен туктатмый. 1940 елларның икенче яртысы һәм 1950 елларга күз салсак, анда мәдәни хәрәкәтнең

җанлануына китергән байтак уңай күренешләргә тап булабыз. Билгеле инде, сугышта җиңүгә бәйле күтәренкелек әдәбиятта да чагылыш таба. Фронт ялкыны аша үтеп кайткан тәҗрибәле әдипләр актив иҗатка тартылу белән бергә, яшь авторлар да әдәбиятка күп килә. Сугыш елларында җыелып, тупланып килгән бай материалга нигезләнеп, зур күләмле, киң колачлы әсәрләр языла башлый. Г. Бәшировның «Намус», К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романнары 1951 елда икенче дәрәҗәдәге Сталин премиясенә лаек була һәм ил күләмендә яңгыраш ала, күп телләргә тәрҗемә ителә. 1953 елны «Правда» газетасында М. Җәлил шигырьләре басыла һәм татар шагыйренең ил буйлап данлы исеме тарала, иҗаты халыкка кайта. М. Җәлил әсәрләренең дөньякүләм танылуы татар әдәбиятына игътибарны арттыра һәм үсешенә этәргеч бирә. Бу елларда репрессияләнгән әдипләрнең (Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Ш. Усманов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Х. Туфан, С. Рәфыйков һ. б.) иҗаты кайту да татар әдәбиятына җанлану алып килә. 1950, 1954 елларда Татарстан язучыларының II һәм III съездлары була. Бу чорда сугыш вакытында туктап торган газета-журналларның бер өлеше кабат чыга башлый. 1950 елдан «Яшь сталинчы» (1956 елда «Татарстан яшьләре» дип үзгәртелә), 1951 елдан «Чаян» һәм «Пионер» журналлары (соңгысы 1957 елдан – «Ялкын») укучыларга килеп ирешә. 1957 елны Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре үтә. Шулар белән рухланып һәм әдәбият-сәнгатьнең халык тормышындагы ролен аңлап, 1958 елны ТАССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе булдырыла. Беренче премия «Тукай» романы өчен Ә. Фәйзигә бирелә.

Татар әдәбияты яшәештәге каршылыкларны шомартып сурәтләүне күздә тоткан «конфликтсызлык теориясе» һәм башка күптөрле кыенлыклар аша үтеп, акрынлап җанлана, сан һәм сыйфат үзгәрешләренә нигез әзерли. Бу еллар сүз сәнгатендә хезмәт темасы һәм хезмәт ияләрен әхлакый тәрбияләү мәсьәләсе дә үзәктә тора. Шулар янәшәсендә сугыш темасы, халыкның фронттагы һәм тылдагы батырлыгын, аның нигезләрен эзләү, ачу гаять актуаль булып кала. «Чор әдәбиятындагы иң олы тема – сугыш темасы: ул барлык жанрларда да дәвам итә, – дип яза Д. Заһидуллина. – Тылдагы батыр хезмәтне, хатын-кызларның, яшьләрнең җиңү өчен көч салуын тасвирлаган әсәрләр дан казана» [6: 12]. Шуңа да әлеге еллар татар әдәбиятында Г. Әпсәләмовның «Ак төннәр» (1946), «Мәңгелек кеше» (1960), «Газинур», «Алтын йолдыз», Г. Бәшировның «Намус» (1948), М. Әмирнең «Саф күңел» (1953–1959), Ә. Еникинең «Кем җырлады?» (1956) һ. б. роман-хикәяләр киң яңгыраш таба. Үз вакытында гаять популяр булган әсәрләрне без герой концепциясе чагылышы ноктасыннан тикшерүне максат итәбез. Ул исә авторларның иҗат принципларын, әсәрләрнең идея-эчтәлеген, геройлар характерын ачу максатында авторлар файдаланган алым-чараларны билгеләү кебек сорауларны алга куя.

Сугыштан соңгы елларда дөнья күргән проза әсәрләре шактый тулы өйрәнелгән, аерым алганда, үз вакытында Г. Бәширов [3],

М. Әмир [2] кебек әдипләр каләмдәшләренең иҗатына игътибарлы булып, чор үзенчәлеге, иҗат принциплары, сәнгатьчә эзләнүләр турында фикерләре белән уртаклашалар. Рус телендәге матбугат та татар әдәбиятына игътибарлы була. «Новый мир» журналында И. Арамилев Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романына югары бәя биреп, авторның романтик фикерләү үзенчәлекләрен ача, аерым йомшак якларын да күрсәтеп үтә [1]. И. Нуруллин [12], Х. Хәйри [13], Ф. Мусин [11], Г. Халит [14], бераз соңрак Ф. Миңнуллин [9], Ф. Галимуллин [5], безнең көннәрдә Д. Заһидуллина [6], А. Кашапова [7] һ. б. хезмәтләрендә сугыш темасының татар әдәбиятында чагылыш этаплары, аерым сыйфатлары, табышлар һәм югалтулар билгеләнә. Шуның белән бергә, әлеге әсәрләргә милли характер чагылышы ягыннан якын килү чор әдәби процессы үзенчәлекләрен, авторларның сәнгати эзләнүләрендәге уртак һәм аермалы якларны тулырак ачу мөмкинлеге бирә.

Сугыштан соңгы елларда сугышка бәйле вакыйгалар һич тә бертөрле генә сурәтләнми. Бу, билгеле, язучының фронт хәлләрен яисә тылдагы тормышны чагылдыруына, авторның әлеге хәлләргә шәхси карашы, алга куйган максаты, сайлап алган иҗат юнәлеше һәм сәнгати фикерләү үзенчәлеге белән бәйле була. Бу чорда герой төшенчәсе, аның әдәби әсәрдә чагылышы гаять җитди мәсьәләгә әверелә. Сугыш чоры вакыйгаларын сурәтләгән әсәрләрдә дә ул үзәктә булып, әдипләр үзләренә хас сәнгатьчә фикерләү аша шуңа җавап эзлиләр.

Татар әдәбияты халыкның яшәү рәвешен, иң матур сыйфатларын, гореф-гадәтләрен һәм традицияләрен чагылдыра. Милли тормыш кыйммәтләре буларак, алар геройларның эш-гамәлендә, характер сыйфатларында аеруча тулы ачыла. Бу очракта язучы теге яисә бу милләтнең асылын билгели торган үзенчәлекләрне калкытып куя, башкалардан аерырга мөмкинлек биргән билгеләрне алга чыгара. Д.С. Лихачев язганча, милли һәм гомумкешелек сыйфатлары аша ныклы кабатланмас бергәлек оеша [8: 40]. Сугыш шартларында кешенең эчке потенциалы бер үзәккә туплана, ул психологик киеренкелектә яши, шуңа бәйле милли характер үзенчәлекләре дә тулы һәм ачык чагыла.

Бу чорда Г. Әпсәләмов сугыш турындагы әсәрләре белән аеруча киң танылу ала. Язучы «беренче әсәрләрендә игътибарын сугышчының тиңдәшсез батырлыгын сурәтләүгә юнәлдергән булса, соңрак язылган романнарында күбрәк шул батырлыкның чыганаклары белән кызыксына, фикерләүдәге үзгәрешләр, сугышның асыл кыйммәтләрне үзгәртүе, вакытлы, узгынчы ихтыяҗлардан арындыруы турында сөйли» [4: 71]. Әдипнең «Ак төннәр» җыентыгына туплап бирелгән хикәяләрен батырлыкка соклану хисе берләштерә. Аларда без аерым сыйфатлары калкытып куелган геройлар белән очрашабыз, бу әдипнең яңа герой эзләве буларак кабул ителә. Ә инде «Алтын йолдыз» (1948) романында автор көчле кеше концепциясен тормышка ашыра. Әллә ничә буын укучыларның өстәл китабына әйләнгән әсәр бүген дә яратып укыла, кабатланмас романтик рухлы геройлары белән җәлеп

итә. «Алтын йолдыз» – иң югары батырлык, гадәттән тыш кыюлык өчен бирелә торган бүләк. Романның беренче бүлегендәге вакыйгаларда мәктәп укучылары шул исемдәге спектакльдә уйныйлар. Спектакль героеның батырлыгы күбесенең тормыш юлында маяк булып тора. Төп геройларның берсе булган Мөнирә үзләренең батырлыкка әзер булуын белдерә. Автор карашлары беренче чиратта Галим Урманов образында урын ала. Ул яшьлек хаталары аша чыныгып үсә һәм идеаллаштырылган герой дәрәҗәсенә күтәрелә. Эшче гаиләсендә үсүе, укытучылары, бергә укыган дуслары, фронтта исә ышанычлы командирлары ярдәмендә Галим җиңү өчен гомерен бирергә әзер көчле кеше булып җитлегә. Үз-үзенә ышанычы шундый зур булганга, автор аны үлемнән курыкмый торган совет кешесе, татар солдаты итеп сурәтли. М. Кашапова болай бәяли: «Галим акыл белән түгел, бәлки хис белән яши. Кечкенә генә йомшаклыгы өчен дә үзен тәнкыйтьли. Чын герой тапларсыз, йомшаклыкларсыз булырга тиеш кебек тоела аңа, ягъни ул хыялында идеал герой тудырып, шуңа охшарга тырыша» [7: 18]. Галим янәшәсендәге башка образлар – Ильяс Бикбулатов, Андрей Верещагин, Мөнирә Илдарская, Һаҗәр һ. б. – шундый ук сыйфатларга ия ил уллары һәм кызлары буларак сурәтләнә. Дөрес, автор геройларын гадәттән тыш сыйфатларда бирүе белән артыграк та мавыгып китә. Моңа үз вакытында И. Арамилев та игътибар итә һәм аның тормышчанлыкка зыян китерүен ассызыклый [1: 257].

Г. Әпсәләмовның «Газинур» (1951) романы, дошман амбразурасын күкрәге белән каплап, иптәшләренә юл ачкан татар егете Газинур Гафиятуллинга багышлана. Әсәрдә аның биографиясенә бәйле мотивлар публицистик аңлатма-сөйләүләр, кайбер документлар белән үрелеп, авторның киң әдәби сурәтләвендә ачыла. Шул рәвешле, үзенчәлекле синтез барлыкка килә. Герой характеры туган җир туфрагында үз халкының яшәү рәвешенә, әхлакый кыйммәтләре йогынтысына бәйле оеша – автор укучыга җиткерергә теләгән мөһим фикерләрнең берсе әнә шул. Газинур батырлыгы – аңлы рәвештә үлемгә бару чагылышы. Җиңү өчен, иптәшләрен коткару өчен бу адымга барганда кеше ниләр кичерә? Бу сорау бүген дә һәркемне дулкынландыра. Шуңа да автор алга куйган максатларның берсе – батырлык чыганагын, нигез сәбәпләрен эзләү. Әсәрдә Газинурның тормыш юлы күз алдыннан үткәрелә, ул үскән гаилә, абыйсы белән каршылыклы мөнәсәбәте, сөйгән кызына, аннары хатынына булган хисләре, авылдашлары белән аралашуы сурәтләнә. Эзлекле рәвештә аның дөньяга карашы формалашу, туган җиренә, якыннарына булган җылы хисләре ачыла. Нәкъ менә шулар, бер фокуска тупланып, кешенең иле-халкы алдында җаваплылык хисен тудыра, дип раслый Г. Әпсәләмов. Алдагы романдагы көчле кеше образын үстерә барып, автор татар улының батырлыкка бару юлын сурәтли.

Сугышның беренче елларында бик күпләр, әсирлеккә төшеп, концлагерьларда михнәт чигә, үлемгә дучар ителә. Бу мәхшәрдән исән калганнар, туган илендә «сатлыкҗан» исеме алып, төрмә-лагерьлар аша

үтәргә мәҗбүр була. Сугыш бетеп шактый вакытлар узгач кына, әсирлеккә төшкән кешеләрнең газаплар тулы тормышын сурәтләү мөмкинлеге туа. Әсирләр концлагерь шартларында да дошманга каршы көрәшүдән туктамаганнар. Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» (1957) повестенда, Г. Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» (1960) романында әнә шундый вакыйгалар торгызыла. Дөрес, «гаять катлаулы һәм каршылыклы бу дөньяны рәсми идеология белән бәйле рәвештә берьяклы бәяләү дәвам итә. Сугышның фаҗигалы, гаделсез, кешелексез яклары әле игътибардан читтә, күләгәдә калдырыла» [10: 37]. Әмма әлеге әсәрләр герой концепциясен ачу ягыннан җитди яңалык алып килә. Бу урында шуны да билгеләп үтик: тоткынлыкта көрәш юлы, формалары төрле булырга мөмкин. Н. Дәүли һәм Г. Әпсәләмов әсәрләре язылганда җәлилчеләрнең батырлыгы турында инде билгеле була. Исән калу өчен башта легионга язылып, аннары ул мөмкинлектән файдаланып, легионерлар күңеленә туган ил, җир кадерен һәм фашизмга каршы көрәшү идеясен салу юлларын табу һәм моңа ирешү – Гайнан Кормаш оешмасына кергән җәлилчеләрнең батырлыгы әнә шуннан гыйбарәт. Н. Дәүли һәм Г. Әпсәләмов әсәрләрендә исә һәрдаим дошман күзәтүе астында булып та, күңеленнән аңа баш имәгән, көрәшкә әзер әсирләр язмышы ачыла. Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» (1957) повестенда татар әдәбиятында беренчеләрдән буларак әсирлек язмышы сурәтләнә. Аның мөһим үзенчәлеге шунда ки: әдип автобиографик материалларга нигезләнә. Шул рәвешле, аның герое үз башыннан кичкән хәлләрне укучы күз алдына бастыра. Фашизмның ерткычлыгын ачуга да әсәрдә җитди урын бирелгән. Әсирлек газаплары җанлы картиналар рәвешен алып, чын мәгънәсендә тетрәндерә. Хикәяләүче образы әсәрдәге вакыйгаларны бергә туплый. Ул – татар кешесе һәм халкыбызга хас иң матур сыйфатлары белән ачыла. Әйе, концлагерь шартларында эш-гамәл белән батырлык күрсәтеп булмый. Әмма ул сыйфат геройның үз-үзен тотышында, дусларына ярдәм итүдә, иң кыен вакытларда ихтыяр көчен туплап, ялгыш адымнар ясаудан тукталуда һ. б. чагыла. Тоткынлык шартларында кешеләр сынала. Хикәяләүче татар егете характерының иң мөһим сыйфаты – рухи ныклык. Н. Дәүли туган җир кадере, якыннарның матур истәлеге кешегә әйтеп бетермәслек көч-егәр бирүен ача. Әлеге геройның милли характеры сабырлык-түземлектә, рухи иреген, җиңүгә ышанычын саклап калуда, янәшәдәгеләргә кулыннан килгәнчә ярдәм итүдә чагыла.

Г. Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» (1960) романы исә әсирлек газаплары кичергән кешеләр язмышына яңа штрихлар өсти. Әсәрдә Бухенвальд концлагеренда булган хәлләр реаль кешенең прототибы булган Бакый Назыймов образы аша ачыла. Бу яктан роман автобиографик, документаль һәм публицистик прозага хас билгеләрне үзенә ала. Автор төп иҗат принцибына тугры булып кала: чынбарлык күренешләрен романтик сурәтлелек, теләк-омтылыш, хыял чагылышы белән үреп бирә. Төп герой Бакый – совет офицеры, шуңа да ул гомумиләштерелгән герой, коммунист буларак күзаллана. Бу

яктан социалистик реализм иҗат методы таләп иткән сыйфатлары белән ачыла. Аның күңелендә дошманга нәфрәт белән бергә ватанын, туган җирен ярату, тугрылык хисләре урын алган. Автор Бакый Назыймовны көчле һәм ышанычлы характерлы кеше итеп сурәтләүгә килә. Кеше тоткынлык халәтен бик авыр кичерә. Концлагерьда яшерен оешма төзү һәм коралллы восстание әзерләүне күз алдына китерү дә авыр. Мондый шартларда нәкъ менә ышаныч казану әсиргә бирелгән иң зур бәя булып тора. Автор героеның татарлыгын, милли яшәеш шартларында үсүен һич тә онытмый. Аның истәлек-хатирәләрендә татар халкының иң матур сыйфатлары – хезмәт яратуы, өлкәннәрне хөрмәт итүе, ышанычлы, ярдәмчел, сабыр булуы ачылып, Бакыйның да аларны үзендә булдырырга омтылуы билгеле бер эзлеклелектә ачыла. Сугыш, бигрәк тә тоткынлык шартларында алар герой характерының үзәген тәшкил итәләр. Романның «Мәңгелек кеше» дип аталуы да нинди генә шартларда да кеше булып калуны һәм инсанның чын асылын билгеләгән гомумкешелек сыйфатларының мәңгелек булуына ишарәли.

Сугыштан соңгы елларда татар әдәбиятында фронт һәм тыл бердәмлеген сурәтләү даими игътибар үзәгендә була. Прозада аеруча киң яңгыраш алган әсәрләрнең берсе – Г. Бәшировның «Намус» романы (1948). Иҗтимагый-социаль эчтәлекле әсәрдә илгә, халыкка бирелгәнлек намуслы хезмәт, рухи ныклык аша сынала, дигән идея үткәрелә. Автор фронт һәм тыл бердәмлеге, хезмәткә, гомумән яшәешкә намуслы караш, туган илгә бирелгәнлек кебек мәсьәләләрне гаять тормышчан һәм җанлы картиналарда чагылдыра. Вакыйгаларда Нәфисә бригадасының мул уңыш үстерү өчен көрәше сурәтләнеп, аңа авыл кешеләренең яшәү рәвеше, күрше колхозлар, район тормышы, Сталинград сугышы фаҗигалары һ. б. килеп кушыла. Алар сугыш чорының тулы панорамасын күз алдына бастыра. Роман идеологик принципларга нигезләнеп язылса да, үзенең милли характерлы геройлары белән аерылып тора. Үз чорына хас әдәби тип буларак тасвирланган Нәфисә – чын мәгънәсендә татар хатын-кызының иң матур сыйфатларын үзенә туплаган образ. Аның сабырлыгы, тыйнаклыгы, ярдәмчеллеге, тормыш сынаулары каршында каушап калмыйча, башкаларны үз артыннан ияртерлек оештыру сәләтен ачуга нигез булып тора. Фронт шартларындагы геройлардан аермалы буларак, Нәфисә образында хатын-кыз йомшаклыгы белән көчле, намуслы герой табыла. Ул көчсезлегендә дә, хис һәм акыл көрәшендә буталып бетүендә дә татар хатыны булып кала: сынаулар аша үтеп, намусына хыянәт итмичә, кешелек сыйфатларын саклап яши. Нәфисәгә хас матур сыйфатларның нигезе ата-ана тәрбиясендә, матур гореф-гадәтләрдә, халкыбызның милли үзенчәлекләрендә булуы кат-кат искәртелә. Шуңа да Нәфисә халыкның фронттагы һәм тылдагы фидакярлеген, батырлыгын, көчле патриотик хисләрен чагылдырган образ булып калка.

Фронт һәм тыл бердәмлеге мәсьәләсен үзәккә куеп иҗат ителгән әсәрләр арасында М. Әмирнең «Саф күңел» (1954–1959) дилогиясе дә

бар. Вакыйгалар Ялантау район үзәгендә барып, зур булмаган эпизодлар рәвешендә сугыш хәлләре дә кушылып китә. Әсәр үзәгендә Сания һәм Камил образлары тора, алар иң матур сыйфатлары белән ачыла. Автор геройларын булдыклы хатын һәм ир, иҗтимагый эшлекле һәм, иң мөһиме, саф күңелле кешеләр итеп сурәтли. Башка әсәрләрне тулыландырып, автор көчле кешеләрне сафлык сыйфаты белән баета һәм шуның белән сыный да. «Саф күңел сыйфатына ия итеп автор Санияне генә күрергә теләми. Камил, Газиз Баязитов, Рифкать һ. б. персонажларның күңел дөньясы шулай ук бик матур» [7: 24].

Сугыш фаҗигаларын чагылдыруда үзгә бер юнәлеш Ә. Еники иҗатында урын ала. Сугыш барган елларда «Бала», «Мәк чәчәге», «Ана һәм кыз» кебек хикәяләре сугыш вакыйгаларын, аларга карашмөнәсәбәтне кеше күңелендәге хис-кичереш үзгәреше аша ачуы белән җитди яңалык алып килә. Әдип сугыштан соңгы елларда да үз иҗат принципларына тугры кала. Аның «Кем җырлады» (1956) хикәясе җанны өзеп алырлык фаҗигасы һәм кешенең асылын билгеләүче хис дулкынын ачуга бәйле лиризмы белән башка күпсанлы әсәрләрдән аерылып тора. Яшь солдатның үләр алдыннан сөйгәне Таһирәнең җырлавын ишетүе, шуның белән туган җирен, әнисен, якын кешеләрен күз алдыннан үткәрүе әлеге фаҗиганы тагын да тирәнәйтә, сугышка нәфрәтне көчәйтә, тынычлыкның кадерен белү кирәклеген хис-кичереш аша йөрәккә сала. Ә. Еники сызлану-сыкрану аша кеше кадере турында сүз алып бара һәм аның иң зур кыйммәт булуын ача. Ул иҗат иткән мөлаем татар кызы Таһирә авырлыктан, кайгы-хәсрәттән җыр-моң ярдәмендә үзен һәм янындагыларны тынычландыра алган өр-яңа образ булып калка.

Сугыш темасына язылган әсәрләрнең бертөрле генә бәяләнмәвен дә әйтеп китәргә кирәк. Аеруча Г. Әпсәләмов һәм М. Әмир романнары сугыш вакыйгаларын шомартып, берьяклы күрсәтү, геройларны идеаллаштырып бирү ягыннан тәнкыйтькә дучар була. Мисал өчен, Г. Әпсәләмов әсәрләрен Ф. Миңнуллин «социалистик реализм» принципларына нигезләнеп язылган норматив әдәбият үрнәге» [9: 103], дип бәяли. Кимчелекләрдән азат булмасалар да, әлеге әсәрләр үз чоры әдәби процессында мөһим урын алып торалар.

Шулай итеп, Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, М. Әмир, Н. Дәүли, Ә. Еники һ. б. әдипләрнең сугыштан соңгы елларда герой характеры чагылышына нисбәтле эзләнүләре әдәбиятның бертөрлелектән арынуына хезмәт итә. Фронт һәм тыл шартларында төп геройларга хас аеруча мөһим сыйфатларны аерып чыгару һәм аларның эш-гамәлендә урын алуы рәвешендә бара. Шәхес концепциясен билгеләүдә әсәрләрнең милли герое көчле, батыр, рухы нык, ышанычлы, намуслы, саф булу кебек характер сыйфатларында сурәтләнә. Әлбәттә, геройлар бирелешендә, әсәрләрнең сәнгати эшләнешендә аерым җитешсезлекләр булса да, алар китап укучыларда патриотизм хисе тәрбияләүгә хезмәт итүләре, шулай ук сүз сәнгатенең үсешүзгәрешенә җирлек әзерләүләре белән зур әһәмияткә ия.

**Әдәбият**

1. *Арамилев И.* Орлята становятся орлами // Новый мир. 1953. № 2. С. 256–258.

2. *Әмир М.* Гомәр Бәширов // Әмир М. Үзебез турында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. Б. 150–162.

3. *Бәширов Г.* Безнең бурычлар // Совет әдәбияты. 1955. № 3. Б. 97–108.

4. *Бәширов Ф., Зарипова Р.* Проза // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 5 т.: 1917–1956 еллар / [фәнни мөх. Д.Ф. Заһидуллина]. Яңарт. һәм тулыл. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. Б. 45–78.

5. *Галимуллин Ф.Г.* Намуслы гомер // Ватаным Татарстан. 2001. 10 гыйнвар.

6. *Заһидуллина Д.* Кереш // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 5 т.: 1917–1956 еллар / [фәнни мөх. Д.Ф. Заһидуллина]. Яңарт. һәм тулыл. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. Б. 5–14.

7. *Кашапова А.М.* Романтические культы в послевоенных татарских романах (1945–1960 гг.): Репрент. Уфа, РИО БашГУ, 2005. 40 с.

8. *Лихачев Д.С.* Заметки о русском. 2-е изд., доп. М.: Сов. Россия, 1984. 64 с.

9. *Миңнуллин Ф.М.* Безнең прозада сугыш темасы // Балта явызлар кулында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 97–107.

10. *Мусин Ф.М.* Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 5 т.: 1917–1956 еллар / [фәнни мөх. Д.Ф. Заһидуллина]. Яңарт. һәм тулыл. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. Б. 14–44.

11. *Мусин Ф.М.* Хәзерге авыл һәм әдәбият // Казан утлары. 1978. № 6. Б. 160–167.

12. *Нуруллин И.* Путь к зрелости. Казань: Татар. кн. изд-во, 1971. 350 с.

13. *Хәйри Х.* Язучы һәм тормыш // Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 287 б.

14. *Халит Г.* Чынлык һәм гүзәллек гармониясе // Совет әдәбияты. 1977. № 3. Б. 121–134.

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Габидуллина Фәридә Имаметдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел Буе) федераль университетының Алабуга институты доценты*

***Габидуллина Фарида Имамутдиновна,***
*кандидат филологических наук, доцент Елабужского института Казанского (Приволжского) федерального университета*

*farida_vip@mail.ru*

*«Фәнни Татарстан» журналында 2025 елның бу һәм алдагы саннарында, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм татар яңарышы әйдәманнарыннан берсе, язучы, драматург, публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе Фатих Әмирханның (Мөхәммәтфатих Зариф улы Әмирханов, 1886–1926) туына 140 ел тулуга багышлап, махсус сәхифә урын ала. Биредә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан әдипнең мирасы күпкә тулыландырылып, укучыга тәкъдим ителә торган алты томлы академик басмадан яңа материаллар да биреләчәк. Журналыбызның һәр санында дөнья күрәчәк материаллар аша әдипнең бай иҗаты хакында күзаллау тагын да төгәлләшеп, иҗаты һәм эшчәнлеге бүгенге фәнни югарылыкта бәяләнер дип ышанабыз.*

УДК 821.512.145

***Д.Ф. Заһидуллина***

# ФАТИХ ӘМИРХАН: ТАТАР ХАЛКЫ ӨЧЕН ЯНЫП ЯШӘҮ

Статья посвящена жизни и творчеству татарского прозаика и драматурга, публициста и журналиста Фатиха Амирхана. Рассматриваются малоизвестные факты из жизни, журналистской деятельности, сделана попытка обобщающей оценки творческой эволюции писателя. Установлено, что Ф. Амирхан стал одним из первых авторов татарской романтической прозы, мастером психологизма. Впервые в татарской драматургии он представил к вниманию татарского читателя психологические драмы. Ф. Амирхан обращается к художественному потенциалу разных литературных направлений: реализма, романтизма, модернизма. Он является сторонником идеи прогресса татарского народа, в критике и публицистике выступал за развитие национального образования, науки, культуры.

**Ключевые слова:** татарская литература, Фатих Амирхан, возрождение нач. XX века, психологизм, романтизм.

The article is devoted to the life and work of the Tatar novelist and playwright, publicist and journalist Fatih Amirkhan. Little-known facts from life and journalistic activity are considered and an attempt is made to generalize the assessment of the writer’s creative evolution. It is established that F. Amirkhan became one of the first authors of Tatar romantic prose, a master of psychology. For the first time in Tatar drama he presented psychological dramas to the attention of the Tatar reader. F. Amirkhan addresses the artistic potential of various literary trends: realism, romanticism, modernism. He is a supporter of the idea of the progress of the Tatar people, in criticism and journalism he advocated the development of national education, science and culture.

**Keywords:** Tatar literature, Fatih Amirkhan, renaissance of the beginning. Twentieth century, psychologism, romanticism.

2025 елның 1 гыйнварында XX йөз башы татар мәдәни тормышында иң йогынтылы шәхесләрнең берсе, Казан шәһәренең иң көяз егете Фатих Әмирханның тууына 139 ел тулды. Татар әдәбиятында төрле юнәлешләрдә эзләнүләр алып барган, бер-берсенә охшамаган, ләкин әдәби осталык ягыннан камил әсәрләр язган әдип, драматург, тәнкыйтьче, журналист, чибәр һәм зыялы, акыллы һәм талант иясе, гомерен милләткә багышларга карар кылган шәхес, туган көненең елны башлап җибәргән ял көннәренә туры килү беләнме, әллә инде озак вакытлар иҗатын кызыл әдәбият кысаларына кертеп бәяләү омтылышы яшәп тә, милли әдәбият белемебезнең шуннан арына алмавы сәбәплеме – үзенә тиеш югары бәяне һаман да алып бетерә алмый төсле тоела...

Гәрчә XX йөз башында Ф. Әмирханның һәр язган әсәре, мәкаләсе, язмасы басылып бара, кат-кат нәшер ителә, күләмлерәк әсәрләренең дәвамы көтеп алынып, зур сөйләшүләргә сәбәп була. 40 яшенә дә җитмичә дөньядан киткән әдип бай иҗат мирасы калдыра. И. Рәми мәгълүматларына караганда, үзе исән чакта гына да язучының 20 китабы басылып чыккан [10: 28].

Ни кызганыч: совет чорының артык «кызылланган» тәнкыйте әдип иҗатыннан баш тартып, вафатыннан соң 10 елдан артык аның бер генә әсәре дә дөньяга чыкмый. Шулай да татар әдәбият белеме, әдәбиятчы галимнәр язучының затлы исемен, мәшһүр иҗатын укучыга кайтарырга кирәклекне аңлыйлар: ил тарихындагы катлаулы, авыр 1941 елда аның А. Шамов төзегән, Х. Хәйри кереш сүз язган «Сайланма әсәрләр»е басыла; 1957–1958 елларда кайбер әдәби әсәрләре һәм публицистик язмалары кертелгән 2 томлыгы әзерләнә; 1984–1989 елларда Ф. Әмирхан мирасы шактый тулы – әдәби әсәрләре дә, публицистикасы да, тәнкыйть һәм хатлары да тупланып, Татарстан китап нәшриятында 4 том булып дөнья күрә [2: 93].

## Тормыш сәхифәләре

Ф. Әмирханның зәвыклы, дөньяны-яшәешне күреп кенә түгел, тоеп-сизеп һәм сиземләп аңлатучы бай күңеле, язмыш сынауларына бирешмәгән көчле рухы бүгенге укучы өчен дә үзенә җәлеп итүче сер булып кала. Бу сернең чишелеше, күпмедер, язучының тормышы, гаиләсе, ул кайнаган мохит белән бәйле.

Фатих Әмирхан 1886 елның 1 гыйнварында Казанда, 9 нчы мәхәллә имамы һәм мөдәррис Мөхәммәдзариф Хөсәен улы (1853–1921) гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Бу гаилә – татар дөньясында билгеле, абруйлы нәселләрдән: 1992 елда Р.Г. Әмирханов төзегән шәҗәрә буенча [4: 6], Гәрәйләрдән, Морат муллалардан ук килә. Морат мулла улы Исмәгыйльдән туган Әмирхан хәзрәт (1771–1828), Бохарада укып кайтып, Казанда муллалар династиясенә нигез сала: 1810 елда Иске таш мәчеттә мулла булгач, Яңа Татар бистәсендә «Әмирхания» мәдрәсәсен оештыра [4: 9]. Аның улы, Фатихның бабасы Хөсәен хәзрәт Әмирхан – шулай ук берничә ел Бохарада укып

кайткан, 14 исемдәге хезмәтләр (тәрҗемәләр, шәрехнамәләр, төрле күләмдәге рисаләләр, шигырьләр) язган Иске таш мәчет имамы – үзенең 4 китабын нәшер итә: алар арасында татарча Коръән тәфсире (1890), гарәпчә язылган дини «Шәрхел-хикәят» хезмәте (1879) һәм тарихи «Тәварихы Болгария» (1883), «Нәҗүмет-тәварих» («Тарихчылар йолдызы», 1884) бар [4: 12–14].

Бабасының һәм әтисенең хезмәтләрен бастыруга көч куйган галим һәм мөгаллим Мөхәммәдзариф хәзрәт тә «Әхәдисе кодсия» («Изге хәдисләр», 1909) дигән, дини мәдрәсәләрнең рөшдия (урта) һәм игъдади (урта мәктәптән югарырак) сыйныфлары өчен язылган дәреслек авторы буларак та, Казанның милли-иҗтимагый тормышына актив катнашкан шәхес кимәлендә дә билгеле; Г. Тукай җеназасын укыган имам буларак та халык хәтеренә кергән [4: 19–20].

Фатихның әнисе Бибирабига Зиннәтулла кызы (1852–1918) хуҗалыкларының ишегалдындагы дүрт бүлмәле иске йортларында һәрберсе өчәр еллык ибтидаи (башлангыч), рөшдия һәм игъдади сыйныфлары булган кызлар мәдрәсәсендә мөдирлек итә. Остабикә – башлангыч сыйныфлар өчен язылган «Нәҗател-мөкәлләфин» («Җаваплыларга ярдәм», 1910) исемле уку ярдәмлеге авторы [4: 21].

Шәһәрнең мәшһүр гаиләсендә туган Фатихка да юл гыйлем һәм фән дөньясында булыр дип фаразлана. Әтисе мәктәбендә 3 ел укыгач, ул белем алуын танылган «Мөхәммәдия»дә (1895–1905 еллар) дәвам итә. Мәдрәсә мөдире Г. Баруди тәртипле һәм аралашучан Фатихны Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрендә үз йортында өчәр көн дәвамында оештыра торган чәй мәҗлесләренә кунакларны каршы алу өчен чакыра торган була.

Фатихның шәкертлек еллары Ризван Ибраһимов (Алушев) истәлекләрендә теркәлеп калган: алга таба без шушы чыганакны файдаланырбыз [15: 7–11]. Шул истәлекләрдән күренгәнчә, «Тәрҗеман» газетасын, төрек әдәбиятын даими укып барган яшь егет өч ел дәвамында яшерен шәкертләр түгәрәгенә җитәкчелек итә. Аңа йөрүчеләр, һәр атнакич җыелып, мәктәп-мәдрәсәләрнең җитешмәгән якларын җентекләп тикшерәләр, татар теле кагыйдәләре язып, кулъязма газеталар чыгаралар, сәяси партияләр эшчәнлеге белән танышалар, инкыйлаби эчтәлекле җырлар өйрәнәләр. 1903 елны Фатих мәдрәсәдә Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасын сәхнәләштерүне яшерен рәвештә башлап йөри. Казанда укый торган студент һәм курсисткаларны берләштереп, 1905–1906 елның кышында ул йорт спектакльләре оештыра, үзе баш рольләрне башкара.

«Мөхәммәдия»нең урта баскычына (игъдади) җиткәч, Фатих Казан университеты студенты большевик С. Гассардан рус теле дәресләре ала, 1904 елның июнь-сентябрь айларында энесе Ибраһим (1889–1938) белән Самарада русча белемен тирәнәйтеп кайта. Аның максаты – экстерн рәвешендә өлгергәнлек аттестаты алу һәм университетның юридик факультетына укырга керү була. Әмма әзерләнеп тә, латин һәм физика предметларыннан имтиханын тапшыра алмый.

Шушы елларда коръәнхафиз Фатих диннән читләшә: ураза тотмый, рус һәм Көнбатыш модасыннан калышмыйча купшы киенә, руслар арасында татар икәнлеген яшереп, социалист булып йөри. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә 1901 елда Ф. Әмирхан рәислегендә «Иттихад[1]» яшерен җәмгыяте төзелә, ул 1904 елда «Әлислах[2]» комитеты дип үзгәртелә. Комитет татарлар арасында революцион фикерләр таратуны максат итеп куеп, монархияне бәреп төшерергә, тулы ирек һәм азатлык алырга, Казандагы һәм Россиядәге татар шәкертләрен иске ысуллы мәдрәсәләргә дөньяви фәннәр кертергә, уку йортларындагы эчке тәртипне үзгәртергә өндәгән, җилем басмада листовкалар нәшер итеп тараткан. 1902–1904 елларда кулъязма «әл-Мәгариф» газетасы 1905 елның 29 ноябреннән «Әлислах» исемендәге җилем басма булып чыга башлый, аны Россиядәге мәдрәсәләргә (шул исәптән, Кырым, Төркестан) тарату бурычы куела.

Фатих, идеологик әйдаман буларак, «Әлислах» комитетындагы шәһәр татар яшьләре исеменнән Санкт-Петербургта 1906 елның гыйнвар аенда узган «Иттифак әл-мөслимин»нең II съездында катнаша, анда сыйнфый аерымлыклар мөһим дип, милләт берлеге-бердәмлеге фикерен алга сөргән олы буын зыялыларга каршы сөйли. Бу хакта Ибраһим Биккулов истәлекләрендә күп кенә кызыклы мәгълүмат табарга мөмкин [15: 13–18].

1906 елның 10–15 май көннәрендә Казанда 20 ләп делегат (Оренбург, Троицк, Самара, Чистай, Бубый, Сатыш, Теләнче Тамактан һ. б.) катнашында гомумроссия татар шәкертләренең съезды үтә. Аның карарларында шәһәрләрдәге мәдрәсәләрне берләштерү, программаларындагы аерымлыкны бетерү, аларга дөньяви фәннәр кертү, уку йортлары өстеннән гигиена күзәтүе оештыру, эчке тәртипне саклау өчен шәкертләрдән комиссия булдыру, көнкүрешне рус мәктәпләрендәге кебек итеп кору, шәкертләрнең рәсми газетасын – «Әлислах»ны – гамәлгә кую кебек бурычлар языла. Съездны оештыру, аның кәгазьләрен әзерләү Ф. Әмирхан карамагында була.

Ярым легаль укучы яшьләр оешмасын жандармнар эзәрлекли башлый һәм 1906 елның мартында газетаның меңгә якын нөсхәсен конфискацияли. «Әлислах»ның җилем белән басылган соңгы 16 нчы саны 1907 елның мартында дөнья күрә.

Шәкертләрнең II съезды 1907 елның 1–6 май көннәрендә шулай ук Казанда оеша. Бу чарада Ф. Әмирхан турыдан-туры катнашмый. Хакимиятнең реакцион сәясәте шартларында 1908 елдан комитет эшен туктата. Аның фикерләрен һәм эшен рәсми басма буларак вакытлы матбугат мәйданына чыккан «Әлислах» газетасы дәвам итеп китә.

[1] *Иттихад* – берләшү.
[2] *Әлислах* – үзгәртеп кору, реформа.

## Публицист һәм журналист

Фатих 1906 елның көзендә Кавказ халыклары каһарманы шәех Шамилнең оныгы Заһид Шамил (1868–1923) чакыруы буенча Мәскәүгә китә һәм «Тәрбиятел-этфаль» («Балалар тәрбиясе») исемле беренче татар балалар журналы редакциясендә җаваплы сәркатип булып эшли башлый. Басманың иң беренче саны Ф. Әмирхан язган «Идарәдән» дигән язма белән ачыла. Автор балаларга татар дөньясында барган иске-яңа көрәше турында сөйли, аларны да журнал эшендә катнашырга чакыра, «киләчәккә куәтле игътикад[1] белән башланган бу караңгылык вә җәһаләткә каршы башланган көрәшемездә кайчан да булса бер җиңәрмез дип ышанамыз» [12: 17] дип, яшь укучыларын якты киләчәккә өнди.

Журналда Әмирхан кечкенә укучыларын аңлаешлы итеп мәшһүр шәһәрләр (Истанбул, Мәскәү һ. б.), табигать күренешләре (кояш, йолдызлар, җир тетрәү) бәйрәмнәр, фәнни һәм иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр (әйтик, Дума ачылу) белән таныштыра, яңа татар әдәбиятының беренче карлыгачларыннан Г. Исхакый әсәрләрен укырга тәкъдим итә, күпсанлы ирекле тәрҗемәләр (Х.К. Андерсенның «Гадкий утенок» экиятен – «Мәхәббәтсез үрдәк баласы», «Улитка и розовый куст» экиятен «Гөл агачы һәм әкәм-төкәм» исеме белән һ. б.) бастыра.

Бу чорда иҗат ителгән текстлар арасыннан, «Идарәдән (Яңа ел мөбарәк булсын!)» дигән 3 нче сандагы, һиҗри 1325 ел тулу уңаеннан әзерләнгән язмасы игътибарга лаек. Укучыларына «милләтебезнең булачак әгъзалары» дип эндәшеп, әдип балаларга үз халкын бәхетле якты киләчәккә чыгару өчен тырышу кирәклекне, моңа ирешү өчен гыйлем һәм фән генә ярдәм итә алачакны сөйли, «өйрәнеңез, укыңыз, зыяланыңыз» дигән сүзләр белән мөрәҗәгать итә [12: 31–32].

Биш саны нәшер ителгәч (1907 елның гыйнвар-март айлары), «Тәрбиятел-этфаль» чыгудан туктый. Казанга кайтып киткән Фатихның аякларын, уң кулын 1907 елның 15 августында паралич суга. Шушы авырудан 21 яшьлек егетнең аяклары йөрми торган булып кала. Сау вакытында көчле оптимист, җилкенчәк Фатих, коляскага беркетелгәч, җитдиләнә, ләкин күңел көрлеген җуймый, беркайчан да авыруыннан зарланмый. «Аның коляскасын һәрвакыт яшь егетләр, чибәр кызлар сырып алган була», дип искә алалар замандашлары [15: 96].

1907–1909 елларда Ф. Әмирхан радикаль карашлы яшьләр матбугаты органы саналган, атнага бер тапкыр 16 битлек булып нәшер ителгән «Әлислах» газетасының (рәсми мөхәррире Вафа Бәхтияров) рухын һәм эчтәлеген билгеләүче һәм һәр санда диярлек мәкаләләр бастыручы мөхәррире була.

Газетаның иң беренче санындагы «Казан, 3 октябрь» дигән баш мәкаләдә ул газетаның мәсләген «Татарның мәгыйшәтене[2] асылыннан

[1] *Игътикад* – ышану.

[2] *Мәгыйшәт* – тормыш.

сүтеп төзәтергә кирәк! Безгә аның урынына яңа мәгыйшәт кирәк» дип аңлата, нинди мәсьәләләр күтәреләсен билгеләп уза [12: 49]. Чыннан да, газета тематик яктан бик бай булып чыга. Монда белем-мәгърифәт, әдәбият-мәдәният, татар теле, театр, музыка мәсьәләләре дә, илдәге һәм дөньядагы сәяси-иҗтимагый вазгыять тә, хатын-кыз проблемасы да, дин, тарих, фәлсәфә дә игътибар үзәгенә куела [3].

Басма яшь татар язучылары, шагыйрьләре белән хезмәттәшлек итә. Анда М. Гафури, С. Рәмиев, М. Укмасый әсәрләре нәшер ителә. Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә», Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» кебек беренче хикәяләре дә шунда дөнья күрә.

Ф. Әмирхан газетага үз исеме белән дә, «Дамелла», «Ташмөхәммәд», «Ф. Ә.» тәхәллүсләре астында да яза. Иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга кагылышлы, бигрәк тә Дәүләт думасы эшчәнлеген аңлаткан язмалары халыкка аңлаешлы һәм сәяси төпле булулары белән аерылып торалар: «Думалар» (1907 ел, 3 октябрь), «3 нче Дума» (1907 ел, 25 октябрь), «Дума ачылды» (1907 ел, 5 ноябрь), «Думада центр» (1907 ел, 12 ноябрь), «Дума» (1907 ел, 3 декабрь) һ. б.

1907 елгы 3 октябрь санында ул «Мөтәгассыйб Казан татарларына ачык хат» дигән кискен сатирик мәкалә бастыра һәм иске карашлы татарларның эш-гамәлләрен күзәтеп, аларны милләткә, халыкка каршы кылынган дошманлык дип атый. Әмирхан татарларның иҗтимагый тормыштагы арттalыгын, искелек тарафдарларын кискен тәнкыйтьли. Әйтик, «“Әлислах”тан ни көтәргә ярый?» (1908 ел) исемле мәкаләсендә мөхәррир мәктәп-мәдрәсәләрнең хәлен күрсәтеп, алда торган бурычларны билгели, аларның мөһимнәре дип, гигиена таләпләренә туры килә торган уку биналары салуны, аларны белемле укытучылар һәм дәреслекләр белән тәэмин итүне атый.

Ф. Әмирханның «Әлислах»та басылган публицистик мәкаләләрен бер омтылыш, авторның татар дөньясын, татар җәмгыятен – мәгарифен, мәгърифәтен, фәнен, татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен үстерү аша – үсеш юлына чыгару нияте берләштерә. Нинди генә темага алынмасын, әдип эмоциональ тәэсир итү яки башка халыклар тормышы белән чагыштыру аркылы яңарышның, алгарышның мөһимлеген, заруриятен ассызыклый.

Газетаның теле, басманың татар әдәби телен үзгәртү-камилләштерү юнәлешендә әдипнең өлеше хакында Җ. Вәлиди гаять мөһим сүзләр язып калдыра. «“Әлислах”ның теле ул вакытта чыга торган гәзитләрнең теленнән бик нык аерыла. Монда госманчылык тенденциясен бөтенләйгә ташлау, татар телен катгый рәвештә мөстәкыйль бер тел итеп тану күренеп тора. Шуның белән бергә сүзләрне, тәгъбирләрне сайлауда, җөмләләрне төзүдә яурупалаштыру да күзгә бәрелә» [6: 430].

Газетада эшләү дәверендә Ф. Әмирхан үзен әдәбият тәнкыйтьчесе итеп таныта. «Әлислах»ның 1907 елдагы 3 декабрь санында «Габдулла Тукаев шигырьләре» дигән мәкаләсе басылып чыга. «Һәр

милләтнең шагыйрьләре – «шул милләтнең теленең сакчысы вә төзәтүчесе вә шул халыкның кайгы вә шатлыкларын үзләренә вә башкаларга дөрес сурәттә аңлатучы вә халыкның коры сүзләрдә изһар итеlә[1] алмаган халәте рухияләрен изһар итүчеседер. Шуңар күрә дә шигырь вә шөгарә халык әдәбиятында иң мөхтәрәм урынга куеладыр» [13: 11] дип, Ф. Әмирхан әдәби әсәрнең ике вазифасын аера: телне саклау-төзәтү; халыкның кайгы-шатлыкларын күрсәтү. Әлеге фикер Г. Тукай иҗаты мисалында исбатлана.

1908 елның 2 февралендә «Әлислах»та «Габдулла Тукай шигырьләре» дигән тагын бер рецензия басыла. Бу язмада Ф. Әмирхан Г. Тукай шигырьләренең теле һәм образлылык хакында сүз йөртә. Әсәрләрне бәяләүдә алдагы язмада искәртелгән ике критерийны кабат телгә ала, аннан соң язылган һәр тәнкыйть мәкаләсендә әсәрләрне шушы нокталардан якын килеп бәяли. Тәнкыйтьченең һәр язмасы татар әдәбиятын үзгәртергә дигән кайнар теләк-омтылыш белән сугарылган.

«Әлислах»ның 1908 елгы 2 март санында басылган «Мавәраэннәһердә сәяхәт» мәкаләсендә З. Бигиевнең шул исемдәге сәяхәтнамәсен, 1908 елдагы 9 март санында дөнья күргән язмада С. Рәмиевнең «Низамлы мәдрәсә» пьесасын һәм тел, сурәтләү җәһәтеннән тикшерә. Тәнкыйть мәкаләләрендә «сурәтлелек» (образлылык) төшенчәсен таркатып, ваклап аңлату омтылышы да ясый. Мәсәлән, «Низамлы мәдрәсә»дә Садыйк образының тулы эшләнмәвенә игътибар итә, ә инде шул ук басмада 1908 елдагы 3 апрель санында чыккан М. Гафуриның «Үги балалар» китабына тәнкыйтендә «фикерне типлар вә каһарманнар» [13: 32] ярдәмендә аңлатуның гына әдәбилек хакында сөйләвен ассызыклый. «Хыялмы, хакыйкатьме?» дә («Әлислах», 1908, 19 апрель) Ф. Кәриминең шул исемдәге китабына мөнәсәбәтле «ачы каләме белән берәр ачы милли мәсьәлә кузгатуын» [13: 35] әһәмиятле саный. Ләкин Ф. Әмирхан өчен әдәби әсәрнең фикер әйтүе, милли мәсьәлә кузгатуы үзмаксат түгел. «Әлислах» аша (1908, 17 июнь, 13 июль) «Татар шагыйрьләре» мәкаләсе белән Касыйм Уралецка җавап биреп, болай яза: «Тәнкыйтьче әфәнде: Гафури укырга, әхлакка өнди, – дип, шигырьне коры моральлек җәһәтеннән тәкъдир итә. Бу җәһәттән караганда, мәшһүр «Бәдәвам» китабына Гафури әфәнде барып җитә алганы юк әле: анда гыйлем – фарыз, хәмер эчү, исереккә сәлам бирү – хәрәм, ди» [13: 3]. Шул рәвешле, әдәби әсәрнең кыйммәте ягыннан Касыйм Уралецны, аның кебек фикерләүче татар әдәбиятчыларын «шигырь дигән нәрсәне вәгазь китабы дип аңлаучылыгы» [13: 63] өчен тәнкыйтьләп, Әмирхан татар әдәбиятының Урта гасырлардан килгән иң олы кимчелегеннән котылырга чакыра.

Бу мәсьәләгә тагын да төгәлрәк якын килү белән без «Әлислах»та 1909 елның 26 февралендә басылган «Габдулла Тукаев диваны»

[1] *Изһар итәлә* – белдерелә.

мәкаләсендә очрашабыз. Монда ул ачыктан-ачык түбәндәгеләрне бәян итә: «Шигырь тугрысында бик күптән, кирәк Шәрыкта вә кирәк Гаребтә мөгайян[1] бер фикер вә мөгайян бер караш хөкем сөрәдер. Бу караш әүвәлдә халыкта җибилли (инстинктивно) хасил булган булса да, соңга таба төрле кагыйдә нәзарияте (теориясе) дә вөҗүдкә чыккандыр. Хиссияттән мәхрүм, тасвираттан мәхрүм сүз тезмәләрен һичвакытта һичбер милләт әдәбияты үз шигырьләре арасында санаганы юк» [13: 92].

Г. Тукай Уральскидан Казанга кайткач, «Әлислах»та Ф. Әмирхан белән кулга-кул тотышып эшли. Фатих иң якын дустының төрек теле катнашкан телдән халык теленә күчеп әсәрләр яза башлавына зур йогынты ясый, аның ихлас киңәшчесенә һәм фикердәшенә әверелә. Аяксыз калган әдип янына иң еш килеп йөрүче һәм аралашучы кеше дә Г. Тукай була. Дустының вакытсыз үлемен Ф. Әмирхан бик авыр кичерә.

Ф. Әмирхан әдәбият-мәдәният әһелләрен фикри үстерү эшенә башка яклап та якын килә: 1908 елны ул «Әлислах» каршында тәрҗемәчеләр түгәрәге оештыра. Аның максаты итеп, рус, гарәп, төрек телендә язылган файдалы, кирәкле китапларны татар теленә тәрҗемә итү күрсәтелә. Чыннан да, тиз арада татар матбугаты рус, Европа, Шәрык галимнәре, философлар, язучылар, акыл ияләре хакында тәрҗемә материаллар да бастыра башлый. Бер яктан, тәрҗемә әдәбият, әдәби әсәрләр үзләре татар язучылары өчен үрнәк хезмәтен үти. «Тәрҗемәләрдә, еш кына ахыргы максатын аңлап тормастан, түбәндәге бурычлар чишелә: әдәби метод булдыруга ярдәм итү (романтизм, реализм); жанрлар ягыннан баету (хикәяләүче: роман, повесть, новелла, экият, кыйсса; лирик: ода, поэма, баллада, мәсәл; драматик: трагедия, көнкүреш, фәлсәфи, иҗтимагый, символик драма, комедия, мелодрама, водевиль һ. б.). Тәрҗемәләрнең төп кыйммәте шунда, алар әдәби гомумиләштерүнең яңа формаларын тудыруга хезмәт итә, психологик анализның кайбер яңа төрләрен аңлата» [8: 94]. Газета битләрендә нәшер ителеп, тәрҗемә әсәрләр татар әдәбиятына жанр, форма төрлелеген алып килә, тематик эзләнүләр мәйданын киңәйтә, психологик анализ көчәюгә, әдәби стильләрнең үзләштерелүенә китерә. Ф. Әмирхан үзе газетада рус әдәбияты, аның әдипләре, аларның әсәрләре хакында да язмалар белән чыга, 1909 елда исә Леонид Андреевның «Рассказ о семи повешенных» әсәрен тәрҗемә итә һәм «Асылган җиде кешеләр хикәясе» исеме астында «Үрнәк» нәшриятында бастыра. Тирән психологизм белән сугарылган текст, күрәсең, язучыны шушы сыйфаты белән үзенә җәлеп иткән: рус язучысының катлаулы сөйләмен Әмирхан гаять тәэсирле һәм матур татар телендә укучыга, психологизмны аңлату өчен, каләмдәшләренә җиткерә.

Тәнкыйтьтән – Ф. Әмирхан әдәбият тарихын өйрәнү мәсьәләсенә килә. 1908 елны «Әлислах»ның 8 һәм 30 сентябрь саннарында аның

[1] *Мөгайян* – анык билгеләнгән.

«Әдәбиятка гаид[1]» мәкаләсе басыла башлый. Татар әдәбияты хакында сүз алып баручы бу тикшеренү тәмамланмый кала.

Мәкалә «Нәрсә ул әдәбият?» дигән сорауга җавап белән башланып китә. «Әдәбият кәлимәсен мин монда литература мәгънәсеннән истигъмаль итеп[2], төрле нәрсәләр хакында язылып, мосанныйфы[3] мәгълүм бер шәхес булган нәрсәләргә итлак итәм» [13: 67] рәвешендә шактый киң (фәнни әдәбият, публицистик әдәбият һ. б. керә) һәм төп билгесе итеп авторы булу күрсәтелгән билгеләмә бирелә. Әдәбиятның башлангычын халык авыз иҗатында – авторы мәгълүм булмаган кыйссалар, җырлар, әкиятләрдә дип, Ф. Әмирхан халык иҗатының ике сыйфатын әһәмиятле саный: авыздан авызга сөйләнеп килү; «фикер вә тасвирның» халыкныкы булуы. Һәм автор халык авыз иҗаты тууны мәҗүси ышанулар белән бәйләп аңлата.

Өченче баскыч – дини әдәбият, рухани әдәбият, дип аерган Әмирхан дүртенче баскычта ярым дини, ярым дөньяви әсәрләр иҗат ителүне билгели, шулар арасыннан Ш. Мәрҗани иҗатын югары күтәрә, ләкин бу дәвердә гарәп йогынтысы көчле булуын да искәртә.

К. Насыйридан башланган бишенче баскычны – мәгърифәтчелек этабын – автор рус әдәбияты тәэсирендә формалашкан дип атый. Күренекле әдипләрдән З. Бигиевне телгә ала. Шулай итеп, татар әдәбият тарихының берничә баскычын аера, шуларга хас сыйфатларны барлый, әдәбият күренешләрен өйрәнү һәм бәяләүгә хронологик танып белү ысулын алып килә.

XX йөз башына кадәр татарларда әдәбият хронологиясе үсми: әдәби әсәрләр турында фикер йөрткәндә вакыт һәм заман үзенчәлекләре исәпкә алынмый. Нәтиҗәдә, әдәби үсеш хакында мәгълүмат берьяклы, фактлар төсендә генә бирелә. Әдәби торышны Ф. Әмирханнар башлап җибәргән хронологик танып-белү ысулы исә язучылар һәм әдәби әсәрләр тууны вакыт эзлеклелегендә күзәтә, аерым иҗатларны әдәби барышка урнаштыра, сүз сәнгатенә әдәбитарихи якын килү булдыра.

Әдәбиятны үстерүне халык аңы-фикере белән турыдан-туры бәйләп карый торган Ф. Әмирхан 1908 елда «Әлислах»та («Мәктәпләремездә әдәбият дәресләре», 30 сентябрь): «Вакыт түгелме мәдрәсәләребездә татар әдәбияты дәресләре башларга?» дигән чакыру белән чыга. Аныңча, укучыларга әдәбият дәресләре бирү – татар әдәбиятын-мәдәниятен камилләштерүнең туры юлы. Балалар һәм яшүсмерләрне тәрбияләү генә түгел, әдип фикеренчә, милли үзаңны булдыру һәм ныгыту да сүз сәнгатенә йөкләнә: «Әдәбият – дөньяга карашны киңәйтүдә вә теләгән фикерне аңларлык кешеләргә чәчүдә иң куәтле корал» [13: 78–79], дип яза ул.

Ф. Әмирхан газета битләрендә даими рәвештә мәдәни вакыйгаларны яктырта («Әдәбият кичәсе» (1907, 5 ноябрь); «Әдәбият кичәсе»

[1] *Гаид* – бәйләнешле.

[2] *Истигъмаль итеп* – кулланып.

[3] *Мосанныйфы* – авторы.

(1908, 8 гыйнвар); «Әдәбият кичәсе» (1908, 8 апрель); «Егерме бишендә татарча театр уены» (1908, 4 май); «Татарча спектакльләр» (1908, 24 ноябрь); «Татарча спектакль» (1909, 17 март) һ. б.), аның рецензияләре вакыйга-күренешләрнең уңай һәм тискәре якларына бик төгәл бәяләре белән аерылып тора. «Әлислах»ның һәр санында диярлек яңа басылып чыккан әсәрләргә, китапларга, җыентыкларга күзәтүләр урнаштыра, аларның зур күпчелеге заманча татар әдәбияты нинди булырга тиеш? дигән сорау контекстында әзерләнгәннәр.

Финанс кыенлыгы сәбәпле, 1909 елның 22 июнендә «Әлислах» чыгудан туктагач, Ф. Әмирханның әлеге төрле тематик бәйләмнәре башка газета-журналларга күчә. 1912–1918 елларда ул татар китабын нәшер итүче бертуган Кәримовларның сәүдә йорты хисабына чыгарылган либераль юнәлештәге дөньяви рухлы «Кояш» газетасының (редакторы Зәкәрия Садретдинов) фикри җитәкчесе, җаваплы сәркатибе һәм төп авторы сыйфатында хезмәт куя. Шулай ук мәкаләләрен һәм әсәрләрен «Йолдыз», «Идел» газеталарында, «Ялт-йолт» һәм «Аң» журналларына бастыра.

Г. Тукай белән бергә, Ф. Әмирхан «Аң» журналын оештыручылардан һәм аның мәсләген билгеләүчеләрдән дисәк, ялгышмабыз. Заманының иң затлы басмасы булган бу журнал эшендә Әмирхан мөхәррир Әхмәтгәрәй Хәсәнинең киңәшчесе, үсеп килүче талантлы, гыйлемле татар яшьләре – Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Кәрим Тинчурин, Габдерахман Кәрам һ. б. өчен остаз да була.

«Кояш»та дөнья күргән мәкаләләрендә әдип милли сәнгать һәм мәдәният үсеше мәсьәләләре, рус әдәбиятының дөньякүләм әһәмияте, татар җәмгыятендәге вазгыять һ. б. турында яза. Күрше төрки халыкларның хәлләре белән таныштыруга игътибар итә («Төркестан шивәсендә матбугаты мувәккатә» // «Кояш». 1913. 4 октябрь). 1913–1914 елларда «Кояш»та бер төркем фельетоннар бастырып, татар дөньясындагы күп кенә күренешләрне һәҗү-көлү каләме очына эләктерә. Шул ук вакытта яңа фикерләр һәм идеяләрнең юл яруы әдипне шатландыра. Әйтик, «Милли кызлар гимназиясе мөнәсәбәте илә» («Аң». 1913. № 3) язмасында ул сүз башына чыгарылган уку йорты төзү фикерен хуплавын белдерә, моны, хәтта, ирләр гимназиясенә караганда да мөһимрәк эш дип санавын нәкъ менә аналар ярдәме белән милләт булып җитешү мөмкинлегенә бәйләп аңлата.

Аяксыз калу аның дөньяга карашларына да нык тәэсир итә: 1905–1907 елларда атеист булса, тәгәрмәчле коляскага калгач, дини тойгыларга бирелә, фәлсәфи фикерләүгә өстенлек бирә башлый. 1913 елда Харитонов типографиясендә басылган Коръән аятьләрендәге ялгышларны күрсәтеп, Ф. Әмирхан беренчеләрдән булып тирән эчтәлекле мәкалә бастыра.

Әдәбиятта һәм мәдәнияттә Г. Тукай, Ш. Мәрҗани, М. Лермонтов һ. б. бу чорда Ф. Әмирхан тарафыннан идеал дәрәҗәсенә күтәреләләр.

Ф. Әмирханның газета-журналларда эшчәнлеген күз алдыннан кичергәндә, аның тулы бер буын татар милләтпәрвәрләре өчен рухи

таяныч булганлыгын искәртергә кирәк. Аны Җ. Вәлиди нәкъ шулай бәяли: «Ф. Әмирхан – татар әдәбияты тарихында гына түгел, бөтен татар иҗтимагый тарихында иң күренекле урын тоткан, вакыты белән кечкенә, ләкин әһәмияте буенча чиксез булган бер буынның үзәгендә торган кеше» [6: 429].

## Әдәби иҗаттагы эзләнүләр

Фатих Әмирхан гомере буе рус әдәбиятын, төрек һәм рус телләренә тәрҗемә ителгән Европа матур әдәбиятын яратып укый һәм фәлсәфәсен өйрәнә. Янына татар яшьләре килеп йөри, язучы алар белән мөһим мәсьәләләр хакында сөйләшә, шул ук вакытта язачак әдәби әсәрләре өчен материал да туплый торган була.

Иҗат эшчәнлеген ул 1907 елда, «Гарәфә кич төшемдә» хикәясе белән башлап җибәрә. Бу әсәр татар укучысы күз алдына ике төрле тормыш моделен: үз көнитешенең артталыгын һәм ирешү мөмкин булган Европача яшәү үрнәген – тасвирлап күрсәтүе белән шунда ук игътибарны җәлеп итә.

Аның хикәяләүче герое күкрәген *«тормышымнан риза түгеллек кайгысы баскан»* [11: 16]. Бу кайгының сәбәбе – татар бәйрәмнәренең, татар тормышының күңелсезлеге, көнкүрешенең мәгънәсезлеге, караңгылыгында. Шушы «өн»гә, чынбарлыкка хикәяләүченең «төш»е – автор идеалы каршы куела: мәдәни, шатлыклы, рәхәт бәйрәм киченең манзарасы укучы күз алдына бастырыла. Төш XX гасыр башы зыялыларының милләт киләчәге хакындагы хыялы, көнитешне күзаллавы булып аңлашыла. Шул рәвешле, чынбарлыктан туган хәсрәт, хикәяләүченең эч пошуы ниндидер башка тормыш булу мөмкинлегенә, милләтнең Европача көнитешкә ирешү өметенә алмашына, кеше аңының, акылының тормышны үзгәртәчәгенә ышаныч бирә. Әлеге төп идея дә, ике төрле дөнья сурәтен каршы куеп сурәтләү алымы да милләтнең киләчәген кайгырткан, үз халкын алга җибәрү теләгән бар нәрсәдән өстен күргән яңа татар әдәбиятында алга таба кызыл җеп булып сузыла.

«Бәйрәмнәр» (1909), «Көндезге сәхәр, яки рузасызлар» (1911), «Милләтне тәрәккый иттерү» (1908), «Рәхәт көн» (1910), «Хәзрәт үгетләргә килде» (1912) кебек хикәяләре татар җәмгыятенең торгынлыкта яшәвен тәнкыйтьләп, яңалыкка, гыйлемгә өндәп иҗат ителгәннәр. Язучы татар тормышының төрле катламнарын детальләрдә, мөнәсәбәт-кичереш дулкынында ача белә, капма-каршылыклар ярдәмендә укучыны үз фикеренә, караш ноктасына алып килә. Татар тормышындагы бүгенгенең чагылышы итеп күрсәтелгән вакыйгалар автор рониясе, юмор, сатира алымнары аша үткәннең билгеләре булып аңлашыла. Хикәяләрдәге яшь кеше образлары, аларның дөньяга карашы һәм хыяллары исә бөтенләй башка – яңа чынбарлыкка юнәлтелгән. Хикәяләүче, автор белән якынайган яңа карашлы егетләр генә түгел, «Рәхәт көн»дәге дүрт стена эчендә яшәргә дучар ителгән Гайниҗамал да иреккә, иркенлеккә омтыла.

Шуның белән бергә, язучы инде беренче хикәяләрендә үк үзен оста психолог, бер мизгел сурәтендә кеше язмышын, яшәеш фаҗигасын тергезә алучы рәссам итеп таныта. Әйтик, «Хәкарәт саналган мәхәббәт» (1908) романтик хикәясендә мәхәббәте кире кагылганнан соңгы иртәдә Салих кичергәннәр, шушы мизгелдә уй-кичереш үзгәреше сюжет хасил итә. Биредә көчле хәрәкәт тә юк. Геройның акылы, хисе үзенең мин-минлегенә кагылган сүзләрне онытырга, аларның тәэсирен җиңеләйтергә тели. Бу, аның өчен, әсәр башында күрсәтелгәнчә, «тау, аның уртасы, Салихның фикере шуннан үтә алмый иде» [11: 28]. Хикәя ахырында да тау урынында кала. Язучы исә шушы мизгел аша аның бөтен тормышын, холык-фигылен укучы хөкеменә тапшыра. Мәхәббәтне ялгызлыктан, эч пошудан котылу, бәхет юлы санау Салихка гына түгел, гомумән кешегә хас өмет, хыял, ышаныч икәнлеге гомумкешелек фәлсәфәсе булып яңгырый.

Авторның тасвирлау рәвеше, Салихның кичерешләре дә, борчылулары да саф, ихлас итеп сурәтләнү кайгылы мизгелне матурлыкка әверелдерә. Яшьлек, ярата алу, мәхәббәткә бәйле газап кичерү, чарасызлык чигенә җитү якты сәхифә – кеше гомерендә әһәмиятле урын били торган кичерешләр чыганагы кебек бирелә. Укучы да әсәр белән танышу дәвамында Салихны җәлләү ноктасына басмый, киресенчә, шушы мизгел кайчандыр Салихка да иң рәхәт мизгелләрнең берсе булып тоелачагына, мәхәббәт кичереп, үзләре дә охшаш хисләрдә янганнар өчен бу саф борчылуларның соңрак бер җылылык белән искә төшерелүенә ышандырыла.

Бүгенгене һәм киләчәкне, реаль һәм идеаль тормышны капма-каршы китерү Ф. Әмирханның сатирик әсәрләрендә үзәктә тора. «Фәтхулла хәзрәт» (1909) повесте хыялый-фантастик яссылыкта – үлеп, 42 ел үткәннән соң, Казан университеты лабораториясендә терелтелгән Фәтхулланың башка заманга эләгүен, шунда төрле көлкеле хәлләргә очравын сурәтли. Кадимчелек тарафдарларының тискәре сыйфатларын үзендә туплаган җыелма образ – Фәтхулла хәзрәт аша автор бер төркем дин әһелләрендәге бозыклык, наданлык, икейөзлелекне калку ача, тискәре-тәнкыйди бәясен бирә.

Фәтхулла үзен дөрес яшәүче кеше дип саный, бозык эш-гамәлләрен шайтан котыртуы белән аңлата. Шуңа да хөрмәтле хәзрәт «Бозыкларны төзәтү җәмгыяте»нең хөкеменә эләгә. Идеаль атмосферага кертеп, язучы Фәтхулланың үз-үзен тотышын гротеск чигенә җиткерә, акыл, үзара хөрмәт, матурлык хөкем сөргән җәмгыять фонында хәзрәтнең гариплеге фаҗигага әйләнә. И. Нуруллин бик дөрес билгеләгәнчә, «...ак җәймәдәге кара тап тагын да карарак булып күренгән кебек, алга киткән тормыш фонында Фәтхулла хәзрәтнең реакцион йөзе тагын да ачыграк, тагын да тулырак булып күренә» [9: 279].

Чынбарлыкка капма-каршы киләчәк исә мәгърифәтчелек идеалы яктылыгында, утопия рәвешендә тасвирланып бирелә. 20 шәр катлы йортлары, зур мәчете, китапханә-музейлары булган Казан шәһәре, андагы чыбыксыз көзгеле телефоннар, оча торган машиналар һәм авто-

мобильләр, үлгән кешене терелтү баскычына аяк баскан фән дөньясы мавыктыргыч күрсәтелә. Ф. Әмирхан Фәтхуллаларның әлеге якты киләчәк юлында киртә булуын фаш итә. Киләчәк буын кешеләре – Әхмәт, Ләйлә, Зыя, Нәфисәләр татар милләтенең сакланып калачагына, башка милләтләр белән мәдәни яктан тигез баскычта булачагына өметне белдерә.

Әсәр мондый капма-каршылык белән түгел, бәлки үзенең гаҗәп хикәяләү рәвеше – нечкә юмор, үткен сатира, сызланулы иониянең бер үремтәдә бирелүе белән сокландыра. Бу язу рәвеше бигрәк тә «Фәтхулла хәзрәт» повестеның (1911) икенче басмасына сүз башы итеп бирелгән «Минем тәрҗемәи хәлем» исемле язмада аермачык: әдип татар әдәбиятына үз-үзеннән көлү алымын, шулай итеп, татар җәмгыятен камчылау юлын алып килә. Бу көлү шулкадәр оста оештырылган, ул XXI гасыр укучысы өчен дә әдәби-эстетик ләззәт биреп, әдәби үрнәк вазифасын башкара ала.

Беренче әсәрләрендәге мәгърифәтчелек юлы Ф. Әмирхан өчен тар тоела, ул татар әдәбияты өчен яңа сукмаклар сала башлый. Символларга мөрәҗәгать итеп, фәлсәфи фикер әйтергә, гомумән татар дөньясында барган бәхәсләр, икеләнүләргә яңа караш ташларга мөмкинлек биргән әсәр – «Татар кызы» (1909) языла. Ул үз вакытында ук әдәбиятыбыз өчен яңа күренеш кебек бәяләнә. Ф. Әмирхан үзе дә хикәянең иҗатында аерылып торуын күрсәтә: «Бу хикәя моңа кадәр язган нәрсәләрем арасында үземнең бер генә данә ярата торган нәрсәм» [11: 427].

Әсәрдәге үзәк – тереклек символы итеп сурәтләнгән татар кызы, үткән һәм хәзерге вакытны кисештерүче үзәк, «төш» ролен үти. Беренче карашка, татар кызы барлык татар-мөселман хатын-кызлары язмышын үзенә сыйдырган аллегорик образ булып тоела. Ләкин әсәрдә бу образны башкача аңлау мөмкинлекләре дә ачык күренеп тора. Барыннан да элек, татар кызы Тереклекне гәүдәләндерә, моннан тыш, хыял-омтылышларның самимилеге, матурлык, хәтта, әсәр ахырындагы соңгы җөмләгә мөнәсәбәтле, изгелек кебек тә аңлашыла башлый – символга әверелә.

Эпиграфтагы Коръәннең 81 сүрәсе 8–9 аятьләрдән алынган өзек гарәпләрдә кыз баланы тере килеш кайнар комга күмеп үтерү йоласына ишарә ясый. Татар тормышындагы хатын-кызга карата традицион мөнәсәбәтне шушы йола белән чагыштырып, шуны кара көч дип атап, автор әсәрдә әлеге «күмелү» процессын күзәтеп бара. Туганнан алып 6 яшькә кадәр кеше булып яшәгән кыз баланың 7 яшьтә изоляцияләнә башлавын, иң соңыннан иренә уенчык һәм кол итеп бирелүен сөйли. «Азатлыкны буу Тереклекне үтерә» дигән нәтиҗә ясый. Нәтиҗә автор яшәгән чынбарлыкка гына тәңгәл түгел, ул – мәңгелек хакыйкать, татар дөньясына бәйле кулланылган татар кызы һәм кара көч символлары ярдәмендә гомумән яшәешнең бер кануны белдерелә.

Татар кызы символының өстәмә мәгънәләре кара көч образының да төрлечә шәрехләнүен тәэмин итә. Азатлыкны буунын матурлыкны

да, самими хыял-омтылышларны да юк итүен сөйли. Соңгы җөмлә: «Тереләй күмелгән кыз баладан ни гөнаһы өчен үтерелгәнлеген сорау көне – кыямәт көнедер, – диләр иде…» [11: 56] – өлеше гөнаһсыз газап чигәргә мәҗбүр ителгән татар кызын изге, аны «күмүне» кыяматкә китерерлек җинаять кебек гомумиләштерә. Нәтиҗәдә, татар кызы һәм кара көч Яшәешнең ике ягында урнашкан изгелек, яхшылык һәм явызлык баскычына күтәрелә.

Әсәрдәге күп кенә сыйфатлар: Р. Ганиева билгеләгән «Шәрык әдәбиятларының кысалы кыйссалар традициясе (эпиграфта һәм хикәянең азагында тереләтә җиргә күмелгән кызлар образы бирелә), мөсәҗҗәгъ нәсер (рифмалы проза) стиле» [5] моннан соң язылган әсәрләрдә дә күзәтелә. Идея белдергәндә катнаша торган ачкыч-сүзләр әсәр текстында кабатлана: алар –«хөррият» һәм «тереклек» сүзләре. Әсәрдә кабатлаулар, эчке рифма, аллитерация, анафоралар тавыш уены, моңы хасил итә, бу уен әсәрне кабул иткәндә доминанта ролен үти. Яңгыраш үзе лейтмотив дәрәҗәсенә җитә. Мәсәлән, хикәядәге 1 бүлектә – соклану катыш үкенеч, 2 – сагыш катыш үкенеч, 3 – кайгы катыш үкенеч, 4 – гаепләү катыш үкенеч күзәтелә. 5–6 бүлекләрдәге ирония 7 бүлектә хикәяләүченең ризасызлыгы, каршы төшүе белән тәмамлана. Үкенеч һәм ирония пафосның ике кисәкчәсе булып кына калмый, әсәрнең композицион җилеме, хикәяләүчене сыйфатлаучы вазифаларын да үз өстенә ала. Чөнки үкенеч тә, ирония дә теге яки бу күренешкә, кешегә карата кулланылмый, бәлки Яшәеш нигезләренә юнәлтелә. Әсәрдә үкенечле үткән ирония аша күз ташланган бүгенге киләчәк белән тоташа. Эпиграфта «Тереләй күмелергә теләмәгән мөселман Шәрык кызларына багышлыйм» [11: 47] дигән сүзләрне укыйбыз. Автор шуның белән үткәннең еракта калып баруын, «тереләй күмелергә теләмәгән» бүгенге туташларның киләчәк кешеләре икәнлеген ассызыклый. Хикәядә табылган язу рәвеше (лиризм, детальләр аша психологизм тудыру, яңгыраш ярдәмендә асмәгънә (подтекст) хасил итү) язучының алдагы иҗатында күзәтелә, гомумән татар прозасына нык йогынты ясый.

«Картайдым» хикәясе (1909) романтизм иҗат ысулына мөрәҗәгать итеп язылган. Аның төп герое Мостафа – өлгергәнлек аттестаты алып, университетка кергән 29 яшьлек егет. Үсмер чакта мөдәррис, остаз булу хыялыннан яшьлектә милләткә хезмәт итүче идеалына күчкән, олы мәхәббәт кичергән һәм үзе теләгән кадәр гыйлем җыйган, бу юлда уңышларга да ирешкән Мостафаның үзен бәхетсез хис итүен җәмгыять белән бәйләп кенә аңлату дөрес булмас иде. Шул җәмгыятькә каршы барып, үз дигәненә җитә алган лабаса. Димәк, Мостафа борчылуының сәбәбе, аның эчке халәтенең башы тирәндә: гомумән кеше, шәхес, яшәеш белән бәйләнгән. Кеше зур идеаллар, максатлар куеп, шуларга омтылып көрәшә – яши дә, көннәрдән бер көнне яшьлеге узып баруын аңлый. Яшәү мәгънәсе – үткәндә, яшьлектә икәнгә төшенә. Яшәешне фаҗига итеп карый башлый. Тормыш дөрес кануннарга нигезләнмәгән, ди сыман автор. Шушы фике-

рен герое Мостафаның эчке дөньясын, уй-кичерешләрен тасвирлау белән төреп, тәэсирле һәм ышандырырлык итеп калкытып куя.

Романтизм традицияләрендә иҗат ителгән «Кадерле минутлар» (1912) хикәясе мәхәббәтнең илаһи көч булуын раслап, аны бәхеткә ирешүнең бердәнбер юлы, яшәү мәгънәсе дәрәҗәсенә күтәрә. Хикәянең герое Рәшад үзенең өч ярату тарихын, шул вакытта кичергән кадерле минутларын сөйли. Һәр тарих мәхәббәтнең кешедә «хайвани тойгы (хис)» түгел, бәлки «нәфасәт, нәзакәт, матурлык белән ләззәтләнү» ятуын күрсәтә. Импрессионистик сурәтләр алмашыну, кыйссаларны ярату-сокланудан тыш хисләрдән арындырып тәкъдим итү мәхәббәтне илаһилаштырырга ярдәм итә. Ф. Әмирхан җаннарның күктә, биектә генә чын мәхәббәт, бәхет-сәгадәткә ирешә алуын искәртә. Моңа һәркемнең дә сәләтле түгеллеген билгели.

Ф. Әмирханның романтик әсәрләрендә төрек әдәбиятының йогынтысы, бигрәк тә Халид Зыя Ушаклыгөл (1868–1945) иҗатының тәэсире сизелә.

«Габделбасыйр гыйшкы» (1914) повесте мәхәббәт темасын тагын да үстерә. Ул үзгә вакыйгалылыкка һәм үзгә көлү алымнарына корылган. Кадим мәдрәсә шәкерте Габделбасыйр мәхәббәт «уйлап таба»: кыз исеменнән үзенә үзе хатлар яза, аннан бүләкләр «ала», очрашулар билгели, иптәшләренә үз мәхәббәте тарихын сөйләп тора. Беренче карашка Габделбасыйрның хисләре көлке тоела. Ләкин язучы мәхәббәт хисенең Габделбасыйрны үзгәртүен күзәтеп бара, укучыга шәкертнең гадәттән тыш примитив эчке дөньясын, тирәлекнең шыксызлыгын җиткерә. Иске тормышка ирония белән карап, аңа тискәре бәя бирүче Ф. Әмирхан мәхәббәтнең тормышны үзгәртерлек көч булуын раслый. Әмирхан көлүе яшь аралаш, экзистенциаль һөҗү булып чыга.

«Бер хәрабәдә...» (1912) хикәясе мәхәббәтнең югалуына, үлемгә, яшь гомерне үлем белән тәгәлләүче яшәешкә ләгънәт укып язылган. Ул хикәяләүченең «хәрабә» – яшьлек, матурлык, мәхәббәт, байлык, тәртип... җимерекләре белән очрашу мизгелен тергезә. Шушы мизгелдә кешенең өметләр белән яшәүче яртысы үлем котылгысызлыгын аңлаган икенче яртысы белән кушыла, хакыйкатькә төшенә.

«Сөләйман абзый йорты»на килгән хикәяләүче юлына очраган һәр әйбернең, детальнең үткәндәге хәлен һәм бүгенгесен сөйли. Өйнең тышы, капка, кыңгырау, ишегалды, өйнең эче, бакча, сукмаклар, эскәмия, агачлар – бар да искергән, картайган, бозылган, җансыз. Хикәяләүче бу хәл-күренешләрне битараф бәян итүче түгел, әсәрнең буеннан-буена ул шуларга мөнәсәбәтен белдереп бара. Өйне күргәч туган танымый тору чигендәге гаҗәпләнү хисе борчылу белән алмашына: «вакытында бик байлык, бик җитешлек һәм пөхтәлек белән эшләнгәнлеге күренеп тора торган бу йортның хәзерге кыяфәте, ала-колалыгы, купкалаган, җимерелгәнлеге, тузан белән яшькелткә әйләнгән тәрәзә пыялалары, гомумән, әллә ничек янган, көйгән, ташландык шикелле булып торуы минем эчемне пошыра, күңелемне каралта, моңландыра, әллә нишләтә иде» [11: 149].

Борчылу кайгы хисенә әйләнә: ишегалды да, авыр капка да, гүя хикәяләүченең күңеле дә «ыңгырашып» куя. Курку, чиркану хисе биш ел элек «таза, мәһабәт вә матур» Сөләйманны «кипкән, корышкан һәм сукырайган карт» [11: 151] итеп күргәч, аның саташуын, сүзләрен тыңлагач, бу хәлләргә ышанмаска теләү кебек үзгәрә. Хикәяләүче биш ел элек бу өйдәге, бу бакчадагы рәхәтлек, матурлыкны, Әсмага булган җылы хисен, кызның гүзәллеген искә төшерә. Элекке вакытны сагыну һәм кайгы хисе хәтта текстта да әйтеп үтелә. Карчыкның Әсма кабере яткан якка күрсәтүе, аның өрәге хакында сөйләве кайгыны чарасызлыкка әверелдерә. Чарасызлык исә яшәешкә ләгънәт уку белән тәгалләнә. «Мин артыма әйләнеп карарга куркып, йөгереп, урамның икенче ягына чыктым:

– Ләгънәт сиңа, и тормыш! Әүвәл алдыйсың, аннан соң мыскыллыйсың!» [11: 156]

Шул рәвешле, бер хистән – икенчесенә, бер уйдан капма-каршысына күчеп, хикәяләүче хакыйкатьне эзли, бетүнең сәбәбен табарга, димәк, үлемнән һәм юкка чыгудан котылу юлын билгеләргә омтыла.

Хикәя бик авыр һәм кайгылы хәлләр, тойгылар хакында сөйләсә дә, җиңеллек белән укыла. Чөнки импрессионистик алым – әсәрнең эчке мәгънәсен музыка аша бирү кулланылган. Кыңгырау һәм капканың моңлы тавышын Сөләйман карт елавы, кабатланып бирелә торган сүзе, аны исә лирик чигенеш ясап кертелгән сандугач, бакча тавышы, гитараның моңлы уйнавы, карчык йөткерүе һәм «мин»нең эчке тавышы-монологы, аларны каргалар каркылдавы, каралтыларның өметсез тавышы алыштыра. Картның исеме Сөләйман булу юкка түгел: пәйгамбәр исеме биреп, автор аны изгеләштерә, «чистарта», бу хәлләргә – хәрабәгә төшүгә – картның гаебе юклыкны ассызыклый. Кызлар образын тудырганда да шул ук алым кулланыла. Өйнең яртысында кеше тормый дигән сүзгә хикәяләүче: «Мин белгән заманнарда анда фәрештәләр торалар иде» [11 151], – дип әйтеп куя. Әсәр ахырындагы монологта да: «Фәрештәләрдән өрәк чыгамы соң?» [11: 156] – дигән илерү-сызлану бар. Шулай автор әлеге үзгәрешләргә кызлар да гаепле түгеллекне искәртә. Нәтиҗәдә, әсәр тормыш-яшәешкә ләгънәт укучы, сызлану фәлсәфәсен белдерүче булып аңлашыла. Тормышның мәгънәсе юклыкка төшенү, матурлык, яшьлек, мәхәббәт, бәхетнең вакытлы булуы, юкка чыгуы хакында сөйли.

«Урталыкта» романы (1912) татар мәдрәсәсен тәмамлаган, үзлегеннән русча укырга тотынган Хәсән Арсланов – ата-бабалардан килгән кадими яшәү рәвешен кабул итмәгән, шул ук вакытта үтә революцион яки урыслашкан яшьләрнең мәсләген дә охшатып бетерми торган яшь мөселман тибы тудыра, шуның аша үзе яшәгән татар җәмгыятендәге кадим һәм инкыйлабчы ике төркемнең «уртасында» 1910 елларда үсеп чыккан, милли үзаңны, мәдәниятне үстерү һәм милләтне бергә туплау юлы белән киләчәккә хәрәкәт итәргә теләгән яшьләргә бәя бирә.

Татар әдәбият белемендә Ф. Әмирхан тудырган, аннары Г. Исхакый, Г. Гобәйдуллин һ. б. язучылар иҗатында кабатланган әлеге типны «артык кеше» дип карау яши. Ләкин үз заманы өчен Хәсән Арсланов күпләрнең идеалы булырлык. Аның эш-гамәлләрен, башка яшьләрнең тормышын сурәтләгәндә, язучы икеләнүләргә, акрынлыкка, үз гамәлләренең дөреслегенә ышаныч җитеп бетмәүгә игътибар итә. Бер яктан, яшьләр спектакль куярга әзерләнәләр, рольләр бүлешәләр, бәхәсләшәләр. Аннан килгән акчаны ике ярлы студент өчен түләргә, калганын сәяси тоткыннарга ярдәмгә бирергә дигән карар кабул ителәә. Бу үзәк күренеш яшьләрнең якты максатлар белән яшәвен ассызыклый. Бу барышның акрынлыгына укучының игътибарын юнәлтү исә төркемдә аны иярттеп китәрлек, киләчәкне алдан күреп, аны үзгәртергә сәләтле кеше, лидер-әйдаман булмау фикеренә китерә.

Татар әдәбиятына яңа алымнар кертү юнәлешендә Ф. Әмирхан күп кенә кызыклы тәҗрибәләр ясый. 1912 елны «Аң» журналының 1 нче санында Леконт де Нойльнең «Шәрык йокысы» дигән картинасыннан репродукция урнаштырыла. Анда бер Көнчыгыш кешесенең наргилә – төтенне су аша үткәрә торган тәмәке тарту коралы – кабып, һич кайгысыз йоклаганы сурәтләнә. Рәсем белән янәшә Ф. Әмирханның «Шәрык йоклый… (Рәсемгә даир)» дигән нәсере китерелә. Символистик әсәр рәсемдә сурәтләнгән фәкыйрь алачыктагы зиннәтле йомшак ятакны, аңа чумып йокыга талган кешене, уянганын көтеп торучы наргиләсен күз алдына бастыра. Шуның белән янәшә, рәсемгә шәрехләү бирә: бу йокыга талган – ислам Шәрыгы, ул авыр йокыда, җәннәтләр һәм хур кызлары белән хыяллана. Ә тирә-якта уяулар мәмләкәтләр бүлешә, аның хәзинәләрен талый, үзен кол итәргә җыена. Алар белмәгәнен белергә омтыла, сәүдә итә, белгәнен тормышка ашыра. Бу шәрехтә ислам Шәрыгы һәм уяулар символларын капма-каршы кую аша, хикәяләүче авторның шушы хәлгә битараф булмавы, ачынуы, борчылуы күренә.

Ләкин автор тагын бер символик образга, елаучыга ишарә ясый: рәсемдәге наргилә төтененең күздән яшь агызуын соңгы җөмлә итеп урнаштыра. «Ул төтен бормаланып-бормаланып әтрафка тарала, үзе күргән күзләрне зәһәрли, ачыттыра, аңардан ихтыярсыз яшь агыза» [12: 189]. Әйтерсең, хикәяләүче укучының да күзеннән яшь агызырга, аны наргилә томаныннан азат итәргә омтыла. Агулы йокы фаҗигасы санап барыла: Шәрыкның «матди вә мәгънәви куәте», «хәятка малик булган тормышы, тереклеге», «гакылы вә гыйльми көче», «кайчандыр ярты дөньяны биләрлек хөкүмәтләр ясаган матди көче», «бөтен мәмләкәте, кайчандыр дөньяга фәрманнар таратып торган мәмләкәте», «җәннәтел-фирдәвескә охшап торган җире», «диңгезләре», «бөтен сизүе, тойгылары...» [12: 188] йоклый. Шушы хакта сөйләүче хикәяләүче, уянырга чакырып, Шәрык баласы уянгач күрәчәк чынбарлыкның пәрдә читен күтәрә. «Йоклаучы Шәрык» символы турыдан-туры татар милләтенең хәлен бәяләү өчен кулланыла, аллегорик образлылык, татар

тарихының үткәне һәм бүгенгесенә кагылышлы билгеләрне мул куллану әсәрне милләткә мөрәҗәгать кебек аңлауга китерә.

«Фәрештәләр җуатсыннар сине!» (1914) нәсере дә шушы юнәлештә, язучы милли рухлы кешенең җыелма образын «Җәгъфәр» – Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендәге герой – исеме белән атап, милләтнең бетеп баруына сызлана. «Җәгъфәр» – татар җанлы кеше символы, «ул кечерәк, кечерәгрәк кешеләр кыяфәтенә кереп тә җылаган, ялгызлыктан җылаган, фаҗига күреп җылаган» [12: 254]. Язучы гасыр башы татар зыялыларының чарасыз эш-гамәлләрен «елау» белән тиңләштерә, шул ук вакытта җәмгыятьнең битарафлыгын тәнкыйть объекты ясый: «Җәгъфәр җылый да җылый, әмма әтрафындагылар йә тәгаҗҗеб итәләр, йә рияле сурәттә кызганган булалар, хәтта кайсыбер таш йөрәкләр әле симез, әле пычрак йодрыклары белән Җәгъфәргә яныйлар: «Тыныңны чыгарасы булма!» [12: 255]. Ләкин үзен милләт улы дип санаган кеше еларга тиеш, шушы елау гына милләтне уята да, елата да, аңа хакыйкатьне төшендерә дә ала. Хакыйкатькә төшенмичә торып, киләчәккә юлны билгеләү мөмкин түгел.

XX гасыр башы романтик әдәбияты татар тарихына еш мөрәҗәгать итә, милләтнең үткәнен мифлаштыру күренеше киң җәелә. Ф. Әмирханның «Халык кызлары» циклы (1913) шушы дулкында язылган.

Беренче әсәр – «Ай өстендә Зөһрә кыз» хикәясендә сюжет мифологиядәгечә: Зөһрәнең матурлыгыннан көнләшеп, үги анасы аны нык рәнҗетеп-җәберләп яшәгән, авыруга әйләндергән. Бичара Тәңрегә ялварган, күккә күтәрелгән. Әсәрдә авторның фәлсәфи фикере дә бик ачык беленеп тора: кешеләр бер-берсен рәнҗетеп, җәберләп яшиләр, шуңа күрә аларның тормышлары да, хәтта ай да моңсу.

Шушы әсәрнең дәвамы төсендә иҗат ителгән «Сөенбикә» хикәясендә легенда Сөенбикәне символ дәрәҗәсенә куя. Вакыйгалар Казанны яулап алу, Сөенбикәне Казаннан алып китү хакында сөйли. Үткәнгә бәйләп милләтнең бүгенге хәл-халәтенең ни өчен өметсез һәм караңгы булуы аңлатыла. Сәбәпләр – дәүләтчелекне җуюда, ди автор.

Өченчесе – «Картада оттырылган Зөлхәбирә» хикәясе – халыкта яшәгән Зөлхәбирә хакындагы легендага нигезләнеп язылган. Ул социаль төсмердән дә азат түгел. Имеш, Мостафа мулла, Түрә белән карта уйнап, бөтен байлыгын оттырган. Ахырдан кызы Зөлхәбирәне картага уйнаган. Түрә белән чиркәүгә кергән җирдә, кыз Түрәне үтергән, үзе дә үтерелеп, «җиденче кат күккә» ашкан.

Шушы хикәят белән янәшә әсәрнең буеннан-буена икенче катлам – автор тудырган миф сузыла. Ул авторның яшәешне күзаллавын аңлата. Бу дөнья һәм теге дөнья, кеше һәм Аллаһы Тәгалә бер, бөтен итеп күрсәтелә. Яшәешне үзгәртү юлын автор илаһи һәм җир тормышының берлеген аңлауда таба. Зөһрә кыз шушы ике яссылыкны тоташтыра. Ф. Әмирхан биологик һәм рухи тормышны мәңгелек белән кушу поэтикасы иҗат итә.

1913–1916 еллар аралыгында әдип бер-берсенә бөтенләй охшамаган хикәяләре белән чыгыш ясый. «Ул үксез бала шул!» (1913) хикәясе гает көнне булган кечкенә генә вакыйга ярдәмендә ятимлек фаҗигасын ача. «Зәгыйфь карчыкның корбаны» (1914) – сугыш китергән кайгыны гомумкешелек фаҗигасы дәрәҗәсенә күтәрә. Бердәнбер улын ничек үлемнән коткарып калу хакында гына уйлап көн итүче карчык өмете сугыш дәһшәтенә каршы куела. «Сүнгәч» (1916) хикәясендә бәхет, мәхәббәт, матурлыкның вакытлы булуы хакында фикер үткәрелсә, «Яз исереклегендә» (1916) хикәясендә, киресенчә, яшәүгә, матурлыкка мәдхия яңгырый, мәхәббәт – яңа бер хәят дип белдерелә.

Ф. Әмирхан драма төренә дә мөрәҗәгать итә. «Яшьләр» (1909) драмасы татар тормышындагы фикерләр каршылыгын тема итеп ала. Сәүдәгәр Хөсәен мәдрәсә тәмамлаган улы Газизне, киләчәктә сату-алу эшендә ярдәме тияр дип, рус мәктәбенә укырга бирә. Ләкин Газиз, аның артыннан энесе Йосыф, сеңлесе Зәйнәп башка тормышка омтыла башлыйлар: аларга белемле кешеләр булып, милләткә хезмәт итү идеясе якын тоела. Йосыф белән Зәйнәпне олы улы йогынтысыннан араларга башка чара тапмыйча, Хөсәен Газизне өеннән куып чыгара. Бу каршылыкны герое Газиз авызыннан автор иске һәм яңа тормыш көрәше дип атый. Шул рәвешле, драматург татар дөньясындагы үзгәрешләр башланган, буыннар арасында каршылык барлыкка килгән вакытны, өр-яңа фикерле яшьләр катламы хасил булу процессын, иске һәм яңа арасында тартыш башлануны күзәтә. «Бер гаилә драмасы мисалында автор татар җәмгыятендә барган хәлләрне ача һәм XX йөз башы татар гаиләсендә туган каршылыкның асылын билгели. Яшьләр искечә яшәү мөмкин түгеллеккә төшенә» [1: 46].

«Аталар» лагерена караган Хөсәен, Рәхимҗан, Мәрьям, Зыя, Фәхерниса образлары аша Әмирхан татар дөньясындагы күп кенә якларны тәнкыйть итә. Әсәрдә хатын-кыз бәхете, милләт язмышы кебек проблемалар күтәрелә. Бәхетне милләт өчен көрәшүдә күргән яшьләр образлары тудырып (Газиз, Йосыф, Зәйнәп, Гали, Әхмәт), Ф. Әмирхан татар тормышын асылыннан үзгәртү фикерен яңгырата. Яшьләрне иске тормышны җимерү кирәклеге турындагы караш берләштерсә дә, киләчәкне күзаллаулары төрле. Милләтче Зыя төрки-татарларның берләшү идеясен дөрес саный. Гали мәгърифәтчелек-халыкчылык юлын кулай таба. Социалист Әхмәт сыйнфый тигезлекне яклый. Газиз шәхес ирегең, сайлау ирегең яңа тормышның нигезендә күрә. Татар әдәбияты мәйданында бу геройларның күбесе өр-яңа характерлар булу әсәргә уңыш китерә.

Пьеса татар җәмгыятендә драма әсәренең өр-яңа тибы дип каршы алына, күп кенә әдәбиятчылар Ф. Әмирхан сайлаган психологик драманы татар драматургиясенең киләчәккә үсеш юлы дип белдерәләр, әдип мәдәни даирәләрдә драматург буларак кабул ителә башлый. Әмма әдип үзе беренче әсәреннән канәгать калмый.

«Тигезсезләр» (1914) дип аталган икенче драмасы шул ук: аталар һәм балалар конфликтын үзәккә ала. Ләкин беренче әсәрдә аталарның

максаты – тормышны иске эздә саклау, балаларныкы исә иске тәртипләрне җимерү булса, биредә хәл үзгәрә. «Тигезсезләр» дә аталарның максаты – искечә яшәп баю, балаларныкы исә – яңача яшәп баю кебек төгәлләшә. Татар зыялы яшьләрендә күзәтелгән рухи, фикри, гамәли яңарышларга игътибар итсә дә, автор татар дөньясында милләтне алга илтү идеясенең сүлпәнләнүен ассызыклый.

Драма шулай ук бер гаилә: сәүдәгәр Сафи Насыйбуллин һәм аның балалары, яшьләрнең дуслары турында сөйли. Әсәрнең исемен ачыклап килгән «яңа кешеләр» гыйбарәсе яшь буынга юнәлтелгән. Гомәр Насыйбуллин – барлык гамәлләрен акча җыюга юнәлткән «яңа эшмәкәр». Хәтта якыннары белән мөнәсәбәтләрен дә Гомәр файда кысаларында кора. Аның сеңлесе Рокыя – шулай ук замана кызы: ул гимназиядә белем ала, яраткан эше – рәсем ясау белән шөгыльләнә. Ләкин абыйсы Гомәр аңа юрист һөнәре алырга киңәш итә, моны рәсем ясап тамак туйдырып булмаячагына бәйләп дәлилли. Апасы Сәлимә, гимназия тәмамлау турындагы хыялыннан ваз кичеп, магазинга кассир булып урнаша, яратмаган кешесенә – бай малае Гайсага кияүгә чыгарга әзерләнә. Сәлимә язмышы Рокыяның киләчәгенә ишарә ясый.

Тагын бер «яңа кеше» – язучы Сөләйман. Акыллы, фикерле, тормыш тәҗрибәсе туплаган Сөләйман тормышка аек күз белән карый, дөрес сүзләр сөйли. Ләкин ул үз идеалларын тормышка ашырырлык көчле, көрәшче түгел. Шул рәвешле, язучы «яңа кешеләрнең» иҗтимагый камилләшү юлыннан китеп, шәхси тормышларын кору сукмагыннан атлауларын билгели.

Бу әсәр әдәби-эстетик җәһәттән камиллеге белән аерылып тора. «Тигезсезләр» гыйбарәсенә автор гомумкешелек эчтәлеге сала: аны исә, тышкы шартлардан, ситуацияләрдән бигрәк, һәр характерның кичерешләр, омтылышлар, тойгылар хәрәкәтендә ачып, һәркемнең мохиттә үз урынын ничек билгеләве, үз-үзенә эчке психологик бәясе яссылыгында күрсәтә. Драматургның А.П. Чехов әсәрләре тибындагы психологик драма иҗат итүе татар драматургиясен үстерүгә зур өлеш кертә.

Кеше кичергән ниндидер фикер, күзаллау, аның каршыннан узган, кайчакта төшме-өнме, хыялмы-чынбарлыкмы икәнлеге мәгълүм түгел халәттә булган мизгелне тасвирлау, аны реалистик сурәт тукымасына китереп кертү, ягъни импрессионистик алымнарга мөрәҗәгать итү XX йөз башы татар прозасында еш очрый. Күләмле әсәрләрдә импрессионизм алымы кеше психологиясен ачу белән үрелеп китә, әсәрләргә тәэсирлелек өсти. Кайбер очракларда ул әсәрне чынбарлык чикләреннән алып чыгып китә, яшәеш һәм теге дөнья хакында уйлануларга этәрә, ниндидер фәлсәфи фикер уятуга хезмәт итә. Мизгел рәсеме теге дөнья белән бу тормыш, фани һәм бакый арасындагы чик өстенә туры килә, шушы чикнең бик нечкә һәм шартлы булуын искәртә.

Импрессионизмны үзәк принцип итеп алган әсәрләрнең берсе – Ф. Әмирханның «Яз исереклегендә» (1916) хикәясе. Исем астына автор «языла башлап ташланган бер хикәядән» дигән аңлатма бирә, ул үзе дә ниндидер зур әсәрнең бер кисәге кебек тәэсир калдыра. Җәй

башы, яшь шәһәр егете атларга утырып, авылдагы дустына кунакка бара. Хикәя шушы юлны, егетнең кичереш-уйларын бик тәфсилле сөйләп-күрсәтеп бара. Әсәр авылга килеп җитеп, чәйгә утыру белән тәгәлләнә.

Бер яктан, егет исеменнән хикәяләп, әсәр аның күзе төшкән, күргән һәм ишеткән, уйлаган һәм тойган һәрнәрсәне җепкә тезә. Ләкин хикәяләү салмак тонда түгел: атлар шикелле үк, егетнең дә күңел ашкынуы тавышлар һәм хәрәкәт фигыльләренең күплеге ярдәмендә барлыкка китерелә. Атларның чабуы, кучерның кычкырулары, юлда очраган кешеләрнең тавышлары һәм көлүләре, кызлар белән ат узыштыру, сәламләшүләр – бар да повозканың гына түгел, егетнең дә очынулы халәтен тоярга ярдәм итә.

Озын хикәядә язучы, әйтерсең, һәр мизгелнең сурәт-картинасын кабаттан тергезә. Өчесе дә бертөсле матур атлар, уңайлы повозка, кыр, урман күренешләре, авыл җентекләп тасвирлана. Табигать матурлыгының күңелгә тәэсире күзәтелә. Менә язгы һаваның рәхәтлеге турында сүз алып барыла, шунда ук күңелдәге халәт тә ачыклана: «Бөтен әгъзаларымда сизелә торган саулык, тазалык вә яшьлек өстенә, бөтен вөҗүдемдә үзем сизә торган бер нәфислек, хәтта матурлык миңа бу дәкыйкадә әллә ничек хосусый сурәттә аермачык сизелә, беленә вә шул сизү, вә шул белү миңа томанлы бер рәхәт вә кәеф бирә иде. Ул гына түгел, миңа бу дәкыйкадә үземнең язгы җиңел киемнәремнең җиңеллекләре вә аларның шундый язлыклы матур вә үз гәүдәмә мөтәнасиб нәфис булучылыклары да хосусый сурәттә сизелә вә үз-үземнән һәм үземне чолгап алган әхвальдән риза булучылык тойгысы тудыра иде». Менә үсеп утыручы чәчәкләрнең «үзләренә бертөрле үсеп утыруларында, үзләренә бертөрле матурлыкларында минем җаным ниндидер бер кодси олуглык вә кодси яшеренлек тоя иде». Яки очраган «бик сөйкемле кешеләр вә һәммәсе дә бик бәхетле шикелле иделәр» [11: 283]. Шул рәвешле, әсәрнең буеннан-буена егетнең җан-күңел хәрәкәте дә үзгәреп бара.

Әсәрнең сурәтләү объекты нәкъ менә шул күңел хәрәкәте дә инде. Табигатьтә генә түгел, егет гомерендә дә яз хакимлек итә. Ниндидер билгесез матурлыкка, рәхәтлеккә ашкынучы егет әсәр соңында матур кызларга тап була. Билгесезлек әлеге көтелә торган матурлык-рәхәтлекне мәхәббәттә дип уйлау белән алышына, егетнең халәте шушы ноктага кадәр үсә. Аннары яңа баскыч башлана: «өстәл яны минем өчен яңа бер хәят кәсеп итте» [шунда ук: 297]. Язучы сокланып күзәткән мизгел – яшьлекнең гашыйк булырга өлгереп җитү мәле. Шушы мизгелнең сафлыгын, гүзәллеген, киеренкелеген күрсәтү авторның максаты булып тора.

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**

1. *Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: Истоки и формирование социалистического реализма. М.: Наука, 1983. 263 с.

2. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 томда. 1 т. / төз.: Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 751 б.

3. «Әлислах» газетасының библиографик күрсәткече / төз. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1991. 78 б.

4. *Әмирхан Р.* Әмирханнар (тәфсилле шәҗәрә). Казан: Мәгариф, 2005. 125 б.

5. *Ганиева Р.* Татар әдәбияты һәм Фатих Әмирхан // Мәгърифәт. 1996. 13 февр.

6. *Җамал Вәлиди.* Әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз.: Д. Абдуллина, Җ. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2010. 624 б.

7. *Мәһдиев М.* Ф. Әмирхан. Тормышы һәм иҗат юлы турында кыскача очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 86 б.

8. *Нигматуллин Э.Г.* Татарская литература нач. XX века (до 1917 года) в ее отношении к западноевропейской литературе и философско-эстетической мысли: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1972. 232 с.

9. *Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1966. 427 б.

10. *Рәми И.Г., Даутов Р.Н.* Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 399 б.

11. *Фатих Әмирхан.* Әсәрләр: дүрт томда. 1 т.: хикәяләр (1907–1922). Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 480 б.

12. *Фатих Әмирхан.* Әсәрләр: дүрт томда. 3 т.: публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 512 б.

13. *Фатих Әмирхан.* Әсәрләр: дүрт томда. 4 т.: әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 390 б.

14. *Фатих Әмирхан.* Хәят. Казан: ТӘһСИ, 2016. 308 б.

15. Фатих Әмирхан турында истәлекләр / төз.: Ф. Ибраһимова, Р. Әмирхан. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 255 б.

***Заһидуллина Дания Фатих кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият бүлеге баш гыйльми хезмәткәре*

***Загидуллина Дания Фатиховна,***
*доктор филологических наук, профессор, главный научный сотрудник*
*отдела литературоведения Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*zagik63@mail.ru*

УДК 82-95

***Г.Н. Зәйниева***

# ФАТИХ ӘМИРХАН ПУБЛИЦИСТИКАСЫН БАРЛАГАНДА

Важную роль в истории татарской литературы как периодического печатного органа сыграла газета «Альислах». Газета издавалась с 3 октября 1907 года по 22 июля 1909 года, всего было выпущено 68 номеров. Официальным редактором и издателем был Вафа Бахтияров (1881–1960), но фактически редакционную работу вел Фатих Амирхан (1886–1926). Издание было нацелено на пропаганду просвещения татарского народа, на введение новометодных программ обучения, на расширение национального образования. В газете публиковали свои произведения многие известные литературоведы, публицисты, историки (Габдулла Тукай, Фатих Амирхан, Галимджан Ибрагимов, Кябир Бакир, Ибрагим Биккулов и др.). Фатих Амирхан в каждом номере размещал свои произведения или статьи. Например, его произведения «Гарәфә кич төшемдә» («Сон накануне праздника»), «Хәкарәт саналган мәхәббәт» («Любовь-унижение»), «Картайдым» («Постарел!») изначально напечатались в газете. Он также является автором многочисленных критических статей и рецензий. Самый активный период его творчества пришелся на 1907–1908 годы. Известно, что он публиковал статьи на актуальные для татарского общества того времени темы как под разными псевдонимами, так и без подписи. Например, известно, что вступительные статьи, написанные в газете в качестве редактора, печатались без подписи. Принадлежность данных статей перу Ф. Амирхана не вызывает сомнения, так как 25 ноября 1907 года в письме своему другу журналисту и педагогу Ризвану Алуши-Ибрагимову он написал: «Если “Альислах” дошел до вас, то считай, что вводные статьи и статьи за подписью “Дамелла” написаны рукой бедного друга Фатиха!». В этих статьях в основном рассматриваются вопросы ислама, медресе-мударрисов, шакирдов, образования и обучения, религии и национальности. Представленные статьи впервые печатаются на кириллице в текстологической обработке и с дополнениями.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, татарская литература, газета «Альислах», статьи.

The newspaper “Alislakh” played an important role in the history of Tatar literature as a periodical publication. The newspaper was published from October 3, 1907 to July 22, 1909 with a total of 68 issues. The official editor and publisher was Vafa Bakhtiyarov (1881–1960), but in fact the editorial work was led by Fatih Amirkhan (1886–1926). The publication was aimed at promoting the enlightenment of the Tatar people, the introduction of newfangled training programs and the expansion of national education. Many famous literary critics, publicists, historians (Gabdulla Tukai, Fatih Amirkhan, Galimjan Ibragimov, Kabir Bakir, Ibrahima Bikkulov, etc.) published their works in the newspaper. Fatih Amirkhan publishes his works or articles in each issue. For example, his works “Garafa kich toshemda”, “Hakarat sanalgan mahabbat”, “Kartaydym” were originally published in the newspaper and he is also the author of numerous critical articles and reviews. The most active period of his work was in 1907–1908. It is known that he published articles on topics relevant to

Tatar society at that time, both under different pseudonyms and without a signature. For example, it is known that introductory articles written in a newspaper as an editor were printed without a signature. There is no doubt that these articles belong to the pen of F. Amirkhan, since on November 25, 1907, in a letter to his friend, journalist and teacher Rizvan Alushi-Ibragimov, he wrote: "If you got "Alislah", then consider that the introductory articles and articles signed by Damella were written by the hand of Fatih's poor friend!" These articles mainly deal with the issues of Islam, madrasah mudarris, Shakirds, education and training, religion and nationality. In the period 1906–1912, the writer's work was characterized by the frequent use of Arab-Persian borrowings. The presented articles are printed in Cyrillic for the first time in textual processing and additions.

**Keywords:** Fatih Amirkhan, tatar literature, Alislakh newspaper, articles.

*Татар иҗтимагый хәрәкәтендә мөһим роль уйнаган «Әлислах» газетасы 1907 елның 3 октябреннән 1909 елның 22 июленә кадәр нәшер ителеп, барлыгы 68 саны дөнья күрә. Ул атнасына бер тапкыр, урта кулда, уналты битле булып чыга. Рәсми мөхәррире һәм нашире Вафа Бәхтияров (1881–1960) булса да, баш мөхәррирлек вазифасын, гамәлдә, Фатих Әмирхан (1886–1926) алып бара.*

*Газетада күп кенә әдипләр үзләренең әсәрләрен, тәнкыйть мәкаләләрен, милли мәгариф белән бәйле язмаларын бастыралар. Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Кәбир Бәкер, Ибраһим Бикколов һ. б. күренекле зыялыларыбызның мәкаләләре, тәнкыйди язмалары игътибарга лаек. Фатих Әмирхан исә һәр санда үз язмаларын урнаштырып бара. Аның «Гарәфә кич төшемдә», «Хәкарәт саналган мәхәббәт», «Картайдым» һ. б. исемдәге әсәрләре башлап газетада дөнья күрә, тәнкыйть мәкаләләре нәшер ителә.*

*Аның шул чор татар җәмгыяте өчен актуаль темаларга язган мәкаләләрен төрле тәхәллүсләр белән дә, имзасыз да бастыруы мәгълүм. Мәсәлән, «Әлислах»та редактор буларак язган кереш мәкаләләренең күбесе имзасыз. Әлеге мәкаләләрнең аныкы булуы шиксез, чөнки 1907 елның 25 ноябрендә дусты журналист, педагог Ризван Алуши-Ибраһимовка язган хатында ул: «"Әлислах" сезгә барып ирешкән булса, баш мәкаләләр вә "Дамелла" имзалы мәкаләләрне аяксыз дустым Фатих кулы белән язылган дип укырсың!» – дип искәртә. Кереш мәкаләләрнең күпчелегендә, нигездә, мәдрәсәләргә ислах, мәдрәсә-мөдәррисләр, шәкертләр, уку-укыту, милли мәгариф мәсьәләләре күтәрелә. Түбәндәге мәкаләләр текстологик яктан эшкәртелеп һәм астөшермәләр белән тулыландырылып, укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителә. Алар Институтның текстология бүлеге галимнәре тарафыннан әзерләнә торган Фатих Әмирханның алты томлы «Әсәрләр» академик басмасының 4 нче томында урын алачак.*

## Казан, 19 ноябрь

Быел августта һәрбер мәкятибе галияле[1] шәһәрләрдән килгән хәбәрләрдә университет вә башка югары мәктәпләрдә урыннар җитмәгән, керергә теләүчеләрдән фәкать бер кыйсеме генә кабул ителеп тә, калганнары кабул ителмәгәнлеге хәбәр ителәләр иде.

Бу елларда хөкүмәт тарафыннан ачылган гали мәктәпләр җитешмәгәнлек сәбәпле, частный мәктәпләр ачыла вә ачылган көне белән шәкертләр белән тулы буладыр. Бу елларда һәр җирләрдә хөкүмәт урта мәктәпләре җитешмәгән сәбәпле, берәр генә түгел, әллә ничәшәр урта мәктәпләр ачылды һәм уку хакының кыйммәтлегенә дә карамыйча, һәммәсе шәкертләр белән тулдылар. Шәһәремез Казанда гына да әүвәлдәге елларда ике мең кадәр университет студентлары урынына быел өч мең ярымнан артты, шул җөмләдән өч йөз ярымнан артыгы кызлар. Моннан ике ел әүвәл шәһәремездә 3 ирләр гимназиясе вә 3 кызлар гимназиясе вә бер реальное училище иделәр; әмма быел 6 ирләр вә 5 кызлар гимназиясе вә 2 реальное училище булды. Әүвәлдәге егерме, егерме биш университетка керү өчен имтихан тотучылар урынына, хәзер йөз вә йөз илле шуны теләүчеләр заһир булдылар. Әлхасыйль, сәяси вакыйгаларның тәэсире вә бу ике елдагы мәгыйшәтнең өйрәтүе буенча Русия яшьләре яңа гайрәт вә яңа иҗтиһад белән гыйлем вә мәгарифкә сәвекъ ителделәр[2], вә бөтен көчләрен шуңар сарыф итә башладылар! Әмма без – татарлар, нишләдек?

Менә бу сөальне кеше үз-үзенә биргәч тә, бер өмидсезлек вә бер кайгы басадыр.

Безнең яшьләремездә шул гайрәт, шул шук юкмыни? Башка халыкны мәгарифкә сәвекъ итә торган нәрсәләр безне сәвекъ итмиләрмени?

Ник безнең яшьләремез мәдрәсәләргә барып тулмыйлар? Ник безнең яшьләремез, билгакес, мәдрәсәләрдән таралып, аларны буш вә хәятсыз калдыралар?

Ник Русиянең башка җирләрендә мәктәпләрдә урын җитмәгәнлеген ишетеп тә, үткән ел өч йөз шәкерте булган мәдрәсәнең быел ике йөз генә шәкертле булганыны бөтен татар мәдрәсәләреннән хәбәр итәләр? Ник болар һәммәсе болай? Ник без дә башка кавемнәр шикелле бәхетле вә якты истикъбальле[3] түгел? дигән сөальләр бер ләхзада[4] бөтен калебләрне басадыр.

Вакыйган да, ник соң бу болай? Нәрсә моның сәбәбе? Менә шул мәсьәләләр хәзер безнең – татарларның бөтен уйлый алырлыкларыны ишгаль итәргә[5] тиештер.

Халкымызның халәте руханиясен, мәдрәсәләремезнең мәгыйшәтен вә шәкертләремезнең соңгы еллардагы хәрәкәтен вә яшьләремез-

[1] Мәкятибе галияле – югары мәктәпле.

[2] Сәвекъ ителделәр – юнәлделәр, алга этәрде.

[3] Истикъбальле – киләчәкле.

[4] Ләхзада – мизгелдә.

[5] Ишгаль итәргә – биләргә.

нең хәзердәге әфкяр вә мәкасыйдларын[1] белгән һичбер кеше шәкертләремезне хәят вә гайрәтсезлектә гаепли алмыйдыр, вә аларны зыя[2] вә мәгарифкә сәвекъ итмиләр, бөтен кайгымыз да шуннан килгән дип, тагый[3] дия алмыйдыр. Яшьләремез, башка кавемнәрнеке шикелле үк, укырга вә белергә сөяләр, башка кавемнәрнеке шикелле үк, истикъбальләрен вә хәтта халкымызның истикъбалене дә кайгырталар.

Алай булгач, ник башка халыкның яшьләре үз мәктәпләренә тулган шикелле, безнекеләр дә мәдрәсәләремезгә тулмыйлар, диярсез. Бу сөаль хаклыдыр. Ләкин җавабы да бик асат вә бер генә катлыдыр: мәдрәсәләремез заманның вә яшьләремезнең тәвәҗҗеһ иткән[4] урыннарына вә максудларына тәвәҗҗеһ итмиләр, гыйлем вә мәгърифәт урынына әхлаксызлык вә тәгассыб[5] кына биреп чыгаралар! Менә бөтен бәла кайда!

Менә бөтен мәгыйшәтемезне эштән чыгарган, вә бөтен сәгадәтемезне һәлак иткән, бөтен рәхәтемезне җуялткан вә бөтен истикъбалемезне һәлак иткән нәрсә кайда!

Шушы мәсьәләмезне хәяткә муафикъ сурәттә хәл итә алсак, милләтемез башындагы бик күп мәсьәләләр шуның белән бергә хәл ителәчәктер.

Вакыйганда, ничек вә ни өчен дип яшьләремез мәдрәсәгә тәвәҗҗеһ итсеннәр ки, алар күз алдыларындагы шул мәдрәсә йимешләрне – муллаларымызны күреп торалар – ул бичаралар гомерләренең иң саф вакытларын шул мәдрәсәләргә биргәннәр, әмма аңар каршы мәдрәсәләр аларга нәрсә биргән?

Күбесенең сыйххәтене җуялткан, төрле-төрле начар нәшьәләргә[6] өйрәткән, әхлакларын бозган вә сәдакачылыкка өйрәтеп, ялкау вә эш белми торган ясап калдырган, бөтен гомерендә бер тиенгә ярамаслык иске вә эштән чыккан мантыйк вә хөкүмәт-мәгыйшәт вә дөньяга нәзарны вөҗүдләренә сеңдергән, һич мәгыйшәткә татбикъ ителмәслек[7] мәкятиб, мөдир хөкемнәре белдерткән вә гомердә Коръән хәдискә татбикъ итмәү шарты белән ысулы фикъһ өйрәткән, сөйләшергә вә язарга вә хәтта вакыт хазирәмездәге нәрсәләрне укып аңларга да ярамаслык итеп гарәбчә өйрәткән, 6–7 гасыр моннан мөкаддәмге заманга татбикъ итеп бирелгән фәтваларны китаплардан эзләп табарлык икътидар[8] биргән, яхуд әхбарлары тарафыннан язылган кыйссалар белән тулы, мосаннифлары берәүгә мәгълүм булмыйча, бөтен тайибат[9] хәят дөньяны хәрәм дип кычкыра торган вәгазь китаплары белән миләрен

[1] Әфкяр вә мәкасыйдларын – фикерләр һәм максатларын.
[2] Зыя – яктылык, нур.
[3] Тагый – азгын.
[4] Тәвәҗҗеһ иткән – юнәлгән, мөрәҗәгать иткән.
[5] Тәгассыб – фанатизм.
[6] Нәшьәләргә – кәеф-хәтер хушлыгына.
[7] Татбикъ ителмәслек – яраклаштырылмаслык.
[8] Икътидар – көч.
[9] Тайибат – яхшы эшләр, күңел хуш күргән әйберләр.

зәһәрләгән, бөтен үзе белмәгән нәрсәләрне (ягъни, һәммә яхшыны) инкяр итәрлек тәгассыб һәдия иткән вә сыгыр печән чәйнәгән кеби (хәдис тәгъбире) мәгънан вә хикмәтен белмичә, борыннарына ияреп, Коръән җырларга (авыл халкы тәгъбире) әһда иткән[1] – менә мәдрәсәләрнең бөтен биргән нәрсәләре!!

Бу нәрсәләр хәл хазирәмездә – егерменче гасырда бер эшкә дә ярамаганлыкыны вә, билгакес, иясенә зарар гына китердегене игътибарга алсак, яшьләремезнең гыйлемгә шулкадәр һәвәсләре белән дә бу мәдрәсәләргә барырга теләмәгәнлекләрене бик яхшы аңлыймыз.

Мәдрәсәләремез бу халәттә торсалар, тиздән коры стеналар гына калып та, Бохаридан бик зураеп кайткан зур чалмалы мөдәррисләремезнең эчләрендәге иске хламларыны шул стеналарга гына чәчәргә кирәк булачагы шөбһәсез.

Шуңар күрә мәдрәсәләрне шул көенчә калдырыйк диючеләр – аларның шәкертләрене заһирән[2] куган шикелле итмичән генә куып бетерик тә, шулай итеп, мәдрәсәләрнең вөҗүденә хатимә[3] бирик диючеләрдер. Бу кешеләр мәдрәсәләрнең вә гомумән дә голүме диниянең тамырына төшкән кортлардыр.

Без бик яхшы беләмез ки, ул мәдрәсәләр шулай табигый үлемнәре белән үлеп бетсәләр, бер гасыр да үтмәс, аның урынына яңа вә заманның таләпләренә муафикъ сурәттә ясалган мәктәпләр вөҗүдкә килер, ләкин безне куркыта торган нәрсә: шуларның икесе арасында булган вакыттыр: искеләр бетәмез дип торганда яңаларның ибтидасе дә булмас – ярымгасыр түбән халкымыз – масса, бөтенләй мәктәпсез кала.

Бәлки дә ул ярымгасыр милләтемез өчен бик кыйммәткә төшәр? Менә шушы мөляхәзәдән наши[4] дә без, мәдрәсәләремезне мәвет[5] табигыйләренә калдырып, яңаларның вөҗүденә интизар иткәнгә караганда, хәзер дә мөмкин булган мәдрәсәләрне ислах итеп вә аның белән бергә яңаларның вөҗүденә сәгый[6] итүне муафикъ табамыз.

*(«Әлислах». 1907. № 7. 19 ноябрь)*

## Казан, 24 декабрь

Мәдрәсәләр галәмендә, шәкертләр хәрәкәте башланганнан бирле, бер кызык күренеш була киләдер. Шәкертләр мәдрәсәгә килеп, берничә ай торгач та, ягъни кыш уртасы җитеп, яз якыная башлагач та – мөдәррисләр шәкертләрне иске низам вә тәртипләр белән генә моннан соң канәгатьләндереп булмасына ышанып, төрле ислах ляихәләре[7] уйлап чыгара башлыйлар. Ләкин мондый вакыйгаларның

[1] Әһда иткән – бүләк итеп биргән.
[2] Заһирән – ачыктан-ачык.
[3] Хатимә – ахыр.
[4] Мөляхәзәдән наши – уйлаудан барлыкка килгән.
[5] Мәвет – үлем, вафат булу.
[6] Сәгый – тырышлык.
[7] Ляихәләре – тәкъдимнәре.

һәммәсендә ляихәләр, яз якынаюы сәбәпле, быел вөҗүдкә чыга алмаячак, киләчәк көз башыннан мәдрәсә фәлән-фәлән төрле ислах ителәчәк дип, шәкертләрне җуатып вә үзләре дә вөҗданнарына агыр газап булып яткан бу эшләрдән бераз бушанып калалар. Җәй көне «Дөррәтен-нәсыйхин»[1] моталәгә итеп[2] вә Мәккә-Мәдинәдән бәдәл[3] җыярга килгән төрле пуркиләр[4], әллә кай төшләрдән, диянәт сатып йөрергә килгән әллә нинди дамелла фәлән дә, дамелла төгәннәр белән мосахәбә вә мөзакәрә итеп, яңа ляихәләреннән үзләре курка башлап, көзгә кадәр яңадан ислах фикерләреннән тәүбә итеп, гөнаһларыннан пакьләнеп, мәгъсумият[5] хәлендә калалар. Бичара алданган шәкертләр дә авылда ата-баба вә карчыклардан ишетеп килгән вәгазьләре саясендә[6] мәдрәсәдә яңадан берничә айлар тыныч кына торып торалар. Кыш урталарына таба бу вәгазьләрнең әсәрләре беткәч, яңадан хәлләренең начарлыгыны төшенә вә яңадан ислах таләп итә башлыйлар. Мөдәррис җәнаблары да яңадан шәкертләрне бу тәртипләр белән икънаг итү[7] заманасы кичкән икәнене күз алдында күрә башлый: яңадан ляихәләр, киңәшләр, тагы әллә нәрсәләр башлана, яңадан гәзитә сәхифәләрендә мәдрәсәләр хәле вә фәлән мөдәрриснең ислах ляихәләре заһир буладыр.

Елдагы гадәтчә, бу хәл быел да заһир булды: Уфада мәдрәсәләрне берләштереп, бәгъзысыны – рөшдия[8], бәгъзысыны – игъдадия[9], галия[10] ясарга киңәшләр башланган.

Казанның Зәңгәр мәсҗед мәдрәсәсене[11] дә мәктәп рөшдия, игъдадия сыйныфларына аерырга карар биреп, быел соң булганлыктан, киләчәк елга кичектерелгән («Әлислах», номер 11), мәдрәсәи «Мәрҗания»не[12] дә ислах итәр өчен бу көннәрдә бер комиссия сайлаганнар.

---

[1] «Дөррәтен-нәсыйхин» («Нәсыйхәт сөйләүчеләрнең энҗеләре») – XIX гасырда халык арасында киң таралган дини-әхлакый китап.

[2] Моталәгә итеп – укып, өйрәнеп.

[3] Бәдәл – билгеле бер хакка ялланып, кеше өчен хаҗга барудат гыйбарәт гамәл.

[4] Пуркиләр – чакырылмаган җиргә сәдака алыр өчен соранырга яратучы кешеләр (гадәттә, шәкертләргә әйтелгән).

[5] Мәгъсумият – гөнаһсыз.

[6] Саясендә – ышыгында.

[7] Икънаг итү – ризаландыру, ышандыру.

[8] Рөшдия – башлангычтан югары (урта) мәктәп.

[9] Игъдадия – мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү сыйныфлары.

[10] Галия – югары белем.

[11] Казанның Иске татар бистәсендә урнашкан Зәңгәр мәчет каршында 1825 елда ачылган дини уку йорты, кадими «Халидия» мәдрәсәсе эшли. Исеме мәдрәсәне 1917 елда ябылганга кадәр җитәкләгән имамнар фамилиясеннән (Халитов) алынган.

[12] 1770 елларда Казанның Беренче җамигъ мәчете (хәзер «Мәрҗани» мәчете) каршында ачылган мәдрәсә, мөселман халыклары арасында абруйлы иң эре җәдит мәдрәсәләренең берсе. 1870 еллардан шунда укыткан дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, педагог, дин галиме ахун Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) исеме белән аталган.

Уфаның мәдрәсәи «Галия»сенә[1] дә корбан гаеденнән соң фән мөгаллиме китертмәкче булганнар ... илх[2]. Әлхасыйль, һәммәсендә ислах ляихәләре чыккан, быел вакыт соң булганлыктан, киләчәк елга калдырылыр. Җәй көне мәдрәсәләремез тагы тәүбә итеп куярлар, тагы киләчәк кыш уртасына кадәр искечә барыр. Аннан соң тагы ляихәләр чыгар! Яһу[3], кайчан бетәчәк бу комедияләр?!

Кайчан бер алга, бер артка атлап, бер урында тору урынына, акрын гына булса да алга, алга таба китәрмез?!

Мәдрәсәләрдә шәкертләрнең елдан-ел кимүләре, мәдрәсәгә кергәннәренең дә, ул иске фәннәргә хлам дип кенә карап әһәмият бирми башлаулары – менә болар һәммәсе фактлар (ма кянә[4]) бит! Боларга каршы күз йому, боларны игътибарга алмау башында ми кичмәгән (әфьюн белән) кешегә мөмкин түгел бит! Шәкертләргә кергән фикер вә яңа нәзарларны[5] бәддогалар[6], мәдрәсәләрдән куулар, аталарына әләкләүләр белән генә чыгарып булмаганыны һәр мөдәррис үзе тәҗрибә итеп белде, шуңар күрә канәгать итәргә тиеш иде бит!

Ләкин, мәгаттәәссеф, заманның бу сабаклары надан вә канына искелек сеңгән мөдәррисләремезгә бер дә тәэсирсез калган икән: алар һаман яшьләр, вә аларның гомерләре белән уйнарга телиләр вә заманның куәтле инкыйлабына каршы – тупка каршы, җиңенә таш төяп сугышырга теләгән җаһил бохарилар кеби башларындагы чүп-чарлары белән сугышмакчылар икән! Никадәр тәәссеф[7] ки, мөдәррисләремез тарихе гомумидән хәбәрсезләр. Без аларга коруне вөста[8] тарихыннан берничә вакыйгаларны хәтерләренә төшерер идек тә, алар да үз хәрәкәтләрен яхшырак аңлый башларлар иде!

Бу искелек сакларга тырышу – без татарларда гына булган нәрсә булмыйча, тарихта мисле бик күп мәртәбәләр сәбакать[9] иткән вакыйгадыр: коруне вөста католик руханиларының бөтен куәтләре белән гуманистларга (инсаният[10] вә яңа әфкяр тарафдарлары) каршы сугышлары вә хәтта бу сугышка католик хөкемдарлар вә мәмләкәтләр дә керешеп, гаскәр куәте белән яңа әфкярне таратмакчы булулары яңа фикер тарафдарларын инквизиция мәхкәмәсендә хөкем итеп, утларга ягулары, төрле газаплар белән турап үтерүләре – менә шушы кадәр тырышулар, шушы кадәр вәхшәтләр дә хөр фикерләр вә яңа мәгый-

[1] Уфа шәһәрендә 1906 елның октябрендә ачылган мәдрәсә, XX йөз башында татарлар һәм башка төрки мөселманнарның иң эре мәгърифәт учакларының берсе. Мәдрәсәне нигезләүчесе һәм җитәкчесе Зыя Камали була. Мәдрәсә дин әһелләре әзерләү юнәлешендә эшли, уку-укыту курсы якынча 30 фәннән торган.

[2] Илх – һәм башкалар.

[3] Яһу – «И Алла, я Алла» дигән мәгънәдәге сыгыну ымлыгы.

[4] Ма кянә – элеккечә, ничек булган булса шулай.

[5] Нәзарларны – фикерләрне, карашларны.

[6] Бәддогалар – явыз теләкләр, каргышлар.

[7] Тәәссеф – үкенү, ачыну.

[8] Коруне вөста – Урта гасырлар.

[9] Сәбакать – беренчелек.

[10] Инсаният – кешелек.

шәтне баса вә бетерә алмаганнар. Ул һаман галәбә иткән[1], ул дөньяда хөкем сөрә башлаган!

Менә шундый кечкенә генә бер мисалда, шулкадәр икътидарсыз[2], гайрәтсез безнең мөдәррисләремезгә яңалыкка каршы бу сугышларында мәгълүб[3] булачакларын күрсәтергә йитәр иде!

Шуңар күрә яшьләр вә аларның гомерләре белән уйнау заман вә якты мәгыйшәт тарафыннан гафу ителмәячәк икәнене белеп, йә әсаслы ислахка тотынырлар, яхуд көчләре йитмәслек вазифадан истигъфа итеп,[4] эш эшләрлек кешеләргә урын бушатырлар иде!

*(«Әлислах». 1907 ел. № 12. 24 декабрь)*

## Казан, 31 август

Без үткән номерда руханилар съезды хакында берничә сүз язып, аларның заман вә тарих кагыйдәләренә интыйбак итәргә[5] теләмәгәнлекләрен мисаллар белән күрсәтергә тырышкан идек. Хәзер безнең күз алдымызда татар мәгыйшәтендә безнең бу мөддәгыемезне[6] мөсбәт[7] вакыйгалар күренеп торалар.

Алып укыңыз «Вакыт» гәзитәсендәге мәдрәсәи «Хөсәения» игъланын; сезнең монда күрәчәк маддә вә кагыйдәләреңез һәммәсе бер әсаска – кешене көчләп мөтәдәйин[8] вә милли ясау әсасына мәбнадырлар[9].

Бу бер җөзьи мисал гына, бу фәкать йөз, мең вакыйгалардан берсен генә күрсәтә торган вакыйга. Әгәр без татар гомуми мәгыйшәтенә, хосусан мәдрәсәләр вә гаилә мәгыйшәтенә дикъкатьлечә карасак, боларның һәммәсендә шул ук әсас, шул тактика күрәмез: көчләп, орышып, сугып мәсҗедкә йөртү, көчләп, газапланып, әллә нинди калыпсыз киемнәр киеп йөрергә мәҗбүр итү.

Теләгәнеңез бер мәдрәсәне тотыңыз – монда мөдәррис вә хәлфә әфәнде, кулына чыбыркы вә таяк тотып, шәкертләрне мәсҗедкә куып йөри. Теләгәнеңез бер татарны тотыңыз – ул да баласын шул ук рәвештә мәсҗедкә куа. Ялкау шәкерт, мәсҗедкә барырга теләмәгән бала хәлфәдән, атасыннан качалар, калыр өчен гозерләр[10] эзләргә, ялганнар табарга тырышалар. Моннан чыга торган нәтиҗә бер генә, ул да: болар көчләгән нәрсәне дошман күрү, җаны белән аннан бизү, барса да, нифак[11] белән барып, файдасызга гомер заигъ итү[12].

---

[1] Галәбә иткән – җиңгән.
[2] Икътидарсыз – көчсез.
[3] Мәгълүб – җиңелгән.
[4] Истигъфа итеп – гафу үтенеп, хезмәттән азат ителеп.
[5] Интыйбак итәргә – килешергә, яраклашырга.
[6] Мөдәгыемезне – дәгъвабызны.
[7] Мөсбәт – уңай, исбат ителгән.
[8] Мөтәдәйин – диндар.
[9] Мәбна – нигезләнгән.
[10] Гозерләр – сылтаулар, сәбәпләр.
[11] Нифак – күз буяучылык.
[12] Заигъ итү – әрәм итү.

Милли кием мәсьәләсенә килсәк, ул да нәкъ шул ук вазгыятьтә тора: мине көчләп, үзем сөймәгән капчык эченә тыгып куялар, миллият исеменнән миңа җәй көне 30 градуслы эсседә эссе каракүл бүрек киеп йөрүне тәклиф итәләр[1], теләмәсәм, кыйнап кабул иттерәләр, нәтиҗә ни була; нәтиҗә бер генә: мин бу нәрсәләрне килештермәү генә дәрәҗәсеннән узып, дошман күрә башлыйм.

Мин әүвәлдән ялкаулыгымнан мәсҗедкә йөрми торган кеше, хәзер аны дошман күреп, ата вә хәлфә власте астында булганлыгымнан гына, мәҗбүри мәсҗед кошы булып, күз буяп йөри башлыйм.

Мин әүвәлдә татар гадәт вә киемнәрен, вкусыма килмәгәнлектән генә сөйми торган кеше, вәлиләр җәбере астында аны кия башлыйм, ләкин чын күңелем белән җирәнеп, бөтен татар гадәтләреннән хакыйкый бизеп, дошман күреп киям.

Әлхасыйль, мин кальбем белән камил урыслашкан, бөтен татарлыктан бизгән вә аны чын күңелем белән дошман күрүче булам.

Монда кем гаепле? Яшьләрнең бер кыйсемен бөтен татарлыктан биздергән кешеләр кемнәр?

Моның җавабы бер генә: монда көчләп диянәт[2] вә миллият кертергә тырышучылар гаеплеләр.

Диянәт вә миллият шикелле кешенең кәмаль[3] теләве белән генә чыгарга вә үсәргә мөмкин булган хиссиятне чыбыркы белән кертергә теләүчеләр гаеплеләр.

Диянәтне кешене ышандырып, вөҗданын мәгълүб итеп[4], чәчү урынына – кулларында әллә нинди куәт бар кешеләр шикелле грубый куәт белән чәчүчеләр гаеплеләр.

Бу бичаралар, үзләре дә белмичә, үзләренең хезмәт итәмез дип уйлаган фикерләренә вә аның чәчелүенә зарар итәләр. Болар, үзләре дә белмичә, диянәт вә миллият каршында иң зур гөнаһлы кешеләр булып калалар. Болар Коръән шәрифнең: «Вә җәдилһүм билләти һия әхсәнү»[5] фәлсәфәи җәлиләсенә[6] капма-каршы барып, хөкемен нәсех итмәкче[7] булалар!

Менә шуның өчен без бөтен руханиларны иске тәгассыбларын[8] ташлап, милләт хәлендә булмаса, фәкать үз хәлләрендә генә булса да, башларын йөртеп карарга өндимез.

Әгәр безнең бу дин хадимнәре руханиларымыз, аз гына булса да, үз хәрәкәтләрен ислам рухына татбикъ итәргә[9] теләсәләр, әгәр

---

[1] Тәклиф итәләр – кушалар, боералар.

[2] Диянәт – динлелек.

[3] Кәмаль – җитешкәнлек, тулы, бөтен.

[4] Вөҗданын мәгълүб итеп – вөҗданына каршы эшләргә мәҗбүр итеп.

[5] Мәгънәсе: «[Ислам диненең хак икәнен ачык күрсәтү өчен], кешеләр белән яхшы сүз белән бәхәсләш» («Нәхл» («Умарта кортлары») сүрәсенең 125 нче аятеннән).

[6] Фәлсәфәи җәлиләсенә – фәлсәфи бөеклегенә.

[7] Нәсех итмәкче – үзгәртмәкче.

[8] Тәгассыбларын – фанатизмнарын.

[9] Татбикъ итәргә – килештерергә, яраклаштырырга.

мәшәкать булса да, ислам әхкямнәренә[1] коры гадәтләр вә тәгаббедләр[2] дип кенә караудан ваз кичеп, диннең бер мәгълүм максат вә фәлсәфәи иҗтимагыягә хезмәт итә икәнчелеген аңласалар, дин әвамиренең[3] тәклифе[4] белән кертелмәячәк нәрсә икәненә исламның үзеннән дә мисаллар табарлар иде.

Сирка[5] өчен катгы йәд[6], шәраб, хәмер, зина өчен хәд[7] фарыз иткән ислам әвамир тугрысында һичбер андый җәзалар тәгъйин итмидер: намаз, зәкят, хаҗ, сумны әда итмәгән[8] кешеләр һичбер төрле дөньяви җәзага дучар булмыйлар.

Бу ни димәк? Җәзалар белән тәрк ителүе[9] матлуб[10] фигыльләрне тәрк иттерү максудына кыйсмән муафикъ булынса да, дөньяви җәзалар белән куркытылып кылдырылган нәрсәләр гыйбадәт түгел, бәлки тәзйигъ[11] гомер генә була димәк түгелме?

Католик инквизиторлары бөтен христианлык тарихын кызартырлык дәрәҗәдә түккән каннар белән католиклыкны күпме тәрәккый иттерделәр?

Менә без шуңар күрә дә татар руханиларына: «Әфәнделәр, әгәр сез үзеңез хезмәт итә торган мәсләккә вә аның алдында бик күп гакылларны тез чүктергән фәлсәфәләренә хакыйкать ышанасыз икән, аны кыйнап кабул иттерүне кирәксенмәңез, әгәр хакыйкать сез исламият, диянәт хамилары[12] буласыңыз килә икән, аны хөсне тәрбия вә аңлату белән нәшер итеңез, шулай гына булганда аннан максуд булган файда хасил була, вә шулай булганда гына ул «нифак» гонванынннан[13] чыгып, хакыйкый «диянәт» гонваны белән исемләнергә мөстәхикъ[14] буладыр» димез.

Менә хәзер мәдрәсәләрдә укулар башлана; шәкертләр кабул ителенә башлый, маддәләр төзелә, уку вә укытудан башка һәрнәрсәгә: сач, сакал, мыек, чалбар, бүрек, кәләпүш, ашау, эчү, хәлфәләргә итагать итү, мөдәррисләргә тәгъзыйм[15] вә инхина[16] итү, байларга нифак[17]

---

[1] Әхкямнәренә – хөкемнәренә, законнарына.
[2] Тәгаббедләр – диндарлыклар.
[3] Әвамиренең – әмерләренең, боерыкларының.
[4] Тәклифе – кушуы, боеруы.
[5] Сирка – урлау.
[6] Катгы йәд – кулны кисү.
[7] Хәд – чыбык белән сугу җәзасы.
[8] Әда итмәгән – үтәмәгән, түләмәгән.
[9] Тәрк ителүе – туктатылуы.
[10] Матлуб – таләп ителгән, соралган.
[11] Тәзйигъ – әрәм итү.
[12] Хамилары – яклаучылары.
[13] Гонванынннан – исеменнән.
[14] Мөстәхикъ – лаеклы, хаклы.
[15] Тәгъзыйм – олылау.
[16] Инхина – бөгелү.
[17] Нифак – әшәкелек.

вә мөдаһәнә кылу[1], мәсҗедкә чыгу, намаз уку илхларга[2] низам вә кагыйдәләр куела. Без нәрсәгә бу кагыйдәләр дип сорыймыз.

– Диянәт вә миллият рухында шәкерт тәрбия итәр өчен, – дип җавап бирәләр.

Без аларга: «Юк, ялганлыйсыз! Бу нәрсәләр белән мең ел бер генә кешене тәрбия итеп торсаңыз да, максудыңызга ирешә алмаячаксыз. Үзеңезнең хакыйкый мөселманнар җитештерүдән гаҗиз икәнеңезне каплар өчен күз генә буйыйсыз, чын диянәт урынына үзеңезнең Бохарадан ияртеп кайтканыңыз нифак орлыгын чәчәргә генә тырышасыз, диянәтне әллә нинди кагыйдәләр, мәдрәсәдән куулар, ата белән бала бозыштырулар белән сакламыйлар, аның белән чәчмиләр, бәлки вөҗдан тәрбиясе белән чәчәләр, ләкин аннан сез гаҗиз», – димез.

*(«Әлислах». 1908. № 43. 31 август)*

## Казан, 25 октябрь

Сентябрь 23 ендә мәдрәсәи «Хөсәения»дән 33 шәкерт «Буби» мәдрәсәсенә китте. Шулкадәр вәкыфлар, шулкадәр васыйлар[3], бай мөтәвәллиләр[4] белән матди җәһәте тәэмин ителгән, бөтен Русия татарлары күз тегеп торган бер мәдрәсә үзенең иң иҗтиһадлы шәкертләрен икънаг итә алмады[5]. Никадәр низамнар төзелгән: җөббә киюләр, чәч кырдырулар, мәсҗедкә йөрүләр фарыз вә илзам ителгән[6] бер мәдрәсәдә әллә нинди зур исемле, зур шөһрәтле мөтәвәллиләр тарафыннан идарә ителеп, бик күп нәрсәләр көтелә торган бердәнбер мәдрәсәдә никадәр мәшәкать сарыф ителгән вә никадәр хезмәт кертелгәннән соң, шәкертләрне икънаг итәрлек фән вә укытучылар табылмыйлар!

Моңар безнең милләтчеләремез ничек карасалар – карасыннар, безнең картларымыз мәгыйшәтнең бу күренешен нинди «фатиха» вә «бәрәкәт» белән тәгълил итсәләр[7] – итсеннәр, ләкин без моны үземезнең күптән сөйләп, язып килгән нәрсәләремезне ныгыта торган яңадан бер дәлил дип кенә ышанамыз. Бу мәдрәсәләр әсасларыннан ислах ителмичә, хәятымыз өчен яраклы һәм дәвам итәргә хаклы нәрсә була алмыйлар.

Мадам ки[8] мәдрәсәләр башында беркайда да голүме хәятия тәхсил итмәгән кешеләр тора; мадам ки алар уку, укыту эшеннән бигрәк, чәч, сакал мәсьәләләре, портнойлык эшләре белән иштигаль итеп, үзе алган тәрбия белән яшьләремезне дә черетмәкче булалар; ма-

[1] Мөдаһәнә кылу– икейөзлеләнү, ялагайлану.

[2] Илхларга – һәм башкаларга.

[3] Васыйлар – биредә: ярдәм итүчеләр.

[4] Мөтәвәллиләр – вәкыф эшләре белән шөгыльләнүчеләр, мәчет-мәдрәсә эшләрен башкаручылар.

[5] Икънаг итә алмады – канәгатьләндерә алмады.

[6] Илзам ителгән – өстен чыккан.

[7] Тәгълил итсәләр – сылтау күрсәтсәләр, сәбәп күрсәтсәләр.

[8] Мадам ки – чөнки, әгәр шулай икән, чынлыкта.

дам ки һәр эшемездә булган шикелле, мәдрәсә эшләремездә дә кода-кодагыйлык мөнәсәбәте иң мөхтәрәм урын ишгаль итә, мәдрәсәләр череп бетәргә мәхкүм[1], кызганыч, дарел-гаҗәзә[2] булуларында дәвам итәчәктерләр.

Рәхим итеп бер уйлап караңызчы: ни өчен Галим хәзрәт белән Рәхим кари[3] ул мәдрәсәне шулкадәр «үз» итәләр?

Ни өчен алар Әхмәд бай (Аллаһ рәхмәт итсен) вәкыфыннан истифадә итеп,[4] мәдрәсәне кәйфе йәшаә[5] тәсаррыф итү[6] икътидарына[7] маликлар? Нәрсә вә кем аларга ул хакны биргән дә, кемнәр бирергә үзләрен хаклы күргәннәр? Мәдрәсәгә мөгаллимнәр җитешми икән, аңар без дә ышанамыз, аңар шәкертләр дә ышаналар, алар да бүген безгә яңа мөгаллимнәр пешереңез димиләр. Мәсьәлә бары – мөгаллимнәр җитмәгәч, иҗтиһады вә мәхәббәте белән шәкертләргә үзен сөекле таныткан мөгаллимнәр ник куылалар? Ни өчен мөгаллимнәрне үлчәү Галим хәзрәт белән Рәхим карый кулына тапшырылып, бөтен эш фәкать кода-кодагыйлык хәтере өчен эшләнә? Мөгаллимнәр юк имеш? Әгәр мөгаллимлек вазифасы белән бергә Галим хәзрәтнең ризалыгын табу, аныңча йөрү, тору, киенү, уйлау шартлары да кушу, табигый, бер вакытта да фән укытырлык мөгаллим табылмас!

Әгәр бөтен татар малайлары гали образование алып чыксалар да, Галим хәзрәт шартларына риза булырлык «түбән», «үзләрен үзләре» тәхкыйрь иттерерлек[8] кешеләр табылмаслар. Һәм Ходай насыйп итсен дә, табылмасыннар. Ходай насыйп итсен дә, безнең зыялыларымыз арасында тарилкә ялаучы пуркилар[9] булмасыннар! Галим хәзрәт тә яхшы белсен: фән мөгаллимнәре, яшьләремезне тәрбия итәрлек мөгаллимнәр аның үлчәве шикелле тар үлчәү вә астында искелектән башка һич почвага малик булмаган үлчәүгә сыя алмаячаклар.

Әгәр мәдрәсәне халкымызның мәгыйшәте өчен файдалы итәргә теләсә, мөгаллимнәрне ул үлчәргә түгел, бәлки аңар караганда зыялырак мөгаллимнәрдән үзен үлчәтергә вә тулмаган җирләрен шуңар карап тутырырга тиештер.

Шәкертләр «Буби» мәдрәсәсенә киттеләр. Бу ни дигән сүз? Зур бер шәһәрнең электриклар белән яктыртылган, зур вәкыфлар белән тәэмин ителгән мәдрәсәсеннән бу хасиятләрнең[10] берсенә дә малик булмаган бер авыл мәдрәсәсенә баралар.

---

[1] Мәхкүм – хөкем ителгән.

[2] Дарел-гаҗәзә – көчсезләр йорты, картлар йорты.

[3] Кари –Коръәнне яттан укучы кеше.

[4] Истифадә итеп – файдаланып, кулланып.

[5] Кәйфе йәшәә – ничек телиләр.

[6] Тәсаррыф итү – кулда тоту, эшне идарә итү.

[7] Икътидарына – көченә.

[8] Тәхкыйрь иттерерлек – хурларлык.

[9] Пуркилар – чакырылмаган җиргә, ашка, мәҗлескә сәдака алыр өчен йөрүче, соранырга яратучы кеше.

[10] Хасыятьләрнең – үзенчәлекләрнең.

Соңгы мәдрәсәне әүвәлгесенә тәкъдим итәләр, әүвәлге мәдрәсәдә гомерләрен тәләф була[1] дип ышанып, гомерләрен коткарыр өчен шул бер кечкенә авыл мәдрәсәсенә качалар!

Шул бер, ике, өч гайрәтле, эшлекле зыялы татар яшьләре тарафыннан иҗад ителеп тә, аз бер микъдар акча белән идарә ителә торган мәктәпләр хәзер үзенә укырга тели торган яшь татарларны җәлеп итә, монда ни хикмәт соң? Бу нинди «фатиха» бәрәкәте соң? Менә бу сөальләргә җавап биргәндә, безгә бик күптән сөйләп язып килгәнемез сүзне үк әйтергә тугры киләдер: чөнки берсе зыялылар, хакыйкатән хезмәт итәргә тели торган зыялылар тарафыннан яңа мәгыйшәтне истикъбаль[2] өчен тәрбия итәлә, әмма икенчесе дә вәкыфларга урыннар кода-кодагый тирәсендә табылсын өчен, агай-эне хәтере кырылмасын өчен, мәгыйшәтнең киресенә таба монастырь уставы белән тәрбия ителәдер.

Без монда кариәләремезнең[3] дикъкатьләрен түбәндәге нәрсәгә җәлеп итәмез: картлар кулына тапшырылгач, матди җәһәте тәэмин ителгән мәдрәсә дә ни хәлгә калды. Эшлекле зыялылар эш башында булгач, кечкенә бер авылда бер-ике әһел һәммә саясендә[4] үзенә укырга теләүче яшьләрне җәлеп итәрлек мәктәп вөҗүдкә килеп, тәрәккый итте, итә һәм (халкымыз тәкъдир итә ала башласа) итәчәктер. Менә шуңар күрә дә без, **хәзер картларга урын бушатып, яшьләргә юл бирергә вакыт җитте!** дип бөтен татарга хитаб итәсемез[5] килә.

*(«Әлислах». 1908 ел. № 49. 25 октябрь)*

*Басмага әзерләде:*

***Зәйниева Гөлнара Нургали кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

*К печати подготовила:*

***Зайнеева Гульнара Нургалиевна,***

*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*gulnara.zaineeva@mail.ru*

[1] Тәләф була – әрәм була.

[2] Истикъбаль – киләчәк.

[3] Кариәләремезнең – укучыларыбызның.

[4] Саясендә – ышыгында, күләгәсендә.

[5] Хитаб итәсемез – мөрәҗәгать итәсебез.

УДК 398

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова,*
*А.Ә. Мөхәммәтҗанова*

# «КҮР УГЛЫ» ДАСТАНЫ СЮЖЕТЫНДА ВАРИАНТЛЫЛЫК, ТАРИХИЛЫК, ТРАДИЦИЯЛӘР ЯШӘҮЧӘНЛЕГЕ

Статья посвящена исследованию историчности, вариативности популярной среди многих народов эпоса о Кур углы. На основе анализа рукописных и изданных татарских текстов, относящихся к XIX в., а также вновь найденных в последние столетия текстов дастанных песен авторы проводят параллели между таджикскими, узбекскими, азербайджанскими, туркменскими, турецкими и татарскими версиями; выявляют их особенности; определяют значение в восточной филологии в целом, а также в истории мировой литературы и фольклора в частности; отмечают ценность факта существования дастана на татарском языке на этот известный сюжет. Авторы приходят к выводу, что татарский дастан не имеет ничего общего с историческими событиями, прототипами героев, описанными в восточных и западных версиях знаменитого эпоса, свои выводы аргументируют территориальной и этногенетической отдаленностью татар от всего происходящего в этих регионах и в их версиях эпоса. Татары полюбили это произведение из-за захватывающего сюжета, переработали его в соответствии со своими культурными традициями. Основная часть сюжета дошла до нас в форме книжного дастана, но в то же время авторы упоминают и о записанных у информантов устных вариантах и дастанных песнях из него. Как отголосок традиционной эпической культуры, татарская версия «Кур углы» является одним из ярких образцов для поэтапного изучения истории становления и формирования дастанного наследия народа.

**Ключевые слова:** ориенталистика, сюжет, вариант, история формирования, дастанное наследие, эпическая песня, культурные традиции.

The article is devoted to the study of the historicity and variability of the epic about Kur ugly, popular among many peoples. Based on the analysis of handwritten and published Tatar texts dating back to the 19th century, as well as newly discovered texts of dastan songs in recent centuries, the authors draw parallels between the Tajik, Uzbek, Azerbaijani, Turkmen, Turkish and Tatar versions; identify their features; determine their significance in Eastern philology in general, as well as in the history of world literature and folklore in particular; note the value of the fact of the existence of a dastan in the Tatar language on this famous plot. The authors come to the conclusion that the Tatar dastan has nothing in common with the historical events, prototypes of the heroes described in the eastern and western versions of the famous epic; they argue their conclusions by the territorial and ethnogenetically distant Tatars from everything that happens in these regions and in their version of the epic. The Tatars loved this work because of its exciting plot, and reworked it in accordance with their cultural traditions. The main part of the plot has reached us in the form of a book dastan, but at the same time, the authors also mention oral versions and dastan songs from the dastan recorded by informants. As an echo of traditional epic culture, the

Tatar version of "Kur ugly" is one of the brightest examples for the step-by-step study of the history of the formation and development of the dastan heritage of the people.

**Keywords:** oriental studies, plot, version, history of formation, dastan heritage, epic song, cultural traditions.

«Күр углы» исеме белән мәгълүм дастаннар Себер, Кавказ, Урта Азия һәм Казакъстанның, Якын Көнчыгыш һәм хәтта өлешчә Европаның төрки телле һәм башка халыкларында гаять популяр. «Күр углы» сюжетлы дастаннары төрекмән, үзбәк, таҗик, казакъ, каракалпак, азәрбайҗан, төрек, аҗар, абхаз, кумык, көрд, әрмән, грузин, гарәп, һ. б. халыкларда фольклор әсәре буларак билгеле. Кайбер сюжет уртаклыклары булса да, болар – һәр халыкта аерым бер үзенчәлеккә ия әсәрләр. «Кёр углы», «Кёроглы», «Кер углы», «Күр углы», «Кируглы», «Гёр углы», «Гёроглы», «Гороглы», «Гүр углы», «Гургули», «Гургули-шо» һ. б. исемнәр белән мәгълүм, дөресрәге, аталышы җәһәтеннән, нигездә, тел үзенчәлекләренә бәйле төрле фонетик яңгырашка ия дастаннарның шигърияте, стиле, күләме дә төрле. Әмма аларны берләштерә торган, боларның күпчелеге өчен характерлы уртак күренешләр бар. Һәр халыкта бу дастаннар – авторы билгесез ядкәрләр, ягъни эпик фольклор үрнәкләре.

Тарихта «Күр углы»ның популярлыгы шулкадәр зур булган, бу циклдан сюжетларның күплеге хәтта башка сюжетларны халык иҗатыннан кысрыклап та чыгарган. Әйтик, төрекмән-угызларның соңгырак чор дастани иҗатында атаклы «Алпамыш» яисә «Коркыт» дастаннары очрамый. В.М. Жирмунский моны нәкъ менә шушы сәбәп белән, ягъни XVII–XVIII йөзләрдән бередә милли каһарман турындагы «Күр углы» эпосының гаять киң таралыш алганлыгы белән аңлата [5: 167].

Татарларда «Күр углы» дастаны, аерым алганда аның В.В. Радлов тарафыннан язып алынган версиясе [14: 258–261] турында төрекмән галиме Б.А. Каррыев [7: 250–254], үзебезнең галимнәребез Ф.И. Урманчеев [15: 164–170] һ. б. ның фәнни мәкаләләре, шулай ук Радлов варианты һәм кулъязма вариантлары хакында М.И. Әхмәтҗанов [3: 186–192], Л.Х. Мөхәммәтҗанова [11: 135–161] монографияләрендә тулы мәгълүматлар бар.

Татарларга бу әсәр чагыштырмача соң – XIX йөз ахырларында гына килеп кергән. Башка халыкта беренчел чыганагы ашуг-озаннарга барып тоташкан дастан белән халкыбыз, нигездә, язуга теркәлгән текстлар аша танышкан һәм әлеге текстлар шушы сюжетка үз җирлегебездә яңа нөсхәләр барлыкка килүгә этәргеч биргән [12: 217]. Чыганагы белән башка халыкларда иң әүвәл авыз-тел әсәре булып, тора-бара язуга теркәлгән язма формалы эпоска барып тоташуы әлеге әсәрнең бездә китаби булып формалашуын турыдан-туры тәэмин иткән. Әмма сюжетның фольклорга бәйлелеген күрсәтә торган билгеләр язма текстта да, дастан традициясен бүгенге көндә дәвам итә торган эпик җырларда да чагылыш таба.

«Күр углы» версиясенең бездә иң күләмле, камил вариантлары чичән авызыннан түгел, кульязмалар булып, күчереп, китап басу чорында исә китаплар булып таралган. Шул ук вакытта соңгы елларда «Күр углы» дастаныннан эпик җыр буларак аерымланган текстлар да язып алына. Әйтик, «Кируглы җыры»ның («Күр углы» эпос-дастаныннан) бер варианты Казан дәүләт консерваториясе оештырган экспедиция вакытында 1998 елда Әстерхан өлкәсе Приволжск районы Татар Башмагы авылында Сәфәров Сәләхетдин Җәләлетдин улыннан (1934 елгы) язып алынган [13: 222–223]. Әлеге информантның шул ук дастаннан тагын бер җырны башкаруы мәгълүм, ул вариантның тулы исемен «Кируглы җыры» (Сиңа диеп килдем) дип күрсәтергә мөмкин. «Күр углы» дастаны сюжетына бәйле бу җырларда курку белмәс каһарман Күр углының башбирмәс холкы чагылыш тапкан:

Сиңа диеп килдем
Чандыбилемнән[1],
Синнән курыккан
Әнисеннән тумасын;
Үзем дисәм, тик төрекмән иленнән,
Синнән курыккан
Әнисеннән тумасын.
Мәйдан эченә җиттем,
Бәйгедә катнаштым,
Болгар атым ат каешны тирләтте;
Мин тордым, иңемдә кылыч уйнаттым,
Синнән курыккан
Әнисеннән тумасын!
(«Кируглы җыры»ннан) [13: 227].

«Күр углы» дастаны белән бәйләнешле мондый иҗатның булуы татарларда әлеге дастанның фольклор белән уртаклыгы әле дә дәвам итүне күрсәтә. Бүгенге көндә мөстәкыйльлеккә дәгъва кыла торган фольклор жанры – дастан җырлары арасында «Күр углы» дастанына бәйлеләре чын мәгънәсендә аерым урын алып тора. Асылда Әстерхан өлкәсендә яшәүче татарлардан язып алынып, алар – бүгенге көндә халык иҗатының сирәк, әмма шактый актив тел-авыз иҗаты мисаллары. Татарларда «Күр углы»на кагылышлы дастан вариантларының язмада сакланганнары белән бергә XIX гасырда В. Радлов [14: 258–261] Себердә язып алган сөйләмә характердагылары һәм әле бүгенге көннәрдә дә югалып бетмәгән дастан җырлары («Кируглы җыры», «Күруглы җыры») халкыбызда «Күр углы» сюжетына корылган әсәрнең язма мәдәниятгә дә, тел-авыз иҗатында да билгеле бер роль уйнавы хакында сөйли. «Күр углы» сюжетына татар вариантларының язма нөсхәләре күчерелеп һәм укылып йөргән дастаннардан саналса, дастан җырлары һәм телдән язып алынган вариантлары әсәрнең фольклор тамырлары хакында искәртә.

[1] Чандыбил – «Күруглы» дастанында эпик атама, урын; төрки версия һәм вариантларда «Чандыбил», «Чамлыбел», «Җанлыбил», «Чаглибил» кебек формаларда очрый.

Дастанның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт: Күр батыр исемле вәзир Истанбул патшасына көтүдәге бер биянең озакламый тулпар колынлаячагын хәбәр итә. Колын тугач, күк биянең әлеге кара колынчагын патша хуп күрми, аның тулпар булачагына ышанмый, шуңа Күр батырны сукырайтып җәзалый. Ә колынчак, бераз үсә төшкәч, чыннан да тулпарга әйләнә. Шуннан кызу канлы Күр батыр, улына кара айгырны җитәкләтеп, патша янына бара, аны каргый. Патшаның ачуы чыга. Күр һәм аның улы качалар. Күр батырның улы атасын патша эзәрлекләвеннән коткарып кала, үзе Шәмливил дигән шәһәрдә «егетләр башы булып, узган-барганны коткармый, кәрванны талап тора», ягъни байлар-солтаннарны талау һәм үтерү белән шөгыльләнә.

Күр углының бер төркем батырлар башлыгы Ага Чауз белән сугышуы һәм җиңүе, аның малын тартып алуы, ә үзен әсир итүе җентекләп тасвирлана. Янә бер картны талыйлар. Ул карттан: «Бу дөньяда улың юк, кызың юк килеш үләрсең», – дигән сүзләр ишеткәч, Күр углы Истанбул каласына чыгып китә. Юлда әсир төшкән Күр углын зинданга ябалар, Никар ханым аны коткара. Күр углы Бул бәк ханның сараена кереп, аннан бер кызны, кара атны урлап кача, куа чыккан Бул бәкне җәзалап үтерә. Даны илгә таралган Күр батырның кара атын тотып китергән кешегә Истанбул патшасы кызын вәгъдә итә. Хәйлә юлы белән бу эшне Хәзәл исемле егет башкарып чыга, әмма шул ук Хәзәл Истанбул патшасы ягында калмый, туйдан соң патша кызын, ягъни хатынын алып, Күр углы артыннан үзе дә кача.

Дастан каһарманы Күр углы – курку белмәс батыр, җитез җайдак, үтә катлаулы хәлләрдән дә шома чыга белүче, нинди генә көчле дошманны да җиңә алучы елгыр егет, оста оештыручы-җитәкче. Әмма шул ук вакытта бу егет – кеше үтерүче, талаучы куркыныч башкисәр, аны, атын тотып китерә алган кешегә кызын бирергә риза булып, Истанбул патшасы үзе эзләтә. Шуңа күрә бу яктан җинаятьчене аклап булмый кебек. Әмма Күр углы холкына, һәрбер дастан каһарманына хас булганча, намуслылык, вөҗданлылык та ят түгел. Әйтик, Никар ханым зинданнан коткаргач, Күр углының качып китү я яшеренеп яту мөмкинлеге була, ә ул бу юлдан китми. Егетлек алай булмас, ди, һәм, кире шәһәргә кайтып, дошманыннан каты итеп үч ала. Күр углының дошманнары – һәрвакыт социаль дошманнар, алар – бай кәрванчылар, ханнар һәм патша. Әлеге факт вакыйгаларның тамырына – Күр углының җинаятьче-батыр булып әверелү сәбәпләренә алып кайта. Чыннан да, каһарманның атасы Күрне хаксызга рәнҗеттеләр, шуның нәтиҗәсендә карт күзсез калды, иленнән качарга мәҗбүр булды. Рәнҗетүче – үзенең хакимиятеннән явыз файдаланган Истанбул патшасы. Дошманлыкның, явызлыкның сәбәбе әнә шул. Күр углы кылган гамәлләр үч кайтару мотивы белән башкарыла, шуңа да мантыйкый рәвештә аклана.

Дастанда Күр углы – үз егетләре-көрәштәшләре арасында зур авторитет. Һәрвакыт, һәр җирдә алар җитәкчеләренә ярдәмгә килергә әзер һәм бу бирелгәнлек көч кулланып түгел, фәкать Күр углының кодрәтен, чын батыр булуын тану бәрабәренә башкарыла. Дастанда

Хәзәл образы – Истанбул патшасы тарафыннан Күр улына аның кара атын алып кайту максаты белән җибәрелгән каһарман. Хәзәл Шәмливилгә килеп, Күр углына хезмәткә керә, Күр углының ышанычын яулый, соңыннан кара атны урлап кача. Күр углы, аны куа чыга. Юлда тегермән ишегенә бәйләнгән кара атын күреп, атыннан төшкән Күр углын Хәзәл төп башына утырта: кара атны ияртеп, Күр углы атланып килгән туры атка менеп, елгыр гына качып китә. Хәзәл белә: атын калдырса, Күр углыннан мәрхәмәт булмаячак, ә качып котылса, Истанбул патшасы аңа кызын бирергә әзер. Әлеге тактик алым Хәзәл өчен уңай, әмма ул Күр углы белән дә арасын бозмый, киресенчә, аны туйга чакыра, шунда кара атны кире кайтарырга вәгъдә бирә. Соңыннан, сүзендә торып, вәгъдәсен үти һәм алай гына да түгел, үзе дә, хатынын алып, Күр углы янына качып китә.

Әлеге эпизод дастанда төп каһарманның дәрәҗәсен күтәрә. Шул рәвешчә, Күр углы дастанда гаделлек өчен көрәшүче курку белмәс батыр образын гәүдәләндерә. Аның янында кырык көрәштәш егете һәм төрки эпосның аерылгысыз атрибуты – каһарман үзе генә ияр-ли ала торган тулпар аты бар. Эпос өйрәнү белемендә «Күр углы» сюжетлы дастаны версияләрен шартлы рәвештә көнбатыш һәм көнчыгыш версияләр дигән ике төркемгә бүлеп карау бар. Көнбатыш версияләр дигәндә – аҗар, төрек, азәрбайҗан, ә көнбатыш версияләр дигәндә, төрекмән, үзбәк, казакъ, таҗик эпик истәлекләре күздә тотыла. Көнбатыш версияләр көнчыгышныкыннан чынбарлык вакыйгаларын ышанычлырак яктыртулары белән күпмедер дәрәҗәдә аерылып торалар [9: 169–248; 1].

Дастанның күп кенә көнчыгыш һәм көнбатыш версияләре атаклы бахшылар авызыннан аларның музыкаль башкаруында язып алынган. Күпчелек версияләрнең иң зур өлеше тезмә текстан гыйбарәт. Әйтик, төрекмән версиясе импровизаторлардан – Мустак бахшы, Пәлван бахшы, Махтумкули бахшы, Бабаджан Сапаров, Нәдир бахшы, Овлиякули Гоч оглы һ. б. дан язып алынган. Алар әлеге күләмле текстны өлешләп-өлешләп көйләп әйтә торган булганнар [4: 7–32]. Азәрбайҗан ашугларының исә «Кёроглы»ны шигъри юлларны тезмәләр белән аралаштырып телдән әйтүләре мәгълүм [6: 166; 5: 643]. Үзбәкләрдә «Күр углы» дастанын әйтүче Абдулла-шаир, Фазил Юлдашев, Эргаш Джуманбулбул-оглы, Букок Пирмат, Мухаммедкул Джамрат-оглы (Пулкан-шаир) һ. б. импровизаторлар теркәлгән [6: 166; 5: 22–58]. Тыңлаучының ихтыярына бәйле рәвештә дастан ашуг, бахшы, шаирләр тарафыннан телдән башкарылган, эпос әйтү һәм аны тыңлау тулы бер мәҗлес сыйфатын ала торган булган.

Төрле халыкта гаять популярлык казанган «Күр углы»ның сюжет вакыйгалары нигезендә кайчандыр булган реаль хәлләр ята, төп каһарман образы тарихи шәхескә барып тоташа. «Күр углы» төрле халыкта фәнни яктан шактый җентекле өйрәнелгән, текстлары безнең көннәрдә кабат басып чыгарылган әсәрләрдән санала; эпос белгечләре әлеге сюжетны Азәрбайҗан һәм Кече Азия территориясендә барлыкка

килгән дип саныйлар [11: 232]. Дастанның азәрбайҗан, төрек һ. б. версияләрендәге төп вакыйгаларның XVI йөз ахыры – XVII йөз башында географиянең шушы өлешендәге җәләлидләр хәрәкәте белән тәңгәллеген раслый торган шактый зур материал да тупланган [10: 134–146]. Эпостагы кебек үк, җәләлидләр зур юлларда сәүдә кәрваннарына, үз дошманнарының шәһәрләренә һөҗүм иткәннәр, талау белән шөгыльләнгәннәр. Х. Короглы җәләлидләрнең төп массасы төрекмәннәр булган, дигән фикердә тора, аларның башлыгын – шагыйрьләр нәселеннән булган атаклы үч алучы Хәсәнбәкне телгә ала, фикерен Габбас I Сәфәвинең Искәндербәк Туркман исемле тарихчысы китергән фактларга таянып нигезли [10: 134–146].

Чыннан да, тарихта тасвирланган җәләлидләр чуалышы тикшерелә торган дастан вакыйгалары белән күп яклап аваздаш. Хәсәнбәк исеменең дастанның күпчелек версияләрендә шактый әһәмиятле фигура, ә Күр углының исә атаклы башкисәр булу белән бергә шагыйрьашуг буларак тасвирлануы да бик кызыклы. Әмма бу әле дастан версияләре шушы хәрәкәтләрнең турыдан-туры чагылышы дигән сүз түгел. Шулай булса да, эпосның үзәге Күр углы исемле мәшһүр зат һәм аның көрәштәшләре буыны дәверендә я бераз гына соңрак формалашкан булу фактын да инкяр итеп булмый. Фольклор процессына хас булганча, алга таба каһарман үзе дә, тарихи вакыйгалар да әкренләп эпиклашкан. Мәдәниятләре һәм этногенезлары төрле булган күп халыклар иҗатында бу эпос урын алганчы тагын берничә дистә, ә бәлки тагын да күбрәк еллар узган булырга мөмкин. Әмма дастан вакыйгаларына кагылышлы фактларның булган кадәре бу әсәр XVII–XVIII йөздән дә иртәрәк барлыкка килә алмаган, дигән нәтиҗә ясар өчен җирлек тудыра. Димәк, «Күр углы»ның татар халкына килеп керүе тагын да соңгырак чорга караганлыгы да раслана.

Эпосның төрекмән версиясендә («Гёроглы») вакыйгалар Азәрбайҗанның Иран белән чиктәш көньяк районнарында, каһарманның Чамлыбел дип аталган ныгытма-кальгасында бара. Дастандагы бу урын – төрекмәннәрнең теке кабиләсе яши торган Балкан иле. Төп каһарман да – төрекмәннәрнең әлеге кабиләсеннән. Күр углына багышланган дастаннарның күпчелегендә бу хакта искәртелгән. Күр углы Хункарга, ягъни госманлы төрекләре ягына барганда да, кире әйләнеп кайтканда да Аракс дигән елга аша үтә. Моннан тыш эпоста каһарманның Ширвән-Шемаха, Эрзурум һәм Грузия аша кичеп хәрәкәт итүе мәгълүм. Дастан вакыйгалары төрекмәннәрнең Урта Азиядән көнбатышка таба күченү юлларында бара. Дастан версияләрендә дә төп каһарманның башта ата-бабалары ватаны Төркестанда гомер итеп (монда игътибар дастан версияләрендә еш телгә алынган Болы провинциясенә юнәлә, бу – Төркиянең төрекмәннәр тупланып яшәгән урыны), биредә гаскәр җыеп, көч туплап, соңрак Азәрбайҗанның көньяк өлешенә күченеп яшәгәнлеге хакында сөйләнә. Болар барысы да эпосның башлап Кавказдагы һәм Кече Азиядәге төрекмән кабиләләрендә туган булу ихтималының зурлыгын раслый.

Димәк, дастанның төп каһарманы прототибы – теке кабиләсеннән чыккан төрекмән булып, XI гасырларда ук, ә бәлки тагын да иртәрәктер, сәлҗүкләр мәмләкәте составында Азәрбайҗанның таулы көтүлек далаларында яшәгән булырга мөмкин. XI–XII гасырларда Азәрбайҗан территориясендә яшәгән төрекмән-угызларның соңрак азәрбайҗан этногенезы формалашуда җитди роль уйнаган булу факты тарихтан моңа аңлатма була ала. Әмма соңрак бу образ җәләлидләр хәрәкәте вакыйгалары, шул чор реаль шәхесләренең игътибарга лаек гамәлләре нәтиҗәсендә тулылана төшкән, әсәр XVI йөзнең икенче яртысыннан соң формалаша башлап, тагын да соңгырак чорда героик эпос булып оешкан. Эпик үсә бару процессында каһарман образы үзенең тарихи прототибыннан бик нык ерагайган, әмма шул ук вакытта эпос тукымасында тарихилык белән бергә борынгылык барыбер сакланып калган. Дастан версияләре шушы серлелек синтезы белән кызыклы да.

Әлбәттә, төрле милли версияләр вакыйгаларны һәм төп каһарманны үз җирлегенә тартудан азат түгел. Әйтик, азәрбайҗан версиясендә теке-төрекмәннәр шактый үзенчәлекле рәвештә – Айваз һәм Рәйхан гарәпкә бәйле генә телгә алыналар, ә төрек версиясендә төрекмәннәр турында гомумән бер сүз дә юк. Дастанның тәүге версиясе йогынтысында туган соңгырак версияләрендәге мондый үзгәреш-үзгәртүләр үз версияләрен булдырганда килеп кергән җирле билгеләр булырга бик мөмкин. Моннан тыш дастанның төрле төрки версияләрендә топонимика бик нык бутап та бирелә. Әйтик, биредә бахшы үзенә таныш түгел шәһәр исемнәрен үзе теләгәнчә үзгәртә. Мәсәлән, Х. Короглы дастанның төрекмән версиясендә ике исем белән атала торган бер үк шәһәр (рәсми һәм халыктагы исемнәре төрле) турында ике шәһәр кебек сүз алып баруга игътибар итә. «Среди городов, – ди ул, – находящихся во владениях Хункара, упоминаются Испыхан, Нусбыджахан. Испыхан – город в центральном Иране; он был столицей Сефевидов. Нусбыджахан – определение этого города («Полмира»), данное ему народом» [10: 138]. Шулай ук эпоста төрек династиясен аңлата торган «госман» («осман») термины географик төшенчә буларак ныгыган.

Әмма дастанның төрки версияләрендәге күпчелек топонимнарның чынбарлыкта булуларын да инкяр итеп булмый. Чорына һәм урынына мөнәсәбәттә тарихта булып узган хәлләр, сәяси һәм дин дошманлыгы шулай ук дастанда чагылыш тапмый калмаган. Хулагуидлар (Азәрбайҗан территориясендә үзләренең төп базасын тоткан, башкаласы Тебриз шәһәре булган монгол империясе) идарәсеннән соң Дәрбәндтән Багдадкача территорияләрдә төрекмән-угызларның Ак Коюнлу һәм Кара Коюнлу исемле дәүләтләре барлыкка килә. Алар үзара гел көрәшеп-сугышып яшиләр. XV гасырда бу көрәштә Ак Коюнлу җиңгәч, җиңгән дәүләт Госманлы империясе белән сугыша башлый. Тарихта госманлы төрекләре белән үзара сугышлар алып барып яшәгән әлеге кабилә Кызылбашлар дигән исем белән мәгълүм [2]. Болар – исламның шигыйлык юнәлешендәге азәрбайҗаннар

һәм көнчыгыш иранлылар (икенче төрле әйткәндә, нишабурлар – Хорасанда (Иран) шул исемдәге шәһәр исеменнән) булганнар. Кызылбашлар белән госманлы төрекләренең тыныша алмаулары дүрт гасырга сузылганлыгы мәгълүм. Башта алар Кара диңгезгә чыгу, Көнчыгыш Анатолия җирләре өчен сугышсалар, XVI йөздән Шаһ Исмаил Сәфәви үткәргән шигыйлар инкыйлабыннан соң сугыш дини характер ала – шигыйлык һәм сөннилек байрагы астында алып барыла. Бик озак вакытны иңләгән бу сугыш тарихка кызылбаш-госманлылар сугышы яисә фарсы-госманлы сугышы дигән исем белән кереп калган. Урта Азия төрекмәннәре исламның шигый юнәлешен тоткан кызылбашларны үзләренең гомерлек дошманнары дип санаганнар.

Дастан версияләре шушы вакыйгаларга да һәрьяклап бик нык бәйле. Биредә баш каһарманның төп дошманнары – госманлылар һәм кызылбашлар. Дастанның төрекмән версиясендә төрек солтаны Хункар турында сөйләүче ашуг төрекләр белән кызылбашларны «берләштергән». Моны бахшының, тарихи нечкәлекләргә кереп тормый гына, төрекмәннәрнең дошманнары итеп гомумиләштерелгән җыйнама образ тәкъдим итүе дип аңларга кирәк.

Эпоста XVII–XVIII гасырларда төрекмәннәр яу чапкан күрше Иран шәһәрләре Нишапур, Сабзивар, Дамган, Тәһран еш телгә алына. Хункар белән сугышка әзерләнгәндә Күр углы, шура җыеп, төрекмән кабиләләрен дошманга каршы күтәрелергә өнди. Х. Короглы нәкъ шушы эпизодның XVIII йөз төрекмән язучылары Мәхтүмкули, иҗаты XIX йөзгә караган Молланепес әсәрләрендә дә очравын искәртә [10: 139]. Дастанны халыкка җиткерүче импровизаторлар ерак тарихтагы хәлләрне тасвирлау белән бергә сюжетка үз чоры вакыйгаларын һәм шәһәрләрен дә бик киң кертеп җибәргән. Дастанның төрекмән версиясендә, азәрбайҗан версиясенең ахырында һ. б. версияләрдә эпос өчен традицион ук, кылыч кебек кораллардан тыш утлы корал да телгә алына. Хункар гаскәренә каршы көрәштә Күр углы һәм аның яклы башка үч алучы халык вәкилләре шундый корал – туп, тупенг – кулланып сугышалар. Утлы коралның Урта Азиядә XIV йөз ахырында гына пәйда булып, эпоска аның XV–XVII йөзләрдә генә килеп кергәнлеге – ачыкланган мәсьәлә [5: 59]. Димәк, дастанда утлы корал белән эш итүне иркен тасвирлау шулай ук бахшыларның үз чоры казанышларын эпоска кертеп җибәрүләре буларак бәяләнә ала.

Моннан тыш «Күр углы» версияләрендә борынгы язма тарихи чыганакларда телгә алынган реаль шәхесләр белән тәңгәл образлар шактый. Дастанның көнчыгыш һәм көнбатыш версияләре Күр углының авантюраларга оста көрәшче булуы белән бергә ашуг булуын да искәртәләр. Әрмән тарихчысы Аракель Тавризский танылган музыкант, шагыйрь-импровизатор Кёроглу турында, аның соңрак дастанда да телгә алыначак көрәштәш-фикердәшләре Гизироглу, Косе Сафаре хакында язып калдырган. Аракельдә шулай ук билгеле шәхесләрнең «Юлга сыймас», «Тәңре танымас» дигән кушаматлары да теркәлгән [16: 87]. Шушындый ук исемнәр, кайберләре бераз үзгәргән

рәвешендә (әйтик, төрек версиясендә «Кабергә сыймас» дип үзгәртелгән исем бар) дастан версияләрендә дә очрый.

Гомумән, Күр углы исемле атаклы ашуг тарихи әдәбиятта шактый еш телгә алына. XVIII йөз төрек сәяхәтчесе Әүлия Чәләби, төрек солтаны хезмәтендә торган, шулай ук кызылбашлар составындагы мәшһүр шагыйрь-импровизаторлар турында сөйләгәндә, мәсәлән, бу исемне зур талантка ия популяр шәхес буларак тәкъдим итә, башка шагыйрьләргә бәя биргәндә аларны Күр углы (Кёроглы) белән чагыштыра [10: 141]. 1665 елда дәүләт эшләре белән бәйле сәяхәте вакытында Әүлия Чәләби һәм аның юлдашлары җәләлидләр хәрәкәте исеме белән мәгълүм крестьян чуалышларына юлыга. Әлеге талаучы банда Әүлия Чәләби төркеменә һөҗүм итә, банда башлыгы сәяхәтченең биленнән аның хәнҗәрен тартып ала. Шулвакыт Әүлия Чәләби: «Сез кылган явызлыкны бу урыннарда Гуроглы да кылмаган иде», – ди. Тарихчының «бу урыннар» дигәненең «Чардаглы – Чаглибил» дип аталган урыннар булуы аеруча әһәмияткә ия. Билгеле булганча, барлык версиядә шушы атамага аваздаш Чамлыбел – Күр углы урнашкан крепость, ә кайбер очракта хәтта ил буларак тасвирланган. Сәяхәтче бу территорияләрне Төркия биләмәләре буларак тасвирлый. Моннан тыш Әүлия Чәләби җәләлидләр башлыгы дип Чыгалыбәкне телгә ала, төрекмән-текеләр турында да мәгълүмат бирә. Билгеле булганча, төрекмән версиясендә Чыгалыбәк – Күр углының бабасы, ә Күр углы үзе – һәр версиядә диярлек төрекмән-теке кабиләсеннән.

Кеше исеме булудан тыш, тарихи чыганакларда «күруглы» исемле кабилә дә телгә алына. Бу хакта Х. Короглы түбәндәгеләрне яза: «Искандербек Туркман непосредственно не упоминает имени Кёроглу (или Гёроглы). Только в двух случаях он называет кёроглы как туркменский род из племени зулкадар. О туркменском роде кёроглы, жившем в Хорасане и Азербайджане, сообщает также историк XVIII в. Мирза Мехдихан» [10: 143]. Чыннан да, әлеге этноним «Күр углы»ның азәрбайҗан версиясендәге эпик җырда да очрый, биредә каһарман үзенең җиңелү белмәс күруглы кабиләсеннән булуын әйтә [8: 154].

Дастанда төп каһарман үзенең атасын сукырайткан өчен һәм халыкны тиран идарәсеннән коткару максаты белән шаһтан үч алучы буларак тасвирлана. Әсәр Күр углының фаҗигалы үлеме белән тәмамлана. Тарихи яктан караганда, биредә көнбатыш версияләрнең реаль вакыйгаларны, чыннан да, объективрак яктыртуы сизелә.

Төрекмән версиясендә Күр углы госманлы Хункар кешеләре кулына төшә һәм үтерелә. Төрек пашасы аның башын бөтен кеше дә күрә торган урынга элдертә.

Ә көнбатыш версияләре каһарман үлемен, тарихи детальләрне киң кулланып, бераз башкача тасвирлый. Күр углы, картлыгы якынлашканны сизеп, хатыны Нигяр белән, үзенең Чамлыбелдәге резиденциясен калдырып китеп барганда шаһ Габбас II Сәфәви сараена эләгә. Шаһ Күр углын үзенә хезмәткә чакыра. Героик эпос каһарманы буларак, Күр углы, әлбәттә, мондый тәкъдимнән баш тарта, хан

сараеннан чыгып китеп, юлын дәвам итә. Шаһ Габбас аны башка эзәрлекләмәскә вәгъдә биреп калса да, аларның артыннан куа чыгарга боера. Эзәрлекләп килүчеләр тигезсез көрәштә каһарманның атын – Гыратны үтерәләр, Күр углының башын кисәләр, баш тиресен салдыртып, эченә салам тутырып, Исфаханга алып кайталар.

Игътибар итсәк, Күр углына карата бу явызлыкны көнчыгыш версиядә – төрек солтаны, ә көнбатыш версиядә Сәфәвиләр, ягъни кызылбашлар династиясе вәкиле Габбас II кыла. Бу – көнчыгыш версияләрдә каһарманның дошманнарын бер-берсенә каршы гасырлар буе сугыш алып барган кызылбашлар һәм төрек солтаны белән фольклорча контаминациядә берләштереп, гомуми дошман образы барлыкка китерү алымы.

Ә төрек версиясенең Мырат Сертоглу вариантында исә Күр углы, куып килүчеләрнең үзенә ут ачуларын күреп, үзен үзе үтерә [17: 115–117].

«Күр углы» дастаны кайсы халыкта нинди генә тарихи вакыйгаларга бәйләп каралса һәм төп каһарман прототибы кем дип кенә расланса да, биредә тарихи дөреслекне ачыклау түгел, ә шушы гаҗәеп эпосның һәм аның версияләренең халык иҗатында булу факты үзе кыйммәт. Бу урында Х. Короглының әлеге әсәр версияләренең тарихилыгына мөнәсәбәттә нәтиҗә ясап әйткән сүзләрен китерү урынлы булыр: «Следует отметить, – ди ул, – что упомянутые в эпосе имена героев, хотя и обнаруживаются в том или ином контексте, однако нет надобности искать каких-либо прототипов героям или историческую основу сюжета эпоса. Эпос «Гёроглы» – подлинное народное творчество, отразившее героическую борьбу народа против своих угнетателей. Он вобрал в себя несколько исторических эпох многих древних тюркоязычных родов, вошедших впоследствии в племенное объединение огузов» [10: 145]. Дастанның төрле милли версияләрендә чынбарлык вакыйгаларының объективлыгы төрле дәрәҗәдә булуны да тарихилыктан эпиклыкка күчү процессында һәр версия кичкән индивидуаль юл белән аңлатырга мөмкин. Чынбарлык вакыйгалары хронологик, географик һәм этногенетик яктан ерагая барган саен аларның дастан версияләрендә чагылышы да тарихи әһәмиятен җуя төшкән.

Бу әсәрнең тарихи тамырларын барлау нинди генә нәтиҗәләргә китермәсен, бер хакыйкать бәхәссез булып кала: безнең халыкта да әлеге мәгълүм сюжетлы эпик текстлар бар һәм бу тарихи вакыйгаларның Идел буе татарларына һәм гомумән татарларга турыдан-туры катнашы юк. Татар халкында укылып-күчерелеп йөргән вариантлар алар – безнең халык рухи культура алмашып яшәгән мәдәниятләрдән язмача килеп кергән истәлекләр. Халкыбыз аны иң элек традицион китап культурасына омтылышы һәм әсәрнең мавыктыргыч сюжеты аркасында үз иткән, этноним, топоним, антропонимнарны үз фонетик үзенчәлекләренә яраштырып, әсәргә төрле үзгәртүләр, кыскартулар керткән. Татар вариантлары күләме белән көнчыгыш һәм көнбатыш версияләр кебек зур түгел, алар белән чагыштырганда, сюжет

системасы да күпкә җыйнак, һәм, әлбәттә, ашуг-озаннар тарафыннан башкарылмыйча, асылда язма формага нигезләнгәннәр. Нәтиҗәдә, популяр дастанның безнең халыкка хас китаби үз версиясе хасил булган. Татар версиясе өчен иң әһәмиятлесе дә әнә шул – дастанны башкалардан үзгә рәвештә кабул итү һәм аның таралыш формасы.

Шул ук вакытта уртак сюжетның тарихилыгына күзәтү ясау безнең версия-вариантларга да шактый ачыклык өстәве белән әһәмиятле. Татар вариантларында сөйләнгән вакыйгалар, биредә теркәлгән топонимик һәм антропонимик мәгълүматлар тарихи вакыйгаларга һәм башка версияләрдә чагылган эпизодларга таянып, аларга нисбәтән тикшергәндә генә бөтен тулылыгы белән ачыла. «Күр углы»ның татар вариантлары да, башка кардәш халык версияләре кебек үк, реаль вакыйгаларга бәйле булуы белән гаять дәрәҗәдә кызыклы. Моны дастанны күчереп таратучылар да, аны укыган затларыбыз да тәгаен белгән, аңлап эш иткән булырга тиеш.

Дастанның татар халкында таралган вариантлары көнчыгыш һәм көнбатыш версияләр дип карала торган төркемнәрдән һәрвакыт читтә кала килде, әлеге сюжетка бездә дә берничә вариантта эпик әсәр сакланган булуга һәм бүгенге көндә дә чагыштырмача актив иҗат – Күр углына багышланган дастаннан эпик җырларның яшәп килүенә игътибар аз юнәлтелде. «Күр углы»ның төрекмән, таҗик, үзбәк, казакъ яисә азәрбайҗан, төрек версияләре тематик яктан бер-берсе белән бәйләнмәгән дистәләгән, хәтта берничә дистә мәҗлестән (хикәяттән) гыйбарәт, бу хикәятләрне төп каһарман Күр углы һәм башка каһарманнар, аларның язмышлары уртаклыгы бер әсәр итеп туплаган. Татар версиясе мондый мөстәкыйль циклларны берләштерә торган әсәр дип каралмаса да, халыкта аның булу факты тарихи, әдәби-мәдәни, географик җәһәттән бик күп нәрсә турында сөйли. Бу мәшһүр эпосның татарларда сакланган һәрбер варианты (күләмле нөсхәләреннән алып дастан җырларына хәтле) Урта Азия версияләре кебек үк, эпик фольклор традициясе инде тәмам ныгып, жанрның үз милли үзенчәлекләре ахыргача формалашып беткән чор ядкәрләре һәм шул чорның кыйммәтле эпик кайтавазы.

**Әдәбият**

1. Азербайджанцы: историко-этнографический очерк. / URL: http://www.myazerbaijan.org/index.php?p=history/27 (мөрәҗәгать итү көне: 26.11.2024).

2. Азербайджан – Википидея. Материалы из Википедии – свободной энциклопедии. / URL: http://ru.wikipedia.org/wiki (мөрәҗәгать итү көне: 27.11.2024).

3. *Әхмәтҗанов М.И.* Татар кульязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр, 2000. 270 б.

4. Гёр-оглы. Туркменский героический эпос. М: Гл. ред. вост. лит., 1983. 806 с.

5. *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. 728 с.

6. *Жирмунский В.М., Зарифов Х.Т.* Узбекский народный героический эпос. М.: Гос. изд-во худ. лит., 1947. 520 с.

7. *Каррыев Б.А.* Эпические сказания о Кер-углы у тюрко-язычных народов. М.: Наука, 1968. 260 с.

8. Кероглу. Пер. с азерб. / Акад. наук АзССР. Ин-т литературы и языка им. Низами. Баку: Изд-во Акад. наук АзССР, 1959. 388 с.

9. *Короглы Х.Г.* Героический эпос «Кёроглы» // *Короглы Х.Г.* Взаимосвязи эпоса народов Средней Азии, Ирана и Азербайджана. М.: Наука, 1983. 336 с.

10. *Короглы Х.Г.* Туркменский эпос «Героглы» и особенности его историзма // Специфика фольклорных жанров. М.: Наука, 1973. С. 134–146.

11. *Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АНРТ, 2014. 380 с.

12. *Мухаметзянова Л.Х. Мухаметзянова А.А.* Регионы бытования эпоса-дастана «Кур углы»: особенности татарских вариантов // Традиционный и современный фольклор народов Волго-Уралья. Материалы Межрегиональной науч.-практ. конф., посвящ. 100-летию фольклориста И.И. Одюкова. Чебоксары, 2024. С. 216–221.

13. Памятники татарского народного музыкально-поэтического творчества. Вып. 1. Песни Астраханских татар. Әстерхан татарлары җырлары / сост. и нот. транскр. Е.М. Смирновой и Н.Г. Гайнуллиной. Казань: Казанская консерватория, 2007. 552 с.

14. *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи, ч. IV. Наречия барабинцев, тюркских, тобольских и тюменских татар. СПб., 1872. 528 с.

15. *Урманчеев Ф.И.* Героический эпос татарского народа. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 312 с.

16. *Brosset M.F.* Collektion D·Historiens Armeniens. V.1. St. – Petersbourg, 1874. 710 p. URL: https://archive.org/details/collectiondhist00arhagoog/page/n1/mode/2up (мөрәҗәгать итү көне: 5.12.2024).

17. Koroglu destani. Istambul: Partev Naili, 1931. 336 s.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

***Мөхәммәтҗанова Алинә Әсгать кызы,***
*Казан федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр институтының «Көнчыгышны өйрәнү һәм африканистика» юнәлешендәге 3 нче курс студенты*

***Мухаметзянова Лилия Хатиповна,***
*доктор филологических наук, доцент, главный научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

***Мухаметзянова Алина Асгатовна,***
*студент 3 курса по направлению «Востоковедение и африканистика» Института международных отношений Казанского (Приволжского) федерального университета*

*lilmuhat@mail.ru*

УДК 94(47)

*И.К. Заһидуллин*

# ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ МӘДӘНИ МИРАСЫ БУЛАРАК ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН МӘЧЕТЛӘРЕ ТАРИХЫН ЯЗУНЫҢ КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Статья посвящена определению актуальности сбора источников для написания историй современных сельских мечетей, возведенных в 1990–2000-е гг. и их жизнедеятельности в последующие десятилетия. При разработке его методики рекомендуется обращать пристальное внимание на практику составления аналогичных текстов известным татарским богословом, муллой и историком Ш. Марджани. Для реконструкции историй татарских мечетей имперского периода выделяются их основные общественные функции, характеризующие богослужебные здания в качестве духовно-религиозных центров местных приходов.

**Ключевые слова:** Духовное управление мусульман Татарстана, современные татарские мечети, методика исследования современного культурного наследия мусульман России, Ш. Марджани.

The article is devoted to determining the relevance of collecting sources for writing the histories of modern rural mosques built in the 1990–2000s and their life in the following decades. When developing its methodology, it is recommended to pay close attention to the practice of compiling similar texts by the famous Tatar theologian, mullah and historian Sh. Marjani. To reconstruct the stories of Tatar mosques of the imperial period, their main social functions are highlighted, characterizing religious buildings as spiritual and religious centers

**Keywords:** Spiritual Administration of Muslims of Tatarstan, modern Tatar mosques, methods of researching the modern cultural heritage of Muslims in Russia, Sh. Marjani.

Соңгы 30–35 елда Татарстанда мөселманнарның дин хокукларын тормышка ашыруны гамәлгә кую һәм дини инфраструктура булдыру өлкәсендә зур уңышларга ирешелде. Бу – дини оешмалар, иганәчеләр, ислам активистлары һәм хакимиятнең максатчан һәм аңлашып эшләүләре нәтиҗәсе.

Бүген мөселманнарның мәдәни казанышлары исемлегенә 1400 дән артык мәчет, дини уку-укыту системасы һәм аның институтлары, нәшер ителгән дини уку әсбаплары, әдәбият һ. б. керә.

Соңгы елларда республикабыз авылларында юбилейлар гөрли: хәзерге заман мәчетләренең 20, 25, 30, 35 ел элек ачылуларына багышланган бәйрәм чаралары зур күтәренкелек белән үтә. Гадәттә, 20 ел элек төзелгән мәчетләр бәйрәмнәрендә авыл халкы һәм чакырылган мөхтәрәм кунаклар катнашында тантаналы җыелыш һәм чәй табыны оештырыла, мәчет төзелешендә катнашкан кешеләргә бүләкләр бирелә, вафат булганнар рухына догалар укыла һ. б. Чыгыш

ясаучылар авыл халкын рухи берләштергән вакытларны, мәктәп һәм клуб янәшәсендә калкып чыккан гыйбадәтханә бинасының ничек итеп үзләренең тормышына тәэсир итүен, балаларның, хатын-кызларның мәчеткә укырга йөри башлавын искә ала, дини тормышны оештыруга бәйле башка истәлекләр белән уртаклаша.

Ирексездән, бүген барын да беләбез, тагын 10 елдан берни дә хәтерләмәячәкбез, дигән күңелсез уй килә.

Моның шулай икәнен 30 һәм 35 еллык юбилейларын билгеләп үтә торган мәчетләрдә үткәрелгән бәйрәм чаралары раслап тора. Бәйрәмгә килгәннәр арасында мәчет төзелешенә үз өлешләрен керткән пенсионерлар, шулай ук беренче имам, мәзин булып торган өлкән буын кешеләре инде калмаган диярлек. 30–35 ел элек булган вакыйгалар турында аларның балалары өзек-өзек итеп булса да сөйләргә омтыла. Чарага җаваплы караган кайбер китапханә хезмәткәрләре гыйбадәтханә төзелгән вакыттагы һәм мәчет ачылу тантанасыннан фоторәсемнәр табып, алардан презентация күрсәтә. Ышанып әйтергә була: бу авылда киләчәк буыннар өчен шушы фотосурәтләр генә калачак.

Татарда, кыргыз яки казакълардан аермалы буларак, тарихи хәтер телдән телгә сөйләп түгел, ә язма рәвештә теркәлеп барган. Шул сәбәпле Татарстанда ислам күтәрелешен тәэмин иткән хәзерге заман мәчетләренең тарихын язу мәсьәләсе көн тәртибенә басты.

Юбилейлар биш ел саен әйләнә дә килә, әйләнә дә килә. Менә шушындый зур һәм күркәм бәйрәмнәрне үткәргәндә, килгән кунакларга бүләк итеп 5–10 битлек мәчет һәм мәхәллә тарихы язылып тапшырылса иде, яисә юбилей тантанасы шундый китапчыкны язу өчен этәргеч булсын иде. Сүз, беренче чиратта, 1990–2000 елларда мәчет төзү фикерен күтәреп чыккан һәм шуны тормышка ашыру юлында тырышлык куйган, мәчет эшчәнлеген тәэмин иткән һәм укытуда, укуда һ. б. өлкәләрдә активлык күрсәткән кешеләрнең исемнәрен барлау һәм алардан язма рәвештә, аудио- яки видеоязмаларда истәлекләр туплау, район газетасын, гаилә фотоальбомнарын өйрәнеп, ул заман авыл кешеләренә кагылышлы, шулай ук имамнар, мәчет, дини мәктәп һәм мәхәллә турында чыганакларны барлау турында бара.

Мәсьәләнең тәрбияви ягы булуны да искәртеп үтү мөһим.

Ш. Мәрҗани һәм Р. Фәхреддин хезмәтләрендә мөселман җәмгыятенә хезмәт иткән дин әһелләре, иганәчеләр һәм башка шәхесләр турындагы язмалар бу кешеләрнең нәсел дәвамчылары өчен зур горурлык чыганагы булып тора. Хәзерге заман авыл мәчете һәм мәхәлләсе турында китаплар да – яңа буын мөселманнарына бүгенге заман каһарманнарын – дин юлында хезмәт куйган туганнарының игелекле гамәлләрен белергә, алар белән горурланырга мөмкинлек бирүче чыганак. Мондый китапны укыган кешеләр туган авыллары мәчетен гыйбадәт йорты дип кенә түгел, ә әби-бабасы, әти-әнисе катнашында төзелгән, аларның хәләл хезмәте һәм күңел җылысы кергән җәмәгать бинасы дип кабул итә.

Бүген Татарстанда эшләп килүче мәчетләрне XVIII гасырның икенче яртысында – XX гасыр башында төзелгән һәм бүгенге заман гыйбадәтханәләре дип, ике зур төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Беренче төркем мәчетләр тарихы СССРда гыйбадәтханәне ябуга һәм аннан соңгы чорга һәм хәзерге заманга, бинаны мөселманнарга кайтарып биргәннән соңгы этапларга бүленә.

Беренче этап ике сәяси чорны: империя һәм совет хакимиятенең беренче 10–20 елын колачлый. Татарстанда сакланып калган тарихи мәчетләр Казан һәм Чистай калаларында, бер дистә чамасы авылларда урнашкан.

Тарихи мәчетләр һәм бигрәк тә хәзерге заман мәчет-мәхәллә тарихларын язганда күренекле дин галиме һәм имам Ш. Мәрҗани тәҗрибәсе игътибарга лаек.

1885 елда нәшер ителгән «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабының беренче томы татар халкының борынгы һәм Урта гасырлар чорын тасвирлый.

Китапның 1900 елда бастырылган икенче томында түбәндәге темаларга багышлаган материаллар бар: Казан каласының мәчетләре һәм хәрби имамнар; авыл мәчетләре (хәзерге Кукмара, Балтач, Арча, Әтнә һәм Саба районнарына кергән 13 авыл); Казан һәм Болгарга мөнәсәбәте булган соңгырак чор төбәк һәм чит төбәкләрнең голәмалары (83 кеше); Оренбург мәхкәмәи шәргыясе, аның 5 рәисе (мөфтиләр) һәм Казан губернасы руханилары тарафыннан 3 елга сайланган казыйлары; Чистай шәһәре (муллалар); Мәкәрҗә (Түбән Новгород) ярминкәсе мәчете һәи ярминкә имамнары, Оренбург мәчетләре һәм имамнары; Казан татар ратушасы һәм аның 10 җитәкчесе; башка күренекле шәхесләр (Казанның күренекле 30 кешесе).

Шул рәвешле, «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»-ның икенче томы тулысы белән диярлек төбәк тарихы һәм мәчет-мәдрәсәләргә һәм имамнарга багышланган. Бу – һичшиксез, татар тарихы. Чөнки галим яшәгән традицион җәмгыятьтә татар иҗтимагый фикере дини эчтәлекле булган, аны руханилар булдырган, ә муллалар татар халкының интеллектуаль элитасын тәшкил иткән, мәдрәсәләр һәм мәчетләр иганәчеләр хисабына эшләп килгән.

Мәрҗани хәзрәтнең тарихчы-эзләнүче буларак башкарган гамәлләре өч этапка бүленә. Ул, мәчетләр тарихын язарга дигән фикергә килгәч, беренче чиратта, үткәннәр хакында хәбәрдар өлкән яшьтәге кешеләр, мәчетләрне төзегән шәхесләрнең нәсел дәвамчылары белән очрашып, гыйбадәтханәнең төзелгән һәм ачылган вакытын, беренче муллаларын ачыклаган; мәчетләргә барып, анда сакланган кәгазьләрне өйрәнгән, муллалардан сораштырган, аларның шәхси архивлары белән танышкан һ. б. Ул туплаган мәгълүматның бер өлеше, бәлки әле күбесе, башкалар хәтердән сөйләгән яки язып биргән чыганаклардан тупланган дип фаразлыйбыз.

Мәчетләр тарихын өйрәнү фикере Урта Азиядән кайтып, 1849 елда Казанның беренче мәхәлләсенә мулла булып килгән Ш. Мәрҗанигә,

әлбәттә, шул ук елны килмәгәндер. Димәк, моңа ниятләгәч, ул үзе мулла булып торган елларда Казан шәһәрендә һәм тирә-як авылларда булган вакыйгаларны искә төшереп, кәгазьгә теркәп куйган.

Алдагы елларда, эзләнүләр алып бару белән бергә, булачак китабына материал булыр дип, елъязмачы сыман, үзен кызыксындырган калаларда һәм салаларда булган игътибарга лаеклы вакыйгаларны теркәп барган.

Аның «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабының икенче томы шул рәвешле язылган.

Ни өчен Мәрҗани фәкать 13 авылның мәчет-мәхәлләсе һәм руханилары турында язу белән чикләнгән соң?

Моның төп сәбәбе – чыганаклар җитмәүдә.

Авыл мәчетләренә багышланган бүлектә кайбер торак пунктлар тарихына кагылышлы хәбәрләр дә урын алган. Автор авылларның географик планда урнашкан урыннарын төрлечә тасвирлый: нинди елга буенда утыра (Ташкичү, Хөснә, Ашыт авыллары турында), Казаннан кайсы яктан һәм нинди ераклыкта урнашкан (Мәрҗан, Мазар Башы, Түнтәр авыллары), кайсы өязгә карый (Байлар Сабасы).

Авыл тарихына кагылышлы өзек-өзек мәгълүматлар китерә: авыл исеменең килеп чыгышы турында версияләр (Хөснә, Мазар Башы), аңа нигез салучылар һәм аларның нәсел дәвамчылары (Ташкичү, Мәчкәрә, Мазар Башы), авылда бай кешеләрнең күп булуы (Кышкар, Мәчкәрә), базар һәм кибетләр төзелү (Ашыт).

Китаптагы беренче өч авыл – Шиһабетдин хәзрәтнең нәселнәсәбе белән бәйле торак пунктлар: Ташкичү мәчетендә этисе Баһаветдин 40 ел муллалык икән, Хөснәдә бабасы Собхән рәсми рәвештә 1801–1809 елларда имам-хатыйп булып хезмәт иткән, аннары сәүдә итүгә күчкән, Мәрҗан авылында Шиһабетдин хәзрәтнең Комыргуҗа авылыннан күчеп килгән Габделкотдус бабасы нәселе тамырланган [2: 108, 110–111]. Гаиләдә туганнар хакында даими сөйләшкәннәр, ниндидер кулъязмалар да сакланган, ягъни Шиһабетдин бала чактан бу өч авыл турында мәгълүмат туплап килгән икән.

Шунысы кызык: Мәрҗани китабында урын алган 13 авылдан берсенең – Вятка губернасы Малмыж өязенә кергән Түнтәр авылының гына – мәчетләре турында мәгълүмат юк. Бу хакта чыганаклары булмаганлыктан, Мәрҗани хәзрәтләре андагы дин әһелләре хакында язу белән чикләнергә мәҗбүр булган.

Автор язган унике авылның тугызында (Ташкичү, Бәрәскә, Мәчкәрә, Корса, Кышкар, Ор, Олы Мәңгәр, Байлар Сабасы, Мазар Башы) таш мәчетләрне, тагын ике авылда (Ашыт һәм Хөснә (Кысна)) агач мәчетләрнең берсен байлар төзеткән. Нәсел нигезе дип санаган Мәрҗан авылы мәчетләре хакында ул гаиләсендә сөйләшкәннәрдән һәм замандашларыннан белешеп язган [3: 225–232].

Ш. Мәрҗани Казан губернасы авылларындагы барлык таш мәчетләр тарихын язып чыккан дип әйтергә мөмкин. Ул заманда авылларда зур чыгымнарга барып таш мәчетләр эшләтү гайре табигый, яңа

күренеш булган. Автор биредә мәчет муллаларыннан, өлкәннәрдән ишеткән мәгълүматны һәм үзе шаһит булган вакыйгаларны файдаланып бәян итә, ислам дине өчен малларын кызганмаган дин кардәшләрен мактый, нәсел дәвамчыларының исемнәрен атый. Байларның, мәчетләр төзеп, Аллаһның ризалыгын алырга тырышулары авылларда ислам динен ныгытырга мөмкинлек биргән. Таштан салынган мәһабәт ислам йортлары авыл халкының горурлыгына әверелгән. Мәчет төзеп биргән татар байларының нәсел дәвамчылары белән аралашу галимгә гыйбадәт йортларының кайчан төзелгән булуын төгәл ачыкларга мөмкинлек биргән. Әйтергә кирәк, бүген XVIII гасырның икенче яртысы мәчетләренең төзелү датасын билгеләгәндә Шиһабетдин хәзрәт язмалары еш кына бердәнбер чыганак булып кала.

Ш. Мәрҗани, мәчетләрнең авылның кайсы өлешендә урнашканлыгы, кемнәр ремонтлаган, киңәйткән, түбәсен япкан, егылган манарасын кем һәм кайчан яңарткан яки яңасын корган, янгыннар һ. б. турында сөйли.

13 авылның руханилары турында язганда, туплаган чыганакларын билгеле бер тәртипне күздә тотып урнаштыра: кайсы авылда туган, нинди нәселдән, нәсел-нәсәбе, белем алган мәдрәсәләре нинди, мөршиде, остазлары кемнәр, кайсы авылларда мулла булып торган, нинди китаплар күчергән, нинди китаплар язган, корьәнхафиз булганмы, мәдрәсә тотканмы, мәшһүр шәкертләре кемнәр, уңай һәм тискәре шәхси һәм эшлекле сыйфатлары, халык телендәге кушаматы, һөнәрләре, сәяхәтләре (шул исәптән, хаҗ кылуы), гаиләсе, нәсел дәвамчылары, туганнары, ничә яшьтә вафат булуы, үлгән елы, күмелгән зираты, җеназа намазын укыган кешенең исеме. Аерым очракларда руханиның тормышында булган кызыклы, гыйбрәтле вакыйгалар һәм шәхесне характерларга ярдәм итүче хатларыннан яки язган әсәрләреннән өзекләр китерә.

Фәкать Ташкичү турында язган текст кына авыл тарихы дип бәяләнергә лаек. Автор авылга кайчан (1717), кем нигез салганын (Ашыт авылыннан Туйхуҗа бине Туйкә), соңрак тагын кемнәрнең кайсы авыллардан күченеп килгәнен (Ашыт, Пимар) һәм аларның нәселләрен бәян итә. Башка авыллардан күченеп килүчеләр барлыгын да әйтеп уза. Авылда мул сулы коеның исеме шул Туйхуҗа нәселе вәкиле Габделхәким белән бәйле дип фаразлый.

Ташкичүнең иске һәм яңа зираты булуын әйтә, аларның авылга карата географик яктан кайда урнашуларын, кабердашларындагы язуларны (аларны авыл кешеләренең нәселләрен ачыклаганда файдалана) китерә. Әтисе, әнисе һәм туган апасы күмелгән яңа зиратның коймасы черегәч, үзенең 1886 елда, 260 сум акча тотып, имән бүрәнәләр утырттырып, койма койдырганын яза [2: 99].

Мисал рәвешендә Ташкичүнең бишенче имамы Шәмсетдин мулла тормышы турында язганнарын күздән кичерик. Баласы булмаган авыл бае Әбүязидә Шәмсетдин исемле ятим баланы уллыкка ала, яхшы белем биреп, Бохарага җибәреп укыта, кайткач ике зур мәдрәсә

бинасы салдыра. Һәр бинасында бүлмәләре бик күп, гомеремдә мондый зур һәм матур мәдрәсә күргәнем булмады, ул бай утарын хәтерләтә иде, дип шәрехли. Шәмсетдин мулла белеме һәм тырышлыгы белән мәдрәсәсен мәшһүр уку йортына әверелдерә, Ташкичүнең данын еракларга тарата. Хаҗ кылырга бару юлында, Мисырда Ибраһим паша белән таныша һәм биредә университетта фарсы теле укытырга кала. Хаҗ кылырга өлгермичә, Мисырда вафат була. Аның бер улы һәм ике кызы калганын яза. Шәмсетдин мулланың шаян, җиңел характерлы, яхшы күңелле булып, малны тиз сарыф итүен, Бохарада укыганда бер голәмадан 50 тәңкә акча алуын, бурычын кайтармыйча кайтып китүен, әмма кылган гамәленең туган иленә кайтып ирешүен бәян итә.

Автор Ташкичүнең, муллаларыннан тыш, мәзиннәре турында да мәгълүмат бирә, шулай ук дин юлында игелек кылган шәхесләрне хөрмәтли.

Чынлыкта Мәрҗани язганнар шушы 13 авыл белән чикләнми, торак пунктларга нигез салу, имамнарның, мәчет төзеткән байларның тормыш юлларын, мәчетләрне күчереп салдыру кебек сюжетларны бәян иткәндә еш кына тирә-як авылларны да телгә ала, татар дөньясының шундый горизонталь яссылыкта дини бердәмлек, туган авыл, туган-тумачалык, әшнәлек, сәүдәгәрләрнең аркадашлыгы, бер остазның шәкертләре яки бер мөршиднең мөридләре арасында барган аралашу һ. б. күпсанлы элемтәләрдән торганлыгын сурәтли. Әйтик, әтисе мулла булып торганда аерым елларда Ташкичү, Хөснә (Кысна), Ашытбаш, Мәмсә авыллары халкы Ташкичүгә җыелып, Гает намазын укуларын, 1843 елгы корылык вакытында Ташкичү, Мәмсә, Ашыт, Сәрдә, Иске Кенәр, Пучмар, Хөснә, Ашытбаш авыллары кешеләре, шулай ук Ташкичүгә җыелып, яңгыр сорап, әтисе Баһаветдин җитәкчегендә җәмәгать намазы укуларын искә төшерә [2].

Ш. Мәрҗани тарафыннан мәчет, имамнар, мәхәллә һәм мәдрәсәләр тарихын бәян итү өчен структура һәм сюжетлар бүгенге Татарстанда ислам дине үсешен һәм авыл мәчетләре тарихын язганда файдаланырлык яисә исәпкә алырлык материал дип уйлыйм.

Ш. Мәрҗанинең муллалар, шул исәптән үзенең эшчәнлеген тасвирлаган язмаларын дикъкать белән укысаң, авыл һәм шәһәр мәчетләренең эшчәнлеге хакында күптөрле мәгълүмат җыярга мөмкин. Мин Мәрҗани текстларын анализлаганда XVIII гасырның икенче яртысында – XIX гасырда төзелгән мәчетләрнең язылачак тарихларында бу гыйбадәтханәләрнең халыкның дини һәм көндәлек тормышында тоткан рольләреннән кайсылары күрсәтелергә тиеш? дигән сорауга җавап эзләдем һәм алар эшчәнлегенең түбәндәге якларына игътибар итү сорала дигән нәтиҗәгә килдем:

Мәчет – милли-мәдәни мирас ядкәре, архитектура объекты. (Аңа реставрация ясаган оешманың документларында мәчет бинасы тарихы турында махсус бүлек бар, биредә бинаны төзү, үзгәртү һәм ремонт ясау турында мәгълүмат тупланган.)

Мәчет – Оренбург мәхкәмәи шәргыясе округында формалашкан мөселман дини-мәдәни автономиясенең беренчел нигезен тәшкил иткән һәм үзидарәгә нигезләнгән күпсанлы дини җәмгыятьләрне, ягъни мәхәлләләрне теркәү, руханилар сайлау, мәктәп-мәдрәсә ачу мөмкинлеге бирүче төп институт.

Мәчет – беренче чиратта, биш вакыт, җомга һәм гает намазларын укый торган һәм канун буенча төзелгән җәмәгать бинасы.

Сәяси җәһәттән, Мәхкәмәи шәргыядән килгән кәгазь буенча, мәчет – император, аның хатыны һәм тәхет варисы хөрмәтенә елга бернечә тапкыр гыйбадәт кылына торган урын. Бу чараны оештырмаган руханилар сәяси яктан тотрыксыз булып танылган һәм вазифаларыннан азат ителгән [1: 62–96].

Тәхеткә утырган яңа патшага ант иттерү, мөселман зираты һәм анда мәет күмү кебек эшләр мәчет мулласы вазифасына кергән.

Мәчет яшь ир-егетләр гаскәр хезмәтенә киткәндә, мосафирлар юлга чыкканда мулладан фатиха алу урыны булган.

Мәчет һәм аның ишегалды мәйданы – мәхәллә тормышына кагылышлы мәсьәләләрне тикшерү һәм карарлар кабул итү, намазга килгән ир-атларның яңалыклар белән уртаклашу үзәге дә.

Мәчет – үзенә һәм мәхәлләдәге дини уку йортына мөселманнар тарафыннан бүләк итеп бирелгән күчемле һәм күчемсез вакыфларны беркетә торган юридик зат хокукына ия оешма.

Мәчет – 1830 елдан мәхәллә халкының гражданлык актлары теркәү өчен ел саен Мәхкәмәи шәргыядән җибәрелгән метрикә кенәгәләрен тутыру һәм аларның икенче данәсе саклана торган урын.

Мәчет – муллаларның шәригать кануннары буенча мөселманнар мирасын бүлү һәм гаилә мөнәсәбәтләрен хәл итү урыны.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы мәчете – бәлагә тарыган яки мәчет-мәдрәсә төзүгә мөмкинлекләре булмаган мөселманнарга, сугыш вакытларында гаскәргә яки яраланган сугышчыларга, аларның гаиләләренә иганә җыю урыны.

Мәчет муллалары – мәхәллә халкының әхлагын тәрбияләүче һәм мөселманча яшәвен күзәтеп, халыкка гыйбадәтханә, мәктәп-мәдрәсә һәм зират турында кайгырту кирәклеген һәрдаим сөйләп торучылар.

Кайбер мәчет муллалары – язган хезмәтләре һәм уку әсбаплары белән ислам дине белеменә һәм мәктәп-мәдрәсәләрдә укытуга үз өлешләрен керткән затлар.

Инде килеп, борынгы һәм хәзерге заман мәчетләре тарихларын язуны кемнәр башкарып чыгарга тиеш? дигән сорауга җавап эзләп карыйк.

Эш оештыру башында, һичшиксез, мәчет имамнары торырга тиеш. Муллаларыбыздан, беренче нәүбәттә, мәчеткә намазга җыелган өлкән буын вәкилләре һәм мәчеттә дин сабагын өйрәнүчеләр аша чыганаклар туплау эшен башлап җибәрү, Ш. Мәрҗани хәзрәтләре тәҗрибәсен файдаланып, үзләре мәчеттәге вазифага керешкәч булган хәлләрне хәтердә яңартып, аларны башка чыганаклар ярдәмендә

төгәлләштерү һәм бүгенге көн вакыйгаларын елъязмачы сыман теркәп бару сорала.

Бу әһәмиятле проектны тормышка ашыруда, шул исәптән җыелган материалларны анализлап кәгазьгә төшерүне оештыруда мәктәп укытучылары, китапханә, авыл советы хезмәткәрләре һәм туган авыллары язмышына битараф булмаган шәхесләр дин әһелләренә ышанычлы таяныч булыр дип уйлыйм.

**Әдәбият**

1. *Загидуллин И.К.* Исламские институты в Российской империи: Мечети в европейской части России и Сибири. Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. 416 с.

2. *Шигабутдин Марджани.* Полезные вести о состоянии Казани и Булгара (Муставад ал-ахбар фи ахвали Казан ва Булгар); часть вторая, перевод на русский язык / предисл. и пер. с арабского, старотатарского Р.А. Адыгамова. Казань: Магариф – Вакыт, 2002. 272 с.

3. *Мәрҗани Ш.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы,***
*тарих фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Исламны өйрәнү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*

***Загидуллин Ильдус Котдусович,***
*доктор исторических наук, доцент, старший научный сотрудник Центра исламоведческих исседований АН РТ*

*zagik63@mail.ru*

УДК [94(470.4):39] «1445/1556» (тат)

***Б.Л. Хәмидуллин***

# КАЗАН ХАНЛЫГЫ ХАЛЫКЛАРЫ – АЛЕКСАНДР ГВАНЬИНИНЫҢ «ЕВРОПА САРМАТИЯСЕ ХРОНИКАСЫ»НДА

Западноевропейские письменные источники XV–XVII вв., хотя в них информация о народах Среднего Поволжья, Приволжской возвышенности и Приуралья XV–XVI вв. дана в минимальном объеме, часто достаточно серьезно восполняют лакуны источниковедческого и историографического характера. Представитель польской историографии итальянец А. Гваньини дает достаточно ценную информацию о народах Казанского ханства, к моменту написания его книги оказавшихся уже в составе Московского государства. Статья посвящена анализу этого, малоизвестного широкой общественности, исторического труда.

**Ключевые слова:** Казанское ханство, казанские татары, черемисы, мордва, Александр Гваньини, перевод источника.

Western European written sources of the XV–XVII centuries, although they contain information about the peoples of the Middle Volga region, the Volga Upland and the Urals of the XV–XVI centuries is given in a minimal volume, often quite seriously fill in the gaps of a source and historiographical nature. The representative of Polish historiography, the Italian A. Gwagnini gives quite valuable information about the peoples of the Kazan Khanate, who by the time of writing his book were already part of the Moscow state. The article is devoted to the analysis of this historical work, which is little known to the general public.

**Keywords:** Kazan Khanate, Kazan Tatars, Cheremis, Mordvins, Alexander Gwagnini, translation of the source.

Чыганаклар җитенкерәмәү аркасында Казан дәүләтенең этник-социаль тарихын өйрәнү бик акрын бара [Хамидуллин, 2000]. XV–XVII гасырларда Көнбатыш Европада инглиз, голланд, испан, итальян, латин, немец, поляк, француз һ. б. телләрдә язылган чыганаклар, Урта Идел Буе, Идел Буе калкулыгы һәм Урал Алды халыклары хакындагы мәгълүматларга бай булмасалар да, алардагы хәбәрләр еш кына һәм шактый дәрәҗәдә чыганакларга таянып аңлатыла һәм мәсьәләне өйрәнүдәге бушлыкларны тутыра, тарихи күзаллауны тулыландыра [7].

Казан ханлыгын (1438/1445–1552/1556) заманында Ш.Ф. Мөхәммәдьяров (1923–2005) «Урта Идел Буе халыкларының дәүләти берләшмәсе» дип атый [3: 5]. Әлеге дәүләтнең этник-социаль тарихы безнең тарафтан өйрәнелеп, җентекләп яктыртылган иде инде [6]. «Народы Казанского ханства» китабы язылып, нәшер ителгәннән соң (2002) 20 елдан артык вакыт узды, шул сәбәпле әлеге хезмәтнең күп кенә нигезләмәләре һәм нәтиҗәләре аерым фактологик төгәллекләр кертүне, яңадан колачлы концептуаль фикерләүне таләп итә. Поляк

историография мәктәбе вәкиле, италияле Александр Гваньининың мәгълүматлары карашларыбыздагы кайбер, әллә ни принципиаль булмаган бушлыкларны тулыландыру мөмкинлеге бирә.



Александр Гваньини

Казан дәүләтенең төгәл чикләре билгеле түгел. Көнбатышта алар – Сура һәм Ветлуга елгаларының көнбатыш кушылдыклары бассейнында, төньякта – Пижма һәм Чипца елгаларыннан төньяктарак, көнчыгышта хәзерге көнчыгыш Башкортстан җирләреннән узган, көньякта Мукшы һәм Самара елгаларына кадәр барып җиткән. Табигый-географик һәм этник-социаль җәһәттән ханлыкның территориясе дүрт көнбатыш «як»ка (Арча, Тау, Болын һәм Яр буе) һәм алты көнчыгыш «җирләр»гә (Башкорт, Агыйдел, Вотяк, Иштәк, Чулман һәм Чыплы), административ-сәяси җәһәттә хан биләмәсенә һәм ким дигәндә биш «даруга»га (Алат, Арча, Галич (Гәреч), Җөри һәм Нугай) бүленгән [10]. Казан ханлыгының төп халкы, дәүләт хасил иткән югары «татар» социаль катлавыннан (рус телле әдәбиятта бу очракта «страта» сүзе кулланыла) һәм гаять зур географик киңлектә таралган, ил тормышының барлык өлкәләрендә өстенлек иткән, формалашып килгән Казан татарлары этносоциумыннан тыш, мордваларның (мукшыларның һәм эрзяларның) һәм удмуртларның, оешып барган башкорт, мари һәм чуваш этносоциаль төркемнәренең бер өлешеннән гыйбарәт булып, XVI гасыр уртасында якынча 400–500 мең кеше тәшкил иткән [8]. «Казан яулары»нда катнашкан рус кенәзе А.М. Курбский болай дип билгеләп уза: «кроме татарска языка, в том царстве 5 различных языков: мордовский, чювашский, черемиский, воитецкий або арски, пятый башкирский» [10]. XV–XVII гасырлардагы күп кенә Көнбатыш Европа чыганакларында һәм картографик документларда (төрле язма вариантларда) еш кына Казан дәүләтенең чик буе өлкәләре буларак «Башкортлар җире», «Мукшылар җире», «Вачин иле», «Мордвалар иле», «Чирмешләр иле», «Чувашлар җире» һәм башкалар искә алына [9].

XV–XVII гасырлар Көнбатыш Европа авторларының без күтәргән мәсьәләгә нисбәтле гаять мөһим хәбәрләре арасыннан түбәндәгеләрне атап үтәргә мөмкин: Казан ханнары нәселенә нигез салган Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәдтә яллы хезмәттә булган баварияле Иоганн Шильтбергер (1381–1440 тирәсе) хатирәләре; татар телен яхшы белгән һәм Азов һәм Идел буе халыкларының (татарлар турында гына түгел, аерым алганда, «Moxia» өлкәсе һәм «Moxii» халкының яшәү рәвеше турында) этнографиясе хакында шактый җентекле мәгълүматлар калдырган Венеция дипломаты һәм сәүдәгәре Иосафат Барбаро (1413–1494) хикәясе; Венеция республикасы илчесе Амброджо Контарининың (1429–1499) «татар далалары»

(«Campagna di Tartari») һәм Московия аша сәяхәте тасвирламасы (анда Көнчыгыш Европа турында кызыклы мәгълүматлар бар); 1557 елда Московиядә булып киткән һәм күп кенә «татар урдалары», шул исәптән «Казан татарлары урдасы» («Orda di Tartari Cassani») хакында Италия сәүдәгәре Марко Фоскарино (?–?) бәяны; 1564–1576 елларда Явыз Иванның опричнина гаскәрендә хезмәт иткән немец Генрих Штаден (1542–1579 дан соң) тасвирламасы (анда «бөек кенәзнең [Иван IV нең] ничек итеп Казан белән Әстерханны яулавы һәм кулга төшерүе» җентекләп бәян ителгән); 1573–1591 елларда Московиядә яшәгән инглиз коммерсанты Джером Горсейның (якынча 1550–1626) бәяны (Иван IV нең татарлар белән мөнәсәбәтләре тасвирланган); Рим папасының 1581–1582 елларда Московиядә булган илчесе Антонио Поссевино (1534–1611) тасвирламасы; 1588–1589 елларда Англиянең Мәскәүдәге илчесе Джайлс Флетчер (1548–1611) бәяны; Польша корольләре Стефан Баторий һәм Сигизмунд III нең сәркатибе немец Рейнгольд Гейденштейн (1553–1620) тасвирламасы.

Янә килеп, биш авторның әсәрләрен – Краков университеты профессоры поляк Матвей Меховскийның (1457–1523) «Ике Сарматия турында трактат»ын («Tractatus de duabus Sarmatiis»), Австрия дипломаты Сигизмунд Герберштейнның (1486–1566) «Мәскәү эшләре турында язмалар»ын («Rerum Moscoviticarum Commentarii»), инглиз дипломаты һәм сәүдәгәре Энтони Дженкинсонның (1529–1610) хисап-хәбәрләрен, италияле нашир һәм тарихчы Александр Гваньининың (1534/1538–1614) «Московия патшалыгына буйсынган барлык өлкәләр, дала татарлары, кирмәннәр, мөһим шәһәрләр һәм халыктагы гадәтләр, дин һәм тормыш рәвешенең тулы һәм дөрес тасвирламасы. Моннан тыш, хәзерге Московия монархы Иоанн Васильевичның күптән түгел кылган мөһим гамәлләре дөрес итеп тасвирланды» («Omnium Regionum Moscoviae Monarchae subiectarum, Tartarorumque campestrium, arcium, civitatum praecipuarum, mo-rum denique gentis, religionis et consuetudinis vitae sufficiens et vera descriptio. Adiuncta praeterea gesta praecipua, tyrannisque ingens moderni Monarchae Moscoviae, Ioannis Basiliadis, nuper perpetrata, vera fide descripta») [1; 12] хезмәтен, шулай ук немец шәркыятьче галиме, язучы һәм физик Адам Олеарийның (1599–1671) «Персия монархы хозурына барган Голштиния илчелеге уңаеннан Шәрык тарафына кылынган яңа сәяхәтнең күптән көтелгән тасвирламасы»н («Offt begehrte Beschreibung Der Newen Orientalischen Reise, So durch Gelegenheit einer Holsteinischen Legation an den König in Persien geschehen») аерым билгеләп узабыз.

Казан ханлыгы тарихы, шул дәүләт халыклары тарихы буенча әлеге язма чыганакларның мәгълүматлылык һәм ышанычлылык дәрәҗәсе принципиаль рәвештә аерыла – бу хакта 2002 һәм 2018 елларда дөнья күргән монографияләрдә тәфсилләп язган идек [6; 9].

Верона шәһәрендә туып, Витебск һәм Краков калаларында яшәгән поляк фәнни историография мәктәбе вәкиле, италияле Александр

Гваньининың «Московия патшалыгына буйсынган барлык өлкәләр...» исемле әсәре – аның 1570 елларның беренче яртысында латин телендә язылып, беренче тапкыр 1578 елда Краковта нәшер ителгән зур күләмле «Польша корольлеген, Литваны, Самогитияне, Русьны, Мазовияне, Пруссияне, Померанияне, Ливонияне, Московия һәм Татария өлкәләрен колачлаган Европа Сарматиясе хроникасы» («Sarmatiae Europeae descriptio quae regnum Poloniae, Letvaniam, Samogitiam, Russiam, Masoviam, Prussiam, Pomeraniam, Livoniam, et Moschoviae, Tartariae que partem complectitur») китабының [12] бер өлеше.

«Хроника»ны язганда А. Гваньини европалы Амброджио Контарини (1429–1499), Матвей Меховский (1457–1523), Сигизмунд Герберштейн (1486–1566), Альберто Кампензе (1490–1542), Альберт Шлихтинг (?–1570 тән соң), Рафаэль Барберини (1532/1539–1582), Матвей Стрыйковский (1547–1586/1593) һ. б. ның материалларын актив файдаланган. Хәзерге күп кенә галимнәр поляк телендәге «Хроника»ның (1611 елгы басма) автордашы аны латин теленнән поляк теленә тәрҗемә иткән шагыйрь һәм тарихчы Марчин Пашковский (?–?) булган дип исәплиләр.

«Московия патшалыгына буйсынган барлык өлкәләр...» хезмәтенең 1 нче бүлегендә «Чирмеш халкы» («Cerevissi popvli») һәм «Мордва халкы» («Mordwa popvli») дип аталган бик кызыклы һәм шактый ук мәгълүматлы ике параграфка юлыгабыз [1; 12]. Биредә шуны искәрү урынлы, «чирмешләр» этносоционимы дигәндә иң элек мариларны күздә тоту зарур; хәер, әлеге төшенчә артында чувашлар һәм удмуртлар да «яшерелгән» булырга мөмкин, Урта гасырлар язма чыганакларында андый очраклар аз түгел (мәсәлән, кара: [4; 2]). «Чирмеш халкы» параграфы текстында, безнеңчә, болын марилары һәм удмуртлар хакында икърар ителә. Чувашлар исә автор тарафыннан «Мордва халкы» параграфында «югары/тау чирмешләре» («төньяк чирмешләр»гә капма-каршы рәвештә) искә алына. Шулай да бу очракта сүз чувашлар хакында түгел, бәлки тау марилары яисә тулаем чувашлар турында да, тау марилары хакында да барырга мөмкин.

А. Гваньини ул заманда инде рус подданныйлыгындагы чирмеш һәм мордваларны тасвирлый. Әмма биредә бер төгәллек керткәндә – Урта Идел буенда 1545–1574 елларда (ягъни тарихта Икенче чирмеш сугышы сыйфатында мәгълүм күтәрелеш тәмамланганчы) барган һәм җирле халыклар тормышына зур йогынты ясаган җитди сугыш хәрәкәтләрен исәпкә алган хәлдә, әлеге тасвирламаның элгәрерәк чорга – Казан ханлыгына күчерелеп кабул ителүе дә мантыйкка ярашлы булыр.

Шулай итеп, А. Гваньини фикеренчә, «чирмешләр, мордвалар һәм вогуллар [Г.Г. Козлова тәрҗемәсендә «черемиси, мордовоты и вахины»] Вятка һәм Вологда провинцияләре арасында йортсызнисез калын урманнарда яшиләр», «үз телләрендә сөйләшәләр һәм ислам динен тоталар, кайберләре – мәҗүсиләр (Алланы бар дип белмиләр)», «урлау һәм талау белән шөгыльләнәләр» [«Вятка өлкәсе»


TARTARORVM CAMPESTRIVM IN HORDAS DIVISORVM MORVMQVE ET CONSVETVDInis vitae eorundem breuissima descriptio.

DE REGNO CAZANENSI.

«Европа Сарматиясе хроникасы»ның бер бите

параграфында А. Гваньини анда «юлбасарлык белән шөгыльләнүче чирмешләр дә аз түгел», дип яза], «сихри әфсенләүләргә ифрат хирыслар», «башлыча киек ите, бал (аларда умарталар бик күп) белән тукланалар, ипине сирәк ашыйлар», «бик тиз йөгерәләр, барысы да бик оста мәргәннәр [А. Гваньини үз «Хроника»сының башка өлешләрендә дә чирмешләрне ике тапкыр «оста мәргәннәр» дип атый] һәм беркайчан да җәяне кулдан төшермиләр», «аларның барлык кәсебе һәм хезмәте – кулларына җәя тотып, киекләр аулау; шуларның ите белән тукланалар, тиреләре белән киенәләр һәм ясак түлиләр», «ау вакытында аякларына эләктерелгән чаңгылардан файдаланалар...; аларны ике аякларына да бәйләп, очкандай, бик тиз хәрәкәтләнәләр». Шунысы аерым игътибарга лаек: зур күләмле «Казан патшалыгы» («de Regno Cazanensi») параграфында, 1524 елгы вакыйгаларны тасвирлап, А. Гваньини: «Казан урдасы шулкадәр зур ки, ул сугышка 20 000 кешелек гаскәр кертергә мөмкин. Аларга чирмешләр дә кушылса, алар 300 000 кешегә җитә», – дип билгеләп уза.

«Мордва халкы» параграфында мордвалар һәм «югары/тау чирмешләре» хакында А. Гваньини болай дип яза: «Түбән Новгородтан көньяк-көнчыгыш тарафка юлыбызны дәвам итеп..., атаклы Идел елгасы буйлап зур киңлектә сузылган, эчләрендә мордвалар дип аталган халыклар яшәгән гаять зур урманнарны очратабыз. Алар үз телләрендә сөйләшәләр, бөтен җиргә таралып урнашкан авылларда яшиләр, һәм кырчылык белән шөгыльләнәләр. Аларда бал һәм төрле кыйммәтле мехлар мулдан. Ул кешеләр кырыс һәм сугышчан, алар үз җирләреннән юлбасарлык кылучы татарларны (күршеләр булып яшиләр) кыю рәвештә куып җибәрәләр, һәрвакыт диярлек җәяү сугышалар, озын җәяләр белән коралланганнар, җәядән бик тә оста аталар: мех бозылмасын һәм яхшы саклансын өчен укларын киекнең борынына төбиләр. Аларның кайберләре ислам динен тота, кайберләре катгый рәвештә мәҗүсилектә кала [«Түбән Новгород кенәзлеге» параграфында А. Гваньини «мордвалар – мәҗүсиләр», ә «чирмешләр – мөселманнар» дип билгеләп уза]. Алар ел саен Мәскәү Бөек патшасына төрле җәнлекләрнең тиреләре белән ясак түлиләр. Аларның хатын-кызлары тырнакларын каралталар, һәрвакыт яланбаш һәм чәчләрен таратып йөриләр. Алар белән башка халыклар – төньяк чирмешләрдән (алар хакында югарыда искә алынды) аеру өчен югары, яки алар яшәгән калкулыкларга нисбәтле тау чирмешләре дип аталган чирмешләр кушылып яшиләр». Шунда ук «Тасвирлама» авторы: «Биредә Мәскәү

патшалыгы белән күрше һәм чиктәш Казан татарлары һәм башка, урдаларга бүленгән дала татарлары хакында бәян иткән булыр идек тә, тик башланган темадан бүленмәс өчен, безгә берничә сүз белән мәскәүлеләрнең холкын, динен һәм гореф-гадәтләрен сурәтләү урынсыз булмас кебек тоела. Әлеге тасвирламаны төгәлләгәннән соң, без кыскача татарларның территориясенә һәм шул халыкларның гореф-гадәтләренә тукталып узарбыз...», – дип белдерә.

А. Гваньининың татарлар (Казан ханлыгы һәм, аерым алганда, Казан татарлары) турындагы латин һәм поляк телләрендәге текстлары бүгенге көнгә кадәр рус теленә тәрҗемә ителмәгән, шулай да тарихчы-археограф һәм православие рухание Ю.А. Мицикның поляк теленнән («Хроника»ның 1611 елгы Краков басмасыннан) украин теленә тәрҗемәсе бар [11; 12]. Әлеге тәрҗемәгә таянып, А. Гваньининың татар һәм Казан ханлыгы тарихына карашларын кыскача бәян итәргә тырышып карыйк.

Итальян авторы карашынча, Дон һәм Идел белән бүленгән ике Сарматия – поляклар, руслар, литвалылар, мазурлар, пруссlar, поморлар, инфляндлылар, мәскәүлеләр, готлар, аланнар, волохлар һәм татарлар (Tartaris / Tartaros / Tartarus) яшәүче «Европа Сарматиясе», һәм «Идел аръягы татарлары һәм аларның өлешләргә бүленгән башка урдалары яшәгән» «Татар, яки Азия Сарматиясе» бар. Алга таба А. Гваньини үзенең текстында Монгол империясе татарлары һәм Бату хан, Алтын Урда татарлары, Литва татарлары, «Перекоп татарлары», «Нугай татарлары» һәм «Нугай татарлары урдасы», «рәхимсез татар ханы Тамерлан», «Идел аръягы татарлары», «Белгород татарлары», «Азиядәге татар провинцияләре», «татарларның Казан һәм Әстерхан державалары», «татар патшасы идарә иткән Төмән патшалыгы» турында яза. Ул «Казан татарларыннан гайре барлык татарлар, төркем-төркем, иксез-чиксез кыргыйлашкан кырларда тирмәләрдә яшиләр. Алар ниндидер провинцияләрне хәтерләткән урдаларга бүленәләр». «Урда» сүзе күп кенә кешеләрнең бер туплануын һәм аларның ниндидер шәһәр яки өязләре булган провинция шикелле бер полкка каравын аңлата. Татарларның төрле урдалары бар, алар күп, аларның һәркайсының үз атамасы бар. Шул ук вакытта Нугай, Идел аръягы, Әстерхан, Перекоп, Манкоп, Кырым, Очаков, Белгород, Козачок, Төмән, Юрга, Шибан, Калмык, Туркоман, Кыргыз, Шамаха, Сәмәрканд, Башкорт, Кеселит, Малгомуз, Байдай, Абхаз, Чиркәс, Пятигорск урдалары һәм башкалар бар... », дип фикер йөртә.

Казан татарлары (текстның латинча вариантында «Casanen Tartaris», «Tattari Cazanen» һ. б.) турында беренче тапкыр «1441 елда» «Мәскәү кенәзе Казан татарлары ярдәмендә Литвада сугышканда» дип телгә алынуына тап булдык. Икенче мәртәбә ул түбәндәгечә искә алына: «1521 елда. Мәхмәтгәрәй, Перекоп ханы, нугай татарлары ярдәме белән Иделне зур кыенлык белән кичеп, баш шәһәр Казанны мәскәүлеләрдән алды һәм Казан татарларын үзенә буйсындырды...».

Кызганычка каршы, бик тә кыска эчтәлекле (күләме ике китап битеннән артмый) «Казан патшалыгы» («de Regno Cazanensi») параграфында, Казан ханлыгының географик урыны, дәүләт төзелеше, икътисади һәм мәдәни үсеше, этник составы һәм халкының социаль структурасы мәсьәләләренә караганда, сәяси тарихы күбрәк яктыртыла.

Йомгаклап, А. Гваньининың «Казан патшалыгы»на нисбәтле рәвештә ниләр хәбәр итүе хакында нәтиҗә ясыйк. Мәгълүматлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт. Сура елгасы Мәскәү һәм Казан дәүләтләрен үзара бүлеп ага. Сура Иделгә койган урында Мәскәү кенәзе үз хөрмәтенә Васильгород дип аталган замок төзегән. Казан ханлыгы Бөек Новгородтан 60 поляк миле ераклыгында «Идел өстендә башлана» һәм «көнчыгыштан көньякка таба сузыла, һәм 200 поляк миле озынлыгына сузылган кыргыйлашкан кырларда төгәлләнә. Аңардан көньяк-көнчыгыш тарафтагы җирләрне Шибан, Казак һәм Төмән татарлары дип аталган башка татарлар били». «Барлык ханлыкның башкаласы – Казан шәһәре Идел елгасы һәм үзенә исем биргән Казансу өстендә урнашкан. Ул елганың ерак ярында утыра. Кальга табигать тарафыннан да, уңайлы урынга урнашуы белән дә җитәрлек дәрәҗәдә сакланган (ныгытылган), аны яулау кыен. Югары Новгородтан 70 миль ераклыкта». «Казан татарлары башкалардан аерылып торалар, кайчакта гаять кешелеклеләр. Алар хуҗалык алып барырга һәм басулар эшкәртергә, бакчалар үстерергә гадәтләнгәннәр. Буш тирмәләрдә түгел, йортларда яшиләр. Мәскәү, төрекләр һәм башка татарлар, күршеләре белән сәүдә итү өчен аларның сәүдәгәрләре, төрле ярминкәләре бар; Мәскәүнең мәрхүм кенәзе Василий Иванович заманына кадәр үз патшалары булган һәм алар беркемгә дә буйсынмаганнар. Ләкин шул Василий аларны буйсындырган; ул озак вакытлар җиңеп һәм җиңелеп аларга каршы сугышкан, ахырда буйсындырган – үзенә ясак түләүчеләргә әйләндергән һәм патша улын аларга үз ихтыяры белән билгеләгән. Теләсәләр-теләмәсәләр дә, өлешчә Мәскәүдән Иделгә койган уңайсыз елгалар, Мәскәү белән гадәти сәүдә аркасында казанлылар буйсынырга тиеш булганнар, чөнки дошманлык туганда сәүдәгәрләргә Мәскәүгә бару кыенлашкан». Алга таба кыскача гына Казанда Хәлил, Ибраһим, Илһам, Мөхәммәдәмин, Габделлатыйф, Шаһгали һәм Сафагәрәй ханнар идарә иткән чорларда Казан ханлыгы һәм Мәскәү Бөек кенәзлегенең дәүләтара мөнәсәбәтләре бәян ителә. «Ходайның 1551 елы ахырында… казанлылар үз замокларын һәм шәһәрләрен бирелдерергә мәҗбүр булдылар. Шул чакта бөек кенәз Иван үз ихтыяры белән атасының эшен ахырына җиткерде, һәм шул вакыттан Казан дәүләте баш шәһәре белән Мәскәү Бөек кенәзлеге биләмәсенә керде, ә бөек кенәз үзенә Казан патшалыгы идарәчесе титулын алды».

Күргәнебезчә, поляк историографиясе вәкиле италияле А. Гваньини китабы язылганда инде Мәскәү дәүләте составында булган элеккеге Казан ханлыгы халыклары турында шактый кыйммәтле мәгълүмат

бирә. Бу хәбәр Амброджио Контарини, Матвей Меховский, Сигизмунд Герберштейн кебек Көнбатыш Европа сәяхәтчеләренең мәгълүматлары фонында әллә ни күзгә ташланып тормаса да, безнеңчә, галимнәр һәм туган якны өйрәнүчеләрнең җитди игътибарына лаек.

**Әдәбият**


1. *Гваньини А.* Описание Московии / пер. с латинского [с краковского издания 1578 года] Г.Г. Козловой. М., 1997. 176 с.

2. *Димитриев В.Д.* О значении этнонима «черемисы» в русских и западноевропейских источниках XVI – начала XVIII веков // Ученые записки ЧНИИ. Чебоксары, 1964. Вып. XXVII. С. 118–132.

3. *Мухамедьяров Ш.Ф.* Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства (XV – первая половина XVI вв.) / Рукопись дис. … канд. ист. наук. М., 1950. 367 с.

4. *Тихомиров М.Н.* Присоединение Чувашии к Русскому государству // Советская этнография. 1950. № 3. С. 93–106.

5. *Хамидуллин Б.Л.* Крупицы древнего наследия: основные источники по истории Казанского ханства // Казань. 2000. № 7. С. 65–71.

6. *Хамидуллин Б.Л.* Народы Казанского ханства: этносоциологическое исследование. Казань, 2002. 335 с.

7. *Хамидуллин Б.Л.* Народы Казанского ханства на страницах западноевропейских нарративных источников XV–XVII вв. // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2017. № 1/2. С. 50–62.

8. *Хамидуллин Б.Л.* Казанское ханство как цельная этнополитическая общность // GLOBAL-Turk. Астана, 2017. № 1/2. С. 172–189.

9. *Хамидуллин Б.Л.* «…Окаянная дщерь Златой орды…»: очерки и историографические заметки по истории Золотой Орды и Казанского ханства. Казань, 2018. 295 с.

10. *Хамидуллин Б.Л.* Казанское ханство // Портал «Большая российская энциклопедия». URL: https://bigenc.ru/c/kazanskoe-khanstvo-83f288 (дата обращения: 4.10.2024).

11. *Гваньїні О.* Хроніка про Татарську землю / пер. с польского [с краковского издания 1611 года] Юрія Мицика. Запоріжжя, 2000. 72 с.

12. *Гваньїні О.* Хроніка Європейської Сарматії / пер. с польского [с краковского издания 1611 года] Юрія Мицика. Київ, 2007. 1006 с.



***Хәмидуллин Булат Лирон улы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Татар диаспорасын өйрәнү үзәге җитәкчесе*

***Хамидуллин Булат Лиронович,***
*кандидат исторических наук, руководитель Центра изучения татарской диаспоры Института татарской энциклопедии и регионоведения имени М. Хасанова АН РТ*

*bulat.antat@mail.ru*

УДК 372.881,882

***Н.К. Туктамышов***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ МАТЕМАТИКАДАН УКУ МАТЕРИАЛЛАРЫ БУЛДЫРЫРГА ЙОГЫНТЫ ЯСАУЧЫ ФАКТОРЛАР ТУРЫНДА

В статье рассматриваются факторы, влияющие на разработку учебных материалов по математике на татарском языке в условиях билингвальной образовательной среды Татарстана. Цель исследования – изучение условий, необходимых для эффективного преподавания математики на татарском языке в контексте высшего образования. В рамках эксперимента, проведенного в Казанском государственном архитектурно-строительном университете в 2022–2024 годах, сравнивалась успеваемость студентов, обучавшихся на русском и татарском языках. Показано, что обучение на билингвальной основе способствует улучшению результатов по специальным дисциплинам. Сделан вывод о необходимости государственной поддержки для развития национального образования и создания непрерывной системы обучения.

**Ключевые слова:** образование, интеграция, билингвизм, математика, термин, обучение.

The article examines the factors influencing the development of mathematics teaching materials in the bilingual educational environment of Tatarstan. The aim of the study is to explore the conditions necessary for effective mathematics instruction in Tatar within the context of higher education. As part of an experiment conducted at KSUAE in 2022–2024, the academic performance of students studying in Russian and Tatar was compared. The research method involved analyzing performance data from two student groups. The study demonstrates that bilingual education improves results in specialized disciplines. The conclusion highlights the need for state support in developing national education and establishing a continuous learning system.

**Keywords:** education, integration, bilingualism, mathematics, terminology, instruction.

Татарстан – Россия Федерациясенең бер субъекты, анда халыкның якынча 53%ын татарлар тәшкил итә. Бүгенге көндә Татарстанда 1402 мәктәп арасында, рәсми мәгълүматларга караганда, 591 мәктәптә укыту татар телендә алып барыла. Шулай ук күп кенә ике телле мәктәпләр (татар-рус, мари-рус, чуваш-рус һ. б.) эшләп килә. 1990 елда татар укучыларының якынча 24%ы белемне туган телендә алган, бигрәк тә авыл җирлекләрендә бу күренеш киң таралган булган.

Татарстанда ике телдә укыту мохите формалашкан, һәм татар телендә югары белем алу мөмкинлегенә зур ихтыяҗ кала бирә. Шуңа күрә татар телендә укытуны (шул исәптән математиканы) рус телендә гамәлгә ашырыла торган югары белем бирү системасына яраклаштыру бурычы актуаль булып тора. Әмма бүгенге шартларда югары уку

йортларына кабул итү Бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре нигезендә башкарыла, ә бу сынау бары тик рус телендә генә уздырыла.

Татарстанның милли мәгариф системасы телләрнең күптөрлелеге шартларында үсеш ала, бу исә республикада белем бирү мохитен формалаштырганда төрле каршылыклар тудыра. Әлеге проблемаларның күбесе Бельгия, Испания һәм башка күптелле илләрдәге процессларга охшаш [2: 104–133]. Мондый шартларда татар телендә белем бирүне (шул исәптән математиканы) рус телендә алып барылучы югары белем системасы белән интеграцияләү мәсьәләсе мөһим урын били.

Милли мәгарифне интеграцияләү күпсанлы проблемаларны хәл итүне таләп итә. Шуларның иң әһәмиятлесе – милли мәгарифне рус телендә алып барылучы югары белем белән интеграцияләүнең төп шартларын табу. Әлеге проблеманы хәл итүгә иң кулай юл – ике телдә белем бирүне үстерү. Бу алым уку-укыту процессында татар һәм рус телендәге уку әсбапларыннан файдалануны, һәр фәнни дисциплина буенча терминология эшләүне, ике телдәге уку әсбапларын һәм методик материаллар булдыруны күздә тота.

Математика техник белем бирүдә мөһим урын тота, шуңа күрә татар телендә уку әсбаплары һәм методик материаллар эшләү һәм аларны уку-укыту процессында сынау әһәмиятле бурыч булып тора [7]. Шул ук вакытта, белем бирү ике телле мохиттә алып барылуны истә тотып, дәресләрне ике теллелек шартларында нәтиҗәле уздырырга мөмкинлек бирә торган дидактик материаллар әзерләү кирәк.

Әлеге эшнең максаты – уку һәм методик материалларны эшләгәндә, белем бирүнең ике телдә алып барылуын истә тотып, тиешле шартларны өйрәнү.

Ике телдә югары белем бирү түбәндәге шартларда гына тормышка ашырылырга мөмкин:

– Россиянең белем бирү киңлегенең бөтенлеген саклап калу;

– җәмгыятьнең, шул исәптән төбәкнең, социаль-икътисади һәм сәяси үсеш ихтыяҗларын, төбәк һәм этник үзенчәлекләрне исәпкә алу;

– югары белем алу мөмкинлегендә гражданнарның тигез хокуклы булуы һәм укыту телен сайлау ирекe;

– татар телендә фәнни терминология формалаштыру түбәндәге факторларны исәпкә алып башкарыла: өзлексезлек, төрле дисциплиналарның үзара бәйләнешен искә алу.

Билингваль белем бирү мәсьәләләре озак еллар белгечләр игътибарын җәлеп итә. Кагыйдә буларак, ике телдә белем бирү дип, укыту процессында ике телне дә куллану мөмкинлеге булган укытуны атыйлар [8]. Билингвизмга багышланган заманча тикшеренүләрдә ике теллеләрнең бер теллеләргә караганда когнитив өстенлекләргә ия булулары турында фактлар китерелә [9], моны безнең экспериментлар да раслый [10: 341–347].

Татарстан Россия Федерациясенең бер өлеше буларак, белем бирү үсеше, шул исәптән югары белем үсешен, Россиянең бердәм

белем бирү киңлеге кысаларында һәм белем бирү өлкәсендәге закон актларын, шулай ук Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм Татарстан халыкларының башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасын исәпкә алып кына тормышка ашырып була. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: татарларда математика юнәлешендә белем бирүнең үсеше озын, катлаулы һәм даими тарихка ия [1; 3].

Укыту барышында төп проблемаларның берсе – тиешле терминология аппаратын тулыландыру. Билингваль белем бирүнең уңышлы булуының төп элементларыннан берсе – заманча стандартларга һәм тел үзенчәлекләренә туры килгән терминология аппараты эшләү һәм гамәлгә кертү. Татар телендә терминнар формалаштыру өч юнәлешнең үзара бәйләнеше нигезендә алып барыла. Беренче юнәлеш тарафдарлары математика терминнарының рус телендәгесен турыдан-туры күчерү ягында торалар. Икенче юнәлеш тарафдарлары күпсанлы гарәп-иран чыгышлы терминнарны кертүне яклыйлар. Ләкин бу терминнарны турыдан-туры куллануга кертү, аларның күпчелек студентларга таныш булмавы сәбәпле, аралашуны шактый катлауландырырга мөмкин. Мәсәлән, русча «проблема» сүзе «мөхгәммә» белән алыштырыла; «тикшерү» татар сүзе «тафтыш» белән алыштырыла һ. б. Татар теленең чисталыгын саклау һәм борынгы әдәби нормаларны яңарту лозунгы астында киң таралган математика терминнарыннан баш тарту математика юнәлешендә белем бирүнең сыйфатын киметергә һәм аны Россия Федерациясенең белем бирү киңлегеннән изоляцияләүгә китерергә мөмкин. Өченче юнәлеш тарафдарлары фикеренчә, математика терминнары гарәп-иран чыгышлы булса һәм киң кулланылса, аларны татар телендә математика укытканда кулланырга мөмкин. Термин бер тамырлы сүздән генә тормаска мөмкин, мәсәлән: треугольник («өчпочмак»), прямой угол («турыпочмак»).

Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: татар теленең хәзерге хәлен исәпкә алып, җентекләп өйрәнелгән яңа терминнар гына математика төшенчәләрен үзләштерүне һәм аңлауны гына түгел, татар телен дә баетачак.

Татар теленә яңа математика терминнарын кулланышка керткәндә ачыклык һәм кыскалык критерийларына таянырга кирәк. Әлеге принциплар математикадан татарча-русча аңлатмалы сүзлек язганда [Галиева, Галәутдинов, 2013], шулай ук русча-татарча-инглизчә математика терминнары сүзлеге [5] төзегәндә үтәлде.

Татар телендә сүз тәртибе һәм синтаксик берәмлекләрнең урыны шактый катгый: аергыч – ия – тәмамлык – хәбәр. Җөмләнең бәйләнеше объектның анализлануы һәм реаль вакыйгалар тәртибе белән хронологиянең туры килүе аша тәэмин ителә. Бу үзенчәлекләр татар телен математикада куллану өчен шактый «яраклаштырылган» дип расларга мөмкинлек бирә.

Түбәндәге таблицада Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында (КДАТУ) төзелеш юнәлеше буенча белем алу барышында

кулланыла торган һәм югары техник уку йортларында математика укыту нигезен тәшкил иткән кайбер мөһим математика төшенчәләре һәм аларның татарча эквивалентлары китерелгән.

Таблица 1. Төп математика төшенчәләре

| Математика төшенчәсе (рус телендә) | Математика төшенчәсе (татар телендә) | Математика өлкәсе | Кулланылыш |
|---|---|---|---|
| Вектор | Вектор | Векторлар алгебрасы | Кырлар теориясе |
| Система координат | Координаталар системасы | Аналитик геометрия, математик анализ | Термодинамика, тоташ мохит механикасы |
| Система уравнений | Тигезләмәләр системасы | Сызыкча тигезләмәләр системасы | Металл конструкцияләр |
| Уравнение | Тигезләмә | Дифференциаль тигезләмәләр | Физика, эластиклык теориясе |
| Матрица | Матрица | Программалау, сызыкча тигезләмәләр системасы | Механика, икътисад |
| Множество | Күплек | Дискрет математика | Архитектура |
| Функция | Функция | Математик анализ | Кырлар теориясе, тоташ мохит механикасы |
| Производная | Чыгарылма | Математик анализ, дифференциаль тигезләмәләр | Оптимальләштерү мәсьәләләре, динамик процесслар |
| Бесконечная сумма | Чиксез сумма | Рәтләр теориясе, дифференциаль тигезләмәләр | Дифференциаль тигезләмәләр чишелеше |
| Вероятность случайного события | Очраклы вакыйганың ихтималлыгы | Ихтималлык теориясе | Статистика, ышанычлык теориясе |
| Статистический ряд | Статистик рәт | Статистика | Эксперименталь статистика |
| Ряд | Рәт | Рәтләр теориясе, дифференциаль тигезләмәләр | Кырлар теориясе, тоташ мохит механикасы |

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында математика курсына 324 сәгать бирелә. Уку материалларын эшләгәндә түбәндәге психологик-педагогик принциплар нигез итеп алынды:

– профессиональ белемнәрне үзләштерүдәге әһәмиятенә карап, математиканы башка дисциплиналар белән интеграцияләү;

– математикадан белем алу системасының методологиясе белән өзлексез бәйләнеш;

– укыту системасының адаптацияләнүе (яраклаштырылуы);

– вариативлык (укытуга авторлык элементлары кертү).

Түбәндә Казан архитектура-төзелеш университетында өйрәнелә торган темалар күрсәтелгән.

Таблица 2

| Тема | Блок | Сәгатьләр |
|---|---|---|
| Аналитик геометрия | B1 | 25 |
| Векторлар алгебрасы | B2 | 11 |
| Сызыкча алгебра | B3 | 25 |
| Бер аргументлы функция. Дифференциаль исәпләү | B4 | 56 |
| Күп аргументлы функция. Дифференциаль исәпләү | B5 | 27 |
| Интеграль исәпләү | B6 | 72 |
| Гади дифференциаль тигезләмәләр | B7 | 30 |
| Санлы һәм дәрәҗәле рәтләр | B8 | 28 |
| Ихтималлык теориясе. Математик статистика элементлары | B9 | 50 |

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында математиканың аерым базалы дисциплиналар белән үзара бәйләнеше 3 нче таблицада күрсәтелгән:

Таблица 3

| Предмет | B1 | B2 | B3 | B4 | B5 | B6 | B7 | B8 | B9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Химия | | * | | * | | | | | |
| Физика | * | * | * | * | | * | | | * |
| Информатика | | | * | * | | | | | |
| Механика | * | * | * | * | | | | * | |
| Геодезия | * | * | | | | | | | |
| Архитектура | * | * | * | | | | | | |
| Тимербетон конструкцияләр | | | * | | * | | * | * | * |
| Төзелеш икътисады | | | * | | | * | | * | * |
| Металл конструкцияләр | | | * | * | * | * | * | | |

Математик блоклар һәм һөнәри дисциплиналар арасындагы бәйләнеш таблицада йолдыз символы белән күрсәтелгән.

Студентлар төп теоретик төшенчәләрне татар телендә язылган дәреслекләрдән, уку-укыту әсбапларыннан, методик күрсәтмәләрдән һәм укытучының лекцияләреннән үзләштерәләр. Алар практик дәресләр һәм студентларның индивидуаль тикшеренүләре белән ныгытыла. 2022–2024 елларда Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында татар телендә математика укытуның нәтиҗәсен тикшерү өчен педагогик эксперимент үткәрелде.

Эксперимент төзелеш факультетының ике төркемендә уздырылды. Югары уку йортына кабул итү этабында булачак студентлар белән әңгәмә үткәрелде. Шулар нәтиҗәсендә ике төркем формалаштырылды. Бер төркем рус телендә укыды, икенчесе ике телле нигездә укытылды

(монда төп тел итеп татар теле кулланылды). Рус телендә белем бирелә торган төркемгә – 27, ә билингваль төркемгә 21 студент тупланды. Рус телендә укыту төркемендә 10 татар телле студент укый, шулардан 8 е район үзәкләреннән, ә 2 се – Казаннан. Ике телле төркемдә Казан һәм Яр Чаллыдан 3 студент, район үзәкләреннән (шәһәр тибы булмаган) 14 студент укый. Калган 4 студент – авыллардан.

Ике телдә белем бирелгән төркемдә лекцияләр һәм гамәли дәресләр татар телендә үткәрелде. Дәрес вакытында тиешле терминнар рус телендә дә бирелде, һәм кайсы да булса бер төшенчә аңлашылмаган очракта, ул ике телдә дә тәкъдим ителде.

Эксперимент үткәргәндә кулланылган методлар: тикшеренү темасы буенча фәнни-педагогик басмаларның системалы анализы; сораштыру нәтиҗәләреннән алынган мәгълүматларның эчтәлек анализы һәм нәтиҗәләрнең статистик эшкәртелүе.

Таблица 4. Төрле фәннәр буенча уртача билгеләр (биш баллы шкала буенча)

| Предмет | Билингваль нигездә уку төркеме | Рус телендә уку төркеме |
|---|---|---|
| Математика | 3,6 | 3,6 |
| Металл конструкцияләре | 3,5 | 3,5 |
| Тимербетон конструкцияләре | 4,2 | 3,8 |
| Механика | 3,9 | 3,9 |
| Төзелештә механизация | 3,9 | 3,9 |
| Төзелеш икътисады (экономикасы) | 4 | 3,3 |

Татарларны татар телендә һәм рус телендә укыту нәтиҗәләре кызыксыну уята. Рус һәм татар телләрендә белем алган студентларның математика буенча компетентлыкларын чагыштыру түбәндә китерелгән (5 баллы шкала).

Таблица 5. Рус һәм татар телләрендә математика укыту нәтиҗәләре

| Предмет | Математика | Металл конструкцияләр | Тимербетон конструкцияләр | Механика | Төзелеш механизациясе | Төзелеш икътисады |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Рус телендә уку | 3,6 | 3,1 | 3,6 | 3,6 | 3,3 | 3,3 |
| Нигездә, татар телендә уку | 3,6 | 4,3 | 3,9 | 3,9 | 4,0 | 4,5 |

Студентларны, нигездә, ике телдә укыту, таблицалардан күренгәнчә, аларга махсус дисциплиналар буенча да яхшырак нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә. Математика дәресләрен алып бару өчен «Математика» [4] дәреслегенә, шулай ук «Югары математика» [6] дәреслегенә таянып эш ителде.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: тәҗрибә күрсәткәнчә, татар телендә математика укыту җитәрлек дәрәҗәдә уңышлы һәм перспективалы.

Төрле фәннәрдән уку материалларын эшләү һәм булдыру өчен педагогик-психологик һәм лингвистик шартлар өйрәнелде һәм ачыкланды. Математика юнәлешендә татар телендә югары белем бирү телнең стилен, логикасын, ассоциацияле һәм башка аспектларын файдалану мөмкинлекләрен киңәйтергә ярдәм итә. Математикадан югары белем бирү һәм аны үстерү милли мәгарифнең тулы һәм өзлексез системасын булдыруны таләп итә, шулай ук бу эштә дәүләт ярдәме бик мөһим.

**Әдәбият**

1. *Беркутов В.М.* Развитие математического образования булгаро-татар. Казань: Дом печати, 1997. 176 с.

2. *Гак В.Г.* К типологии форм языковой политики // Вопросы языкознания. 1989. № 5. С. 104–133.

3. *Давлетшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 509б.

4. *Салимов Р.Б., Туктамышов Н.К.* Математика. Казан: Мәгариф, 2000. 487 б.

5. *Салехова Л.Л., Туктамышов Н.К.* Математика. Русско-татарско-английский терминологический словарь. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2014. 118 б.

6. *Туктамышов Н.К., Салехова Л.Л.* Югары математика. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2014. 213б.

7. *Barton B.* The language of mathematics. Mathematics education library. Springer. 2008. 184 p.

8. *Barwell R.* Multilingualism in Mathematics Classrooms. Global Perspectives / Great Britain: Cromwell Press Group. 2009. 186 p.

9. *Mechelli A., Crinion J.T., Noppeney U. et al.* Structural plasticity in the bilingual brain // Nature. Vol. 431. 2004. 14 October. P. 757.

10. *Salekhova L.L., Tuktamyshov N.K.* Bilingual mathematics teaching in conditions of higher educational establishment // Proceedings of the ICMI 21 conference mathematics education and language diversity. 16–20 september 2011. Aguas de Lindoia. San Paolo State Brazil. P. 341–347.

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Туктамышов Наил Кадыйр улы,***
*педагогия фәннәре докторы, профессор, Казан дәүләт архитектура-төзелеш унивеситетының югары математика кафедрасы профессоры*

***Туктамышев Наиль Кадырович,***
*доктор педагогических наук, профессор, профессор кафедры высшей математики Казанского государственного архитектурно-строительного университета*

*nail1954@gmail.com*

УДК 008:379.85

*А.Ю. Алекберова*

# АЗӘРБАЙҖАНДА МӘДӘНИ ТУРИЗМНЫ ҮСТЕРҮДӘ АЧЫКҺАВАДАГЫ МУЗЕЙЛАРНЫҢ РОЛЕ

В представленном исследовании отмечено, музеи под открытым небом Азербайджана оказывают большое влияние на развитие туризма, образования и культуры, а также защиту и развитие национальной идентичности. Эти музеи играют важную роль в продвижении культурного наследия страны на мировом уровне и доносят культурное, художественное богатство Азербайджана до мирового сообщества. В качестве примера в статье использованы Гобустанский государственный историко-художественный заповедник, музей под открытым небом, расположенный на территории «Аджами Сейрангахы» в Нахчыване, религиозно-архитектурный комплекс «Сиратаглы» в государственном историко-архитектурном заповеднике «Ичери-шехер», Базарная площадь или Ханагах в селе Гала на Апшеронском полуострове. К исследованию были привлечены музеи Государственного историко-этнографического заповедника «Гала». Подобные музеи играют важную роль в процессе распространения культуры, межкультурного обмена и образования. Они занимают незаменимую позицию в развитии культурного туризма в Азербайджане.

**Ключевые слова:** Азербайджан, культурный туризм, музей, культура, культурное наследие.

The presented study noted that the role of Azerbaijan's open-air museums in cultural tourism has a great impact on the country's past heritage, the development of tourism, education and culture, as well as the protection and development of national identity. These museums play an important role in promoting the country's cultural heritage at the global level and bringing the cultural and artistic wealth of Azerbaijan to the world community. As an example, the article uses the Gobustan State Historical and Artistic Reserve, an open-air museum located on the territory of the "Ajami Seyrangahi" in Nakhchivan, the religious and architectural complex of Siratagly in the State Historical and Architectural Reserve "Icherisheher", Market Square or Khanagah. The complex, the state "Gala" in the village of Gala on the Absheron Peninsula, museums of the Historical and Ethnographic Reserve were involved in the study and their impact on cultural tourism was studied. These museums also play an important role in the process of cultural dissemination, intercultural exchange and education, thus occupying an indispensable position in the development of cultural tourism in Azerbaijan.

**Keywords:** Azerbaijan, cultural tourism, museum, culture, cultural heritage.

Азәрбайҗан мәдәни туризмында ачык һавадагы музейлар зур роль уйный. Бу музейлар – илнең бай тарихын, төрле тарихи чорларга караган һәйкәлләрне, борынгы экспонатларны, мәдәниятне һәм табигатьне күрсәтүче уникаль урыннар. Алар, классик музейлар белән беррәттән, азәрбайҗан халкының мәдәни мирасын саклау, реставрацияләү һәм популярлаштыруга да йогынты ясый.

Әлеге төр музейларга экспозицияләре ачык һава астында урнаштырылган күргәзмәләр керә: скульптура, миниатюра парклары, фигуралы парклар һәм күпсанлы техник (авиация, хәрби техника һәм транспорт һ. б.) музейлар. Шулай ук ачык һавадагы музейларда архитектура корылмалары үрнәкләре тәкъдим ителә ала.

Күп кенә музейларда комплекслы рәвештә аерым бер халыкның үткәне торгызыла. Ачык һавада унашкан музейларда туристлар экспонатлар белән якыннан торып таныша ала. Алар, реконструкцияләнгән киңлеккә эләгеп, аерым илнең яки территориянең тарихы һәм этнографиясе турында мәгълүмат тупларга, мәдәнияте белән танышырга мөмкинлек бирә. Мондый төр музейларның тагын бер өстенлеге илнең икътисади нәтиҗәлелеген күтәрү белән бәйле. Туризмнан кергән керем җирле икътисад өчен дә файдалы булып, халыкны эш урыннары белән тәэмин итәргә дә булыша. Музейлар һәм аларның әйләнә-тирәсендәге туризм инфраструктурасы җирле халыкка мәдәни мирас өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга һәм аны киләчәк буыннарга тапшырырга ярдәм итә. Мондый статуслы музейларның мәгърифәтчелек эшчәнлеге дә биниһая зур: алар – мәктәп һәм университетлар өчен ачык һавада дәресләр үткәрү өчен менә дигән урын. Биредәге экскурсия һәм тренингларны узган студентлар тарих, мәдәният һәм табигать турында мәгълүмат туплый ала.

Ачык һавада музейлар оештыру һәм формалаштыруны тарихи ихтыяҗ дип бәяләргә кирәк. Музей белгече Егана Эйвазова фикеренчә: «Ачык һава астында музейлар булдыруда ике фактор зур роль уйный: халык архитектурасы һәйкәлләрен саклау һәм этнографик коллекцияләр. Мондый музейларны беренчеләрдән булып билгеләп үткән авторлар арасында немец тикшеренүчесе А. Циппелиус һәм поляк галиме Ежи Чайковский була» [2: 449].

Ачык һавада музей оештыру идеясен һәм принципларын XVIII гасырда беренче тапкыр Швейцария галиме Чарльз де Бонстеттен эшли. Швейцариядә 1891 елда Артур Гезелиус бөтен дөньяга билгеле «Скансен» музеен оештыра [6: 6].

Шундый музейлар 1897 елда Копенгагенда, 1902 елда Ослода, 1912 елда Арнемда, 1940 елда Финляндиядә (Туск), Германиядә, Румыниядә, Венгриядә һ. б. илләрдә булдырыла.

1928 елда Рига шәһәрендә (Латвия) ачык һавада этнографик музей оештырыла. 1957 елда Эстониядә «Рок-аль-Маре» музее ачылу XVIII–XIX гасырларда эстоннар тормышы турында ачык күзаллау булдырырга мөмкинлек бирә. Мондый музейлар шулай ук Новгородта, Тбилисидә, Львовта һәм Суздальдә дә эшли. Киев янында ачылганы үзенең масштаблары белән игътибарны җәлеп итә. Ул 200 гектар мәйданны били. Эре экспонатларның саны 200 гә җитә. Биредә 400 еллык торак йорт сурәтләнгән [6: 6].

Мәкаләдә Азәрбайҗанның мәдәни туризмында ачык һавадагы музейларның роле һәм әһәмияте турында мәгълүмат тәкъдим ителә.

Ачык һавадагы музейлар тарихи һәм мәдәни мирасны саклауга һәм аны халык арасында популярлаштыруга хезмәт итә дидек. Гобустан дәүләт тарихи-сәнгать тыюлыгы, Нахчывандагы «Аджами Сейрангахы» музее, «Ичери шехер» дәүләт тарихи-архитектура тыюлыгында Сиратаглы дини-архитектура комплексы, Базар мәйданы яисә Ханагах комплексы, Апшерон ярымутравындагы Гала авылында «Гала» дәүләт тарихи-этнографик тыюлыгы һ. б. борынгы заманнардан алып бүгенге көнгә кадәрге тарихи эзләрне чагылдыра.

Ачык һавадагы музейлар – үзләрендә табигый һәм тарихи мирасны берләштергән үзенчәлекле туризм киңлекләре ул. Биредә туристларга экспонатлар турында, интерактив чаралардан да файдаланып, күп мәгълүмат җыярга мөмкинлек бирелә.

Бу музейлар төрле илләрдән килгән туристларга Азәрбайҗан мәдәнияте һәм тарихы белән танышырга һәм мәдәниятара бәйләнешләр оештырырга ярдәм итә.

Шул рәвешле, Азәрбайҗанның мәдәни туризмында ачык һавадагы музейлар илнең тарихи-мәдәни мирасын саклау, туристларны җәлеп итү, икътисади үсеш күзлегеннән шактый зур роль уйный. Азәрбайджанда мәдәни туризмны үстерүдә аларның позициясе алыштыргысыз.

Азәрбайҗан – кызыклы музей-тыюлыкларга бай ил, алар беренче караштан ук туристлар игътибарын үзенә туплый. Хәзерге вакытта республикадагы 28 музей ачык һавадагы музей статусына ия, шуларның дүртесе («Ичери шехер» дәүләт тарих-архитектура тыюлыгы, Гобустан дәүләт тарихи-сәнгать тыюлыгы, Хан сарае, «Хыналыг» һәм «Миграция юлы» тыюлыгы булган Шекинин тарихи үзәге) ЮНЕСКОның «Кешелекнең матди мирасы» исемлегенә кертелгән. Бу урыннар Азәрбайҗанны дөньякүләм танытуга булыша.

Азәрбайҗанның ачык һавадагы аеруча билгеле тәүге музейларының берсе – Гобустан дәүләт тарих-сәнгать тыюлыгы, дөньядагы иң борынгы торак пунктларның берсе. Тыюлык Азәрбайҗанның Гобустан районында урнашкан. Биредә 1939 елның язында беренче тапкыр борынгы кыяга ясалган рәсемнәр табыла. Фән дөньясына Гобустан петроглифларын беренчеләрдән булып Исхак Джафарзаде алып килә. Ә 1947 елдан башлап бу сурәтләрне системалы рәвештә өйрәнә башлыйлар [11: 176].

Гобустанда табылган байлыкларның тарих һәм мәдәният өчен мөһим роль уйнавын исәпкә алып, Гобустан 1966 елда Дәүләт тарих-сәнгать тыюлыгы дип игълан ителә. Тыюлык зур территорияне били, анда өч тау – Бәюкдаш, Кичикдаш һәм Чингирдаг таулары



Гобустан дәүләт тарихи-сәнгать тыюлыгы

урнашкан [13]. 2007 елда тыюлык ЮНЕСКОның Бөтендөнья матди һәм мәдәни мирасы исемлегенә кертелде. Бу урын илебез һәм чит ил туристларында онытылмас тәэсирләр тудыра. Гобустан, палеолит чорыннан башлап, кешеләр беренче төпләнеп яшәгән урын турында уникаль мәгълүматлар бирә. Бирелгәге табылдыклар Гобустанда бик әүвәл заманнарда яшәгән кешеләрнең көнкүреше һәм хуҗалыгы турында сөйли. Борынгы кешеләрнең тормышы һәм көнкүреше сурәтләнгән кыя рәсемнәреннән тыш, Гобустанның 1000 нән артык кыясында 6000 ләп рәсем табылган [8: 6]. Ачык һавадагы музейда мең еллар элек яшәгән кешеләрнең сәнгате һәм мәдәнияте чагылыш тапкан мәгарәләр һәм тораклар табарга мөмкин. 2011 елда Гобустанда хәзерге заман стандартларына җавап бирә торган музей ачыла. 2013 елда ул «Европаның иң яхшы музее» конкурсында җиңүчеләр исемлегенә кертелә [14].

Ачык һавадагы музейлар Азәрбайҗанның башка төбәкләрендә дә бар. Нахчыван шәһәренең үзәгендә, «Аджами Сейрангахы»да урнашкан бу музей Нахчыван Автономияле Республикасы Югары Җыелышы рәисенең 2002 елның 11 июль карары нигезендә оештырыла. Музей экспонатлары арасында тарих кичкән таш һәйкәлләр, Урта гасырларда яшәгән халыкның бай тарихи-мәдәни мирасын чагылдырган әйберләр, архитектура һәйкәлләре һ. б. бар. Экспозициядә кыйммәтле һәм уникаль таш һәйкәл-экспонатларның дүрт төркеме урнаштырылган, аларның нигезен төзелеш эшләрендә кулланылган колонналар, капительләр һәм колонналарның нигезләре, декоратив тышлыклар, биш тонна авырлыгындагы тегермәннәр, шулай ук безнең дини ышануларыбыз белән бәйле сандыклар тәшкил итә. Сарык сыннары, кабер ташлары, табигатьтәге әзер зооморф фигуралар петроглифлар барлыкка китерә. Моннан тыш, музейда таштан уеп ясалган башка фигуралар, таштагы язулар, кабер ташлары, постаментлар да бар. Безнең ата-бабаларыбыз ясаган таш һәйкәлләр, бигрәк тә Гамигай картиналары тулаем кешелек тарихы турында сөйли. Бары бер генә экспонат – Гамигайдан китерелгән һәйкәл генә пыяла витринага урнаштырылган. Экспозициядә тәкъдим ителгән 450 матди мәдәният үрнәге – Бөек Нахчыван тарихының таштан торгызылган шаһиты.

Бакуда «Ичери шехер»да, Базар мәйданында урнашкан Сиратаглы дини-архитектура комплексы яки милли әһәмияткә ия Ханагах комплексы төзелде. 1964 елда үткәрелгән археологик казулар барышында терраса калдыклары табыла. Ул төрле яктан тротуар һәм колонналы аркалар белән әйләндереп алынган. Археологик казулар нәтиҗәсендә бу участокта 52 кабер булуы ачыкланган. Ишегалды уртасында, каберләр белән янәшә, цилиндр формасындагы кое һәм аннан бераз читтәрәк, көньяк-көнчыгыш тарафта зур колонна булган. Колонна сигез почмаклы өч баскычлы таш аслык өстендә утыра. Табылган матди-мәдәни һәйкәлләр һәм каберләр археологларның бу җирләрнең изге хаҗ кылу урыны булуы турындагы фикерен тагын бер кат раслый.

Тагын бер музей – 1988 елда төзелгән «Гала» дәүләт тарих-этнография тыюлыгы – безнең эрага һәм Урта гасырларга кадәрге мөһим археологик һәйкәлләрне саклау урыны булып тора. Шулай ук бу музейда Азәрбайҗан халкының традицияләрен чагылдырган төрле экспозицияләр һәм матди-мәдәни үрнәкләр тәкъдим ителә [15]. Апшеронда табылган археологик табылдыклар хисабына тыюлыкны алга таба да баету максатыннан, 2008 елда Гейдар Алиев фонды президенты Мехрибан Алиева инициативасы белән Апшерон территориясендә ачык һавада беренче уникаль музей төзелә.

Музей комплексы территориясендә Азәрбайҗанга хас, бигрәк тә Гала авылы һәм Апшерон ярымутравы өчен характерлы археологик архитектура һәйкәлләре җыела һәм реставрацияләнә [16]. Археологик казулар барышында безнең эрага кадәр III–II меңьеллыкларга караган кыя рәсемнәре белән беррәттән, ата-бабаларыбызның яшәү рәвеше, кигән киемнәре, кирәк-яраклары, акчалары һәм шул чорның башка үрнәкләре белән танышырга мөмкин. «Бу территориядә безнең эрага кадәр III–II меңьеллыкларга караган курганнар, торак йортлар һәм башка архитектура һәйкәлләре кабат торгызыла. Музей комплексында борынгы заманнардан һәм Урта гасырлардан ук биредә яшәгән халыкның көнкүреше, хуҗалыгы һәм һөнәрләре турында күп мәгълүмат алып була. Фонд искәртүенчә, бу проект Азәрбайҗанның тарихи үткәнен саклауга гына түгел, илебездә туризмны үстерүгә дә хезмәт итәчәк» [17]. Моннан тыш, интерактив тур дәвамында келәм тукып, балчык чүлмәкләр ясап, борынгы мичтә икмәк пешереп, чын тимерчелек остаханәсендә дә эшләп карарга була. Җирле халыкта да, туристларда да музей комплексында никахлашу һәм сәүдәгәр йортлары белән танышу кызыксыну уята. Туй йортының бер өлеше борынгы келәмнәр һәм матраслар белән бизәлгән. Сәүдәгәр йорты – Гала авылындагы беренче ике катлы йортларның берсе. Комплекс эчендәге X–XIV гасырларга караган замок манара һәм ныгытмалардан тора. Бу дәвердә күзәтү һәм саклау манарасының биеклеге 13,8 метр тәшкил итә. XVI–XVII гасырлар реликты булган ныгытмада X–XVI гасырларда кулланышта булган алтын тәңкәләр, алтын беләзек кисәкләре, керамика үрнәкләре урнаштырылган [18].

«2011 елда “Гала” музей комплексы территориясендә мәгълүмат үзәге, Этник экология үзәге, Антиквариат музее булдырыла, Кәрвансарай-ресторан эшли башлый» [19]. 2011 елда эшли башлаган борынгы экспонатлар урнаштырылган музей Азәрбайҗанның мәдәни мирасын саклау һәм популярлаштыруда әһәмиятле үзәк булып санала. Музей булу һәм аның эшчәнлеге Гала авылының мәдәни тормышына уңай йогынты ясый. Музейга җирле халык та, чит ил туристлары да күп килә. Замок археология-этнография музей комплексына кергән Борынгы әйберләр музее үзенең антиквариаты һәм Апшерон ярымутравының тарихын һәм мәдәниятен чагылдырган башка экспонатлары белән билгеле. Музей коллекциясендә 3000 гә якын матди мәдәният үрнәкләре бар. Әлеге коллекциядән нибары 800 экспонат кына

Борынгы әйберләр музеенда урын алган. «Музейның икенче катында декоратив-гамәли сәнгать әнҗеләре күрсәтелә, өченче катта элек-электән халык арасында кулланышта булган үрнәкләр тәкъдим ителә; алар АКШ та, Германия, Австрия, Бельгия, Россия, Франция, Англия, Иран, Үзбәкстан, Польша, Төркия һәм башка илләрдә җитештерелгән булып, республиканың төрле төбәкләреннән җыела». Бу музей халыкара аренада Азәрбайҗан мәдәниятенең уңай имиджын булдырырга ярдәм итә. Илнең туристлык потенциалын арттырудан тыш, мәдәни дипломатия күзлегеннән дә мөһим [20].

2011 елда Замок музей комплексы территориясендә Замок мәгълүмат үзәге булдырыла. Бу – тамашачыларга мәдәни мирас, музейның һәм тулаем төбәкнең тарихы турында тулырак мәгълүмат бирә торган мөһим киңлек. Әлеге үзәк музей экспонатлары, күргәзмәләр һәм башка мәдәни чаралар турында киң мәгълүмат биреп, музейга килүчеләрнең тәэсирләрен баета. Туристлар һәм кунаклар тыюлык музейлары турында тулы белешмә ала. Монда электробуслар һәм велосипедлар арендага бирелә. Экскурсияләр азәрбайҗан, рус, инглиз, немец һәм француз телләрендә оештырыла [20].

Музей комплексындагы мөһим яңалыкларның берсе – 2015 елда Гейдар Алиев фонды инициативасы һәм ярдәме белән «Калдык-постыктан сәнгатькә» дип аталган уникаль музей бүлеге оештырылу. Әлеге мәдәни үзәктә күрсәтелгән эшләр кешеләр кирәксез дип санаган чүп-чардан (кабель, лампа, шина, пластик су савытлары, целлофан, уенчыклар, төрле автомобиль детальләре һәм башка бик күп файдасыз әйберләр) эшләнгән. Биредә 180 төрле сәнгать үрнәге тәкъдим ителә. Азәрбайҗан осталары эшләре белән беррәттән дөньяның төрле илләреннән килгән рәссамнарның картиналары куела. Кызыклы экспонатлар арасында: тимер кисәкләреннән ясалган сәмруг кош, эшкә яраксыз агачтан эшләнгән ат сыннары, пластик кашыклардан, чәнечкеләрдән һәм пычаклардан ясалган балык сурәтләре һ. б. [21].

Йомгаклап шуны билгеләп үтәргә була: Азәрбайҗандагы ачык һавада урнашкан музейлар туризм, мәгариф һәм мәдәният үсешенә, милли тәңгәллекне саклауга һәм үстерүгә зур йогынты ясыйлар. Бу музейлар илнең мәдәни мирасын дөньякүләм танытуда мөһим роль уйныйлар, Азәрбайҗан сәнгатен һәм мәдәни байлыгын дөнья халыкларына үтемле итеп ирештерәләр.

**Әдәбият**

1. *Aşurbəyli S.* Bakı şəhərinin tarixi: Orta əsrlər dövrü. Bakı: Azərnəşr, 1998, 356 s.

2. *Eyvazova Y.* Tarix və mədəniyyət abidələrinin mühafizəsi. Dərslik. Bakı, 2021, 613 s.

3. *Əliyeva R.* Azərbaycanın dünya əhəmiyyətli abidələri. Bakı, Avropa, 2015. 177 s.

4. *Günay.* Qala Arxeoloji Etnoqrafiq Muzey Kompleksində ilk ekskursiya təşkil olunub // Paritet., 2009. 4–6 aprel. № 34 (1335). S. 8.

5. İlk ekskursiya təşkil olunub Qala Arxeoloji Etnoqrafiq Muzey Kompleksində // İki sahil. 2009. 4 aprel, № 61 (4867). S. 8.

6. *Kərimov E.* Açıq səma altında etnoqrafik muzey // Azərbaycan. 2008. 22 iyul. S. 6.

7. *Qiyasi C.* İçərişəhər Şirvanşahlar sarayı və Qız qalası ilə birlikdə // İçərişəhərin qorunması və inkişafı problemləri: Məqalələr toplusu. Bakı, 2004. 146 s.

8. Qobustan reserve – Heydar Aliyev Foundation. Baku, 2002. 9 s.

9. Qala Arxeoloji Etnoqrafik Muzey Kompleksi haqqında buklet hazırlanmışdır // Azərbaycan. 2008. 25 noyabr, № 264 (5075). S. 3.

10. Qala qoruğu – Heydər Əliyev Fondu. Bakı, 2016. 32 s.

11. *Rüstəmov C.* Qobustan dünyası. Bakı: Azərnəşr, 1994. 176 s.

12. https://az.wikipedia.org/wiki/Açıq_səma_altında_muzey

13. https://news.milli.az/society/217046.html

14. https://unesco.az/index.php/az/articles/material_cultural_heritage/qobustan

15. https://azertag.az/xeber/qala_arxeoloji_etnoqrafik_muzey_kompleksine_info_tur_teskil_edilmisdir-437334

16. https://apa.az/official-news/azerbaycanin-ve-israilin-birinci-xanimlari-qala-arxeoloji-etnoqrafik-muzey-kompleksinde-olublar-768381

17. https://www.anl.az/down/medeniyyet2008/noyabr/medeniyyet2008_noyabr_153.htm

18. https://heydar-aliyev-foundation.org/az/content/view/92/2243/Qala-Arxeoloji-Etnoqrafik-Muzey-Kompleksi

19. https://xazar-ih.gov.az/az/page/96.html

20. https://az.wikipedia.org/wiki/%22Qala%22_D%C3%B6vl%C9%99t_Tarix-Etnoqrafiya_Qoru%C4%9Fu

21. https://azerbaijan.travel/qala-dovlet-tarix-etnoqrafiya-qorugu

***Алекберова Айнур Юсиф кызы,***
*Азәрбайҗан Милли фәннәр академиясе*
*Архитектура һәм сәнгать институтының культурология*
*һәм сәнгать теориясе кафедрасы фәнни хезмәткәре*
*(Азәрбайҗан, Баку)*

***Алекберова Айнур Юсиф кызы,***
*научный сотрудник Института архитектуры и искусства*
*Национальной академии наук Азербайджана*
*(Баку, Азербайджан)*

*alekberova-aynur2019@mail.ru*

УДК 745

***А.К. Җәләлиева***

# ТАТАРСТАНДА НӘФИС КЕРАМИКА СӘНГАТЕ ҮСЕШЕНЕҢ ТӨП ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

В статье автор рассматривает эволюцию художественной керамики на территории Татарстана, а также выявляет и анализирует ключевые тенденции керамики в начале XXI века. Современные керамические произведения Татарстана отражают поиски мастеров, основу которых составляют преемственные связи с искусством прошлого: развитие идей и стилей керамических школ советского времени, обращение к традиционному народному ремеслу, а также стремление к новым пластическим и декоративным решениям. Работа создает возможности для дальнейшего изучения теории и практики регионального керамического искусства и обогащает представление о современном декоративном искусстве республики.

**Ключевые слова:** керамика художественная, керамист, татарская культура, национальный стиль, орнамент.

In the article, the author examines the evolution of artistic ceramics on the territory of Tatarstan and also identifies and analyzes the key trends in ceramics at the beginning of the XXI century. Modern ceramic works of Tatarstan reflect the search for craftsmen based on the continuity of art: the development of ideas and styles of ceramic schools of the Soviet era, the appeal to traditional folk craft, as well as the desire for new plastic and decorative solutions inspired by modern art. The work creates opportunities for further study of the theory and practice of regional ceramic art and enriches the idea of modern decorative art of the republic.

**Keywords:** artistic ceramics, ceramist, Tatar culture, national style, ornament.

Хәзерге Татарстан территориясендә үткәрелгән археологик тикшеренүләр нәфис керамиканың безнең эрага кадәр II меңьеллыктан башлап көнкүрештә кулланылганлыгын күрсәтә. Идел-Кама төбәгендәге неолит, бура һәм Ананьино культураларына караган бу эшләнмәләрне болгар (IX–XIV гасырлар) һәм Казан осталары (X–XVI гасырлар) тагын да үстерә һәм камилләштерә барган.

Чүлмәк ясау белән, нигездә, зур авылларда шөгыльләнгәннәр. XVI гасырдан башлап бу кәсепне күчеп килгән халык та (күбесенчә руслар) үз итә. Көнкүрештә куллану өчен глазурь белән капланмаган бизәкле савыт-саба ясау буенча Питрәч чүлмәк ясау кәсебе әнә шулай барлыкка килә. Осталарның эшләнмәләре эре ярминкәләрдә һәм күргәзмәләрдә катнаша. 1890 елгы зур фәнни-сәнәгать күргәзмәсеннән соң Казан губернасы земство җыелышы 1910 елда Питрәч чүлмәк ясау сәнгати-һөнәрчелек остаханәсе ачу турында карар кабул итә [3: 103]. Анда барон Штиглицның (Александр Людвигович фон Штиглиц) Техник рәсем ясау үзәк училищесын (хәзер Штиглиц академиясе) тәмамлаучылар чакырыла. Җитештерүне башлап

җибәрү өчен Германиядән фарфор үрнәкләре һәм җиһазлар кайтартыла. Укучыларның беренче эшләре 1912 елда узган Бөтенроссия сәнәгать күргәзмәсендә үк танылу ала. Питрәчтә сәнгати дәрәҗәле, рәсем төшерелгән ялтыравыклы керамиканың барлыкка килүе белән без А.И. Ильинскийга бурычлы. Бирелә җирле чүлмәк ясау традицияләренә таянып, пропорциональ формалы гармонияле керамика үрнәкләре эшләнә, аларга бизәкләр төшерелә һәм ялтыравык пыяласыман эремә (глазурь) белән каплана. Бизәк төшерү – «Ильинский мәктәбе»нең характерлы үзенчәлеге. Осталар керамиканың табигый фонына (куе көрән төстән башлап ачык көрәнгә кадәр) зәңгәр, ак, сары һәм яшел үсемлек бизәкләре төшерәләр. Алар арасында Казан татарларында киң таралган үсемлек орнаментының элементлары (тукранбаш, лалә, лотос мотивлары һ. б.) кулланыла [4: 283]. Гражданнар сугышыннан соң, кайбер сәбәпләр аркасында, Питрәч чүлмәк ясау кәсебе акрынлап юкка чыга. 1920 елларның икенче яртысында Бакый Урманче, Казан сәнгать техникумы укытучысы һәм уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары буларак, Казанда Питрәч керамикасын торгызырга омтылып карый. Ул гарәп язулы борынгы үрнәкләр калыбындагы вазаларның берничә эскизын һәм тормыш-көнкүрештә файдаланыла торган әйберләр ясый. 1929 елда остаханә ябыла [8: 66–67].

Озак еллар дәвамында өйрәнелмәгән Болгар һәм Алтын Урда керамикасына 1960–1970 елларда рәссамнар Георгий Зяблицев һәм Борис Шубин игътибар итәләр. Алар күргәзмәләр өчен уникаль әсәрләр дә, тиражлы эшләнмәләр дә ясыйлар. Б. Шубин Урта гасырлар керамикасын реконструкцияли. Керамик савытларның тоткаларына, борыннарына протомалар һәм хайван башлары сурәте төшерелгән була. Аларда зооморф мотивлар, контррельефлы орнаментлар да чагылыш таба. Әлеге серия – рәссамның галим белән иҗади хезмәттәшлеге нәтиҗәсе. Фуад Вәлиев татар сәнгатендә болгар-алан чыганакларын ача, алар буенча эскизлар ясый, ә Борис Шубин аларны керамикада гәүдәләндерә [2: 50].

1980 елларда республика Сәнгать фонды һәм Халык сәнгать промыселлары комбинаты базасында керамика остаханәләре оештырыла. Күргәзмә һәм монументаль панноларны, скульптура композицияләрен, сувенирларны Абрек Абызгилдин, Асия Миңнулина, Нина Кузьминых, Наталья Пилюгина, Рабига Круглякова, Рәбис Сәләхов кебек профессиональ рәссамнар һәм осталар иҗат итә. Шул ук елларда Бөгелмә фарфор заводында, утилитар фаянс савыт-сабадан тыш, керәчтән (фарфор) милли тематикалы сувенир һәм күргәзмә эшләнмәләре дә дөнья күрә [1: 137].

1980–1990 елларда нәфис керамика яңа технологияләр нигезендә төрле формалар ала, бу борынгы сәнгатьнең пластик, конструктив һәм төсләргә бәйле мөмкинлекләрен киңәйтеп җибәрә. Күпләп сәнгать мәктәпләре ачылу һәм яшь осталарның экспериментка тартылуы XX гасыр нәфис керамика сәнгатендә монументаль һәм декоратив

юнәлешләр барлыкка килүгә уңайлыклар тудыра. Материал белән бәйле әлеге экспериментларда декоратив керамиканың архитектура мохитенә актив рәвештә керүе күзәтелә. Рәссамнар Хәмит Латыйпов, Рәбис Сәләхов, Нина Кузьминых, Рөстәм Шәмсутов һ. б. үзләренең әсәрләрендә традицион сәнгать чараларын үстерәләр. Декоратив керамиканы яңача уку ысуллары барлыкка килү илебез сәнгать дөньясында хөкем сөргән яңа заманның гына түгел, ә тулаем алганда төбәк мәдәниятенең йогынтысы белән дә аңлатыла.

Соңгы ике дистә елда Татарстанда заманча керамика сәнгате бик тиз үсә. Җәмәгатьчелекнең кызыксынуы һәм ихтыяҗы зур булу нәтиҗәсендә остаханәләр ачыла, теләге булганнар өчен дәресләр үткәрелә. Җәмәгать урыннарында һәм шәхси интерьерларда авторларның керамик эшләнмәләре (панно, скульптур формалар, савыт-саба) зур популярлык казана.

Татарстан осталары татар гореф-гадәтләренең турыдан-туры варислары ролендә халыкның рухи мирасына, X–XIV гасырлар, Урта гасырлар, болгар керамикасы үрнәкләренә, Казан татарларының XIX гасырда тотрыклы форма алган орнаментына, аның таләпчән матурлыгына, сыгылмалылыгына, төсләр гармониясенә таянып иҗат итәләр.

2021 елдан «ПФК Презент» предприятиесендәге осталар (Алсу Зубкова җитәкчелегендә) борынгы савыт-саба үрнәкләре буенча вазалар, чүлмәкләр, чәйнекләр, кринкалар (тар муенлы чүлмәкләр) эшлиләр. Алар тәбәнәк савытларга дулкынсыман яки авыш штрих сызыклардан торган ялтыравыклы бизәкләрне ачык һәм төгәл итеп төшерәләр. Савытларның авыз һәм тоткаларын XIV гасыр болгар керамикасына хас ат яки тәкә кебек стильләштерелгән хайван фигуралары рәвешендә ясыйлар. Керамик савытларга үзенчәлекле төс бирү өчен осталар яндырганда сөткә салып алу ысулыннан да файдаланалар. Шуның нәтиҗәсендә эшләнмәләр матур төсмер ала.

Урта гасырдагы болгар нәфис керамикасы сәнгате традициясе Нина Кузьминых әсәрләренең стиле камилләшүдә аерым урын алып тора. Нәкъ менә Болгар керамикасының бизәкле пластика теле һәм төсләр гармониясе аның иҗатының төп юнәлешен билгели. «Болгар мотивлары» дип исемләнгән вазалар сериясендә (2014) ялтыравык эффекты һәм тоныкҗиңел төсләр гомумиләштерелгән, стильләштерелгән, пластика һәм ритм өстенлек иткән эшләнмәләр образына ачыклык кертү максатында кулланыла. Н. Кузьминых борынгы үрнәкләрне күчереп куймый, ә ялтыравык, фактура белән тәҗрибәләр ясап, үзенчәлекле эшләнмәләр иҗат итә.

2010 елларда керамик әйберләрнең сәнгати чишелешендә яңа тенденция барлыкка килә – осталар (Н. Пилюгина, Р. Сабиров, Н. Айзятова, Г. Шакирова, А. Тимергалина һ. б.) декоратив тәлинкә һәм панноларны, шулай ук фарфор савытларны бизәүдә татар чигүе һәм күн мозаикасы орнаментларыннан файдаланалар. Наталья Пилюгинаның кулдан бизәк төшерелгән күпсанлы фарфор сервизлары, шулай ук

декольләр композиция ягыннан да, төсләре белән дә аерылып тора. Аның фарфор чәй сервизлары ялтыравык астына һәм ялтыравык өстенә зөбәрҗәт-яшел, зәңгәр-фирәзә төсләр белән бизәк төшерү техникасында язылган. Предмет тулаем чәчәк-үсемлек орнаментлары белән тула, аларның контурлары еш кына тоны буенча нечкә контраст сызыклар белән әйләндереп алынган була. Тамчы яки штрих рәвешендәге алтын буяу белән бергә алар эшләнмәләргә төгәллек һәм тантаналы төс бирә. Оста еш кына чәчәк бәйләме яки оҗмах агачы композицияләрен куллана. Кайчакта декоратив тәлинкәләрнең уртасына татар тормышыннан алынган кызыклы күренешләрне кертеп җибәрә.

«ПФК Презент» фирмасы осталары ясаган чынаяк һәм тәлинкәләр дә игътибарны җәлеп итә. Аларга җете төсләр белән күн мозаикасында кулланыла торган рельефлы бизәкләр (соляр билгеләр, үсемлек һәм зооморф мотивлары һ. б.) төшереп, ялтыравык белән каплыйлар. Бизәкләр еш кына сызып ясала һәм төсле пыяласыман ялтыравык катлам белән баетыла. Эшләнмәләрнең төсләр гаммасы исә татар чигүләренә һәм агач архитектурага нигезләнә.

Традицион тукучылык һәм күн мозаикасы орнаментларына Гүзәл Шакирова да мөрәҗәгать итә, әмма ул башка техник алымнардан (декоратив тиснение) һәм монохром төсләр гаммасыннан файдалана. Кырыйлары махсус тигез итеп эшләнмәгән плакетка һәм тәлинкәләрне автор архаик орнаментлар һәм яфрак эзләре белән бизи. Автор кулланган фирәзә һәм зәңгәр төсле пыяласыман ялтыравыклар эшләнмәләрне аеруча нәфис итә. Аларда Көнчыгышның Урта гасырлар монументаль рәсемнәре йогынтысын тоябыз.

Рәссам Алсу Тимергалинаның керамик сыннарында да («Тормыш агачы», 2021; «Яз», 2019) декоратив тәлинкәләрендә дә милли стильне табарга тырышуы сизелә. Нигездә, автор образларны орнаменталь мотивлар, еш кына зооморф (сарыклар, кошлар) символикасы аша тудыра. Бизәк төшергәндә ул, гадәттә, ачык, куе, төрле төсле ялтыравык куллана («Кошлы тәлинкә», 2019; «Казан», 2018 һ. б.).

2003 елдан башлап бүгенге көнгәчә рәссам Наталья Пилюгина, рус Питрәч керамикасын бизәү принципларына таянып, балчык чүлмәкләрне бизәү сәнгатен үстерә. Ул иң яхшы үрнәкләрне реконструкцияли һәм үз эшләнмәләрен дә тәкъдим итә. Аның иҗатына түбәндәге үзенчәлекләр хас: савытлары ныклы һәм тәбәнәк формалы; аларның авызлары киң, тырнап ясалган контррельефлы орнаментлар төсле ялтыравык белән капланган [5: 110].

XXI гасырның беренче чиреге керамика скульптурасы Нина Кузьминых һәм Андрей Махинин иҗатында чагылыш таба. Н. Кузьминыхның станок скульптураларында, статик булуларына карамастан, ниндидер эчке хәрәкәт сиземләнә. Оста формалар пластикасын бик яхшы тоемлый, төрле декоратив принципларны белеп куллана. Композицияләрдә автор хатын-кыз образының төрле чорларын тасвирлый: ана булу, балачак, яшьлек еллары («Карт кыз», «Башлану»; 2009

һ. б.). Аның хәтта мифологик һәм зооморф фигуралары да үтә нәфис («Су кызы», «Кошлар тормышыннан» сериясе; 2010). Аларда аксыл төсләр гаммасы өстенлек итә. Н. Кузьминых керамикада анималистик скульптура жанрын да үстерә («Кошлар», «Балыклар» серияләре; 2000–2012).

Андрей Махининның рельефлы һәм скульптур композицияләре жанр трактовкасына тартым. Аларда автор гади, вакыты-вакыты белән бераз сәер кешеләр яшәгән провинциаль шәһәр образын чагылдыра. Болар, нигездә, – панно, плакетка һәм кечкенә скульптура формалары. Аларда йомшак кына ирония, ихлас елмаю; аларда кешеләр, кеше һәм табигать, кеше һәм аны чолгап алган предметлар дөньясы арасында гаҗәеп гармония чагыла. Ул эшләр үзенә күрә «портретлар», керамикада гәүдәләнеш тапкан «тарихлар» («Бүләк», «Зиночка китте», «Беренче май», «Карт булса да, үземнеке»; 2023). Шома өслекләрнең һәм фактуралы, тәфсилләп эшкәртелгән күпертмә бизәкләрнең чиратлашуы нәтиҗәсендә кызыклы эффектларга ирешелә. Оста декорда ангоблар, ялтыравыклар, оксидлар, төрле ысул белән фактуралар төшерә («Авыру тычкан»; 2022 һ. б.). Эшләрен рәсмиләштергәндә еш кына агач детальләр, тукымалар, сирәк кенә металл да куллана. Фактура һәм материалның ярашуына мисаллар: «Менә 17 дә булды. Яки бал кортлары сырып алган» (2017), «Ханым өчен йөрәкләр» (2022) һ. б.

Руслан Сабиров шәһәр темасын ача. Автор үзенең яссы композицияләрендә архитектура пейзажларын рәсемгә төшерә. Төсле пыяласыман эретмәләр белән язылган рәсемнәр акварель этюдларын хәтерләтә.

Россиядә туризмның үсә баруы нәтиҗәсендә керамик әйберләр коллекцияләре белән кызыксыну артты. Җирле милли традицияләрне чагылдырган вак пластика, декоратив панно рәвешендәге сувенирларның тулы бер катламы барлыкка килде. Бу бигрәк тә «Презент», «Шәмәрдән балчык уенчыгы» һ. б. осталары эшендә чагылыш таба.

«Шәмәрдән балчык уенчыгы»на Балалар сәнгать мәктәбенең сәнгать бүлеге базасында 1990 еллар ахырында нигез салына. Р. Закирова һәм аның укучылары шул тирәдә чыгарылган балчыктан бүген дә татар халкының тарихын, көнкүрешен һәм мәдәниятен чагылдырган уенчыклар, сувенирлар ясыйлар. Бизәк төшергәндә милли орнамент кулланыла һәм күптөслелек саклана.

Мөселман сәнгате мирасы һәм заманча сәнгать юнәлешләре Рөстәм Шәмсутов һәм Ландыш Садретдинова иҗатларында гармонияле рәвештә яраша. Панно серияләре, гарәп язуы һәм татар орнаментлары белән бизәлгән декоратив тәлинкәләр авангард стилендә башкарылган. Л. Садретдинова балчыктан гарәп каллиграфияле дивар паннолары («Аллаһ», «Бисмиллаһ»), «Җәй» тәлинкәләр сериясен (2018–2022) иҗат итә.

2014 елда рәссам, каллиграф һәм балчык осталарыннан торган төркем (Р. Шәмсутов, Ә. Исхакова һ. б.) тарафыннан эшләнгән «Татар

язуы тарихы» монументаль панносы керамикада каллиграфия сәнгатен куллануга ачык мисал булып тора. Ул панно Татарстан Республикасы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогында сәләтле балалар өчен мәктәп диварларын бизи [7: 52–53]. Паннода татар язуының дүрт чоры күрсәтелә: рун һәм гарәп язулары, латин һәм кирилл хәрефләре нигезендәге алфавитлар. Панно өчен материал булып смальта, ARCH-SKIN[1] һәм бизәк төшерелгән керәч плитәләр хезмәт итә. Авторлар X–XII гасырлар Идел Буе Болгар дәүләте чорына караган һәм Алтын Урда дәверендә дә үсеш алган керамик әйберләрдә һәм архитектура корылмаларында эпиграфика куллану традицияләрен дәвам итәләр (Хан төрбәсендәге, Кече манара бинасындагы бизәкле майоликаны искә төшерик) [6: 271].

Яңа технологияләр белән тәҗрибәләр ясау, төрле материаллар белән мавыккан рәссамнар Лилия Григорьева һәм Юлия Айтуганованың хезмәтләре игътибарга лаек. Шуңа күрә дә формасы һәм фактурасы буенча үсемлекләрне, диңгез суүсемнәрен һәм кабырчыкларны, агач кабыгын хәтерләткән биоморф керамик эшләнмәләр (вазалар, тәлинкәләр, сервизлар, яктырткычлар) заманча торак һәм җәмәгать биналары интерьерларында («Чирәм», «Җәй» ресторанннары һ. б.), шулай ук кафетерий, матурлык салоннарында, Казанның төрле студияләрендә үз урынын тапты.

Шулай итеп, XXI гасырның беренче чирегендә Татарстан осталары өчен халык сәнгате бетмәс-төкәнмәс иҗат чыганагы булып тора. Әсәрләрдә традицион формалар һәм декор заманча эчтәлек ала. Скульптура керамикасында осталар рәсем сәнгатенең төрле чараларын берләштерәләр, кешеләр тормышыннан алынган сюжетларны, шулай ук архитектура мотивларын, табигать формаларын кулланганда фәлсәфи караш өстенлек итә. Төбәк керамикасының үзенчәлекле сыйфаты – хәзерге Татарстан территориясендә яшәгән борынгы мәдәниятләр сәнгатьле мирасының дәвамчанлыгын күрсәтүдә. Балчык осталарының эзләнүләре, күбесенчә, күн мозаика, чигү, каллиграфия кебек татар орнамент сәнгате традицияләрен иҗади куллануга нигезләнә.

Әмма хәзерге заман керамика сәнгатендә кайчандыр Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы шәһәрләрендә (X–XV гасырлар) дан тоткан ялтыравык бизәкләр, майоликалар җитәрлек дәрәҗәдә үсеш алмаган. Осталар Россия башкалаларында һәм чит илләрдә популяр булган сәнгать стильләренә (авангард, минимализм, гиперреализм, концептуализм һ. б.) сирәк мөрәҗәгать итәләр. Бүгенге көндә, кайбер сәбәпләр аркасында, парк скульптура композицияләре һәм панно рәвешендә монументаль формалар ясалмый. Нәфис ке-

[1] ARCH-SKIN керамикасы – балчык, кварц комы һәм кыр шпаты кушылмасыннан торган бизәү плитәләре. Алар, максималь зурлыгы 1600/3200, калынлыгы нибары бер-ике мм булганда, ныклык, озакка чыдамлык буенча иң югары күрсәткечләргә ия. Чыганак: http://stroymaster-base.ru/stroitelstvo-doma/otdelochnye-materialy/keramika-arch-skin-material-hhi-veka.html

рамиканы үстерү өчен, симпозиумнар һәм чүлмәкчелек осталыгы фестивальләре, осталарга грант ярдәме күрсәтү, иң яхшы үрнәкләр коллекциясен формалаштыру өчен дәүләт сатып алулары, монументаль панно һәм скульптуралар ясау өчен дәүләт заказлары булдыру кебек чаралар оештыру сорала. Халык сәнгать кәсепләрен, һөнәрләрен һәм декоратив-гамәли сәнгатен торгызу, саклау, өйрәнү һәм үстерү максатында (элеккеге Үзәк универсаль кибет (ЦУМ) бинасында) үзәк булдыру буенча хөкүмәтнең зур тырышлык куюы бу борынгы сәнгать төренең дә динамик үсүенә китерер дип ышанасы килә.

**Әдәбият**

1. *Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Декоративное искусство Татарстана: 1920-е – начало 1990-х годов: монография. Казань: Фән, 1995. С. 129–137.

2. *Гулова Ф.Ф.* Некоторые тенденции в развитии декоративно-прикладного искусства // Взаимодействие интернационального и национального в изобразительном искусстве Татарстана / отв. ред. Н.З. Саттарова. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1981. С. 42–54.

3. *Махинин А.Ю.* Деятельность Казанского губернского земства по открытию гончарной художествено-ремесленной учебной мастерской в селе Пестрецы Казанской губернии // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. 2011. № 4. С. 101–104.

4. *Махинин А.Ю.* Орнамент пестречинской керамики // Познавая образы мира: культура и искусство в прошлом и настоящем: сб. ст. Вып. 1 / КГУКИ; ред. М.П. Файзулаева. Казань: АСТОРИЯ, 2008. С. 281–290.

5. *Менгден Е.Н.* Традиционные основы Пестречинской художественной керамики: историко-культурный контекст // Многогранный мир традиционной культуры и народного художественного творчества: Материалы II Всерос. науч.-практ. конф. с междунар. участием, Казань, 29 марта 2022 г. Казань: Казанский государственный институт культуры, 2022. С. 108–112.

6. *Носкова Л.М.* Строительная керамика // Великий Болгар. М., Казань: Феория, 2013. С. 270–273.

7. *Сафиуллина-Аль-Анси Р.Р.* Музей истории тюрко-татарской письменности: от идеи создания до реализации / Р.Р. Сафиуллина-Аль Анси, Г.Ф. Замалетдинова // Tatarica. 2016. № 1(6). С. 43–58.

8. *Урманче Б.* Татарские художники и Казанская школа искусств // Татарстан. 1996. № 4. С. 64–73.

***Җәләлиева Айгөл Каниф кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре*

***Залялеева Айгуль Канифовна,***
*научный сотрудник Центра искусствоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*aigul.siraieva@yandex.ru*

УДК 391

***Э.В. Брусков***

# БИЛБАУНЫҢ МӘГЪНӘСЕ
# ҺӘМ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В статье рассматривается сакральное значение пояса, сопровождавшего человека с глубокой древности, от рождения до самой смерти. Доказывается, что пояса отразили условия бытования и сохранения этноса в культуре, обладающей мощным механизмом противодействия хаосу и смерти в системе мироздания, открывшейся древнему человеку в силу его мифологического мировосприятия.

**Ключевые слова:** пояс, традиция, символы, сакральность, оберег, круг, миф, мифологическое мировоззрение, архетип.

The article deals with the sacral significance of the belt, which accompanied man from ancient times, from birth to death. It is proved that the belts reflected the conditions of existence and preservation of ethnos in the culture, possessing a powerful non-entropic mechanism of counteraction to chaos and death in the system of the universe, revealed to ancient man by virtue of his mythological worldview.

**Keywords:** belt, homeostasis, tradition, symbols, sacredness, amulet, circle, spiral, myth, mythological worldview, archetype.

Халык традициясе, традицион кием атрибутлары турында сөйләү өчен, безгә борынгы бабаларыбызның тормыш-көнкүреш шартлары, теге яки бу объектларны булдыруга һәм үзенчәлекле итеп бизәүгә мотивация биргән, шулай ук алардан файдалану тәртибен билгеләгән, куллану өлкәсенә нигез булган психофизик халәтләр турында беркадәр күзаллау тудыру зарур. Бу – ерак үткәндә калган бик борынгы заманнар, һәм ул бездән тирән ретроспектив анализ, фольклорны һәм дини карашларны игътибар белән өйрәнүне таләп итә. Чөнки без бүген эстетик күзлектән кабул иткән әйберләрнең (орнаментлар, бизәнү әйберләре, йолалар, кием һәм торак атрибутлары) күбесе кайчандыр магик мәгънәгә ия булган.

Борынгы бабаларыбызның дөньяга карашы мифологиягә нигезләнү сәбәпле, аларның яшәү рәвеше һәм гамәлләрендә берни дә чиста утилитар төс алмаган, барысы да сакраль булган. Бүгенге көндә аерым булып тоелган бөтен нәрсә бербөтен тәшкил иткән, мәңгелек ритуалга әйләнгән, барысы да безнең бабаларыбыз тарафыннан Космос – борынгы кешегә бербөтен булып күренгән дөнья тәртибе белән синкретик бергәлектә дип кабул ителгән.

Бу тикшеренүнең предметы булып торган билбаудан (пояс) бик борынгы заманнардан ук кеше туганнан алып үлгәнче аерылмаган. Ул һәрвакыт сакраль әһәмияткә ия булып, киемне бизәп торган. Бу – хәтер төпкелләребездә сакланган, хәтта йөз еллар узгач та, мөгаен, әлеге кием деталенең күпфункцияле һәм аның турында мәгълүмат-

ның тулы булуы аркасында, бездә бөтен бер ассоциатив бәйләнешләр һәм хисләр ташкыны рәвешендә чагылган.

Дөнья турында мифологик күзаллауны чагылдыруда да пояс төшенчәсе киң кулланыла. Аның төпкелендә архетиплар ята: әйләнбәйлән, өзлексез әйләнеп тору, әйләндереп алу, түгәрәк, астероид пояслары, вакыт пояслары, климат пояслары һәм бабаларыбызның ритуал пояслары. Алар барысы да кешенең, ул барлыкка китергән әйберләрнең фрактальлеге турында сөйли: кеше – дөньяга, ә дөнья кешегә охшаган.

Бик борынгы заманнардан ук күп кенә халыкларда билбау көчле бөти (тылсым) булып саналган. Билгә буылган билбау кеше тирәли түгәрәк ясап, аны әйләндереп алган, бу төрле мәдәниятләрдә электэлектән бик көчле символ булган. Н.В. Гогольнең «Вий» әсәрендәге Хома Брутны гына искә төшерик: ул, нәҗестән саклану өчен, үзе тирәли түгәрәк сыза. Язучы бу образны уйлап тапмаган, ә шул заманның мифологиясеннән һәм ышануларыннан алган. Славяннар түгәрәкне «коло» дип атаганнар, әмма «коло» әле ул – дөнья күчәре дә (кол), аның тирәсендә барысы да, шул исәптән йолдызлар да (мәсәлән, Котып йолдызы тирәсендә Олы һәм Кече җидегән йолдызлары) әйләнә. Җирдә ялгыз терлекне көтүлеккә җибәрү өчен, казык кагып, аркан белән шуңа бәйләп куялар, һәм ул казык тирәли әйләнеп йөри торгач, тояк эзләреннән түгәрәк ясала; ике түгәрәктән торган тегермән ташында бодай һәм башка бөртекле культуралардан он тарттыралар, әлеге түгәрәкләр тәгәрмәчләрнең борынгы прообразы булырга мөмкин. Бу – билгеле бер күчәр тирәсендә формалашкан күчмә чатыр һәм авылларның түгәрәк рәвешен алуы да, җеп эрли торган орчыклар да. Ягъни «коло» – бер яктан, күчәр һәм әйләнә, тотрыклылык һәм хәрәкәт, язмышка яки үлемгә буйсыну, икенче яктан, тормыш куласасы һәм дөньяны танып белү һәм үзләштерүдә бетмәстөкәнмәс мөмкинлекләргә ия булу, күплекне бердәмлеккә кайтару һәм үз-үзеңә кайту.

Болар исә ата-бабаларыбызның телендә, эшләнмәләрендә һәм гамәлләрендә чагылыш тапмый калмаган. Рус телендәге «коло», «хоро», «коро» тамырлы барлык сүзләр – коловрат, хоровод, корона, кольцо, колесо һ. б. [8: 141] – түгәрәкнең пространство-оештыру, барлыкка китерү мәгънәләре белән бәйләнгән. Ул Кояшны, шулай ук Җирнең һәм аның тирәсендә башка планеталарның хәрәкәтен, тормыш агымын, вакытның туктаусыз үзгәреп торуын, цикллылыгын, объектив чынбарлыкның чиксез һәм өзлексез булуын гәүдәләндергән. Түгәрәкнең төп функцияләренең берсе эчке һәм тышкы пространствоны аеру булганга күрә, ул – идеаль саклагыч форма, һәм аның эчендәге бернәрсәгә дә дошман кул суза алмый, шуңа күрә дә кешене әйләндереп алган бар нәрсә аны яклый һәм саклый.

Славяннар билбауны һәм түгәрәк рәвешендәге яканы шуның белән бәйлиләр. Билбау кендек өстеннән уза, ул – аның яшәү тирәлеге, аның тормыш башлангычы, шуңа күрә аны һичшиксез саклагыч

орнамент белән каплыйлар. Без үзебез өчен бик тә кадерле һәм әһәмиятле нинди дә булса предметны шул рәвешле бизибез. Саклагыч билбау турында сүз барганда исә шунысы мөһим: аның меңнәрчә еллар дәвамында сакланып калган формасы, материалга (тукыма, күн, металл) һәм билгеле бер утилитар (борынгы кеше мифологик-сакраль мәгънәдә аңлаган) функцияне башкару зарурлыгына бәйле булу сәбәпле, үтә консерватив булып чыга, ягъни дөнья турында иң беренчел, глобаль, төп күзаллауларны гына чагылдыра, әмма дөньядагы катлаулы күзаллауларны колачлый алмый. Биредә үзенең сыгылмалылыгы һәм үзгәрүчәнлеге аркасында объектив чынбарлык турында күзаллауларны чагылдыруга җайлашкан сурәт «ярдәмгә» килә. Бүген безгә квадратлар, түгәрәкләр, өчпочмаклар, төсле таплар җыелмалары һ. б. булып күренгән күпсанлы сурәтләр – дөньяга карашның универсаль борынгы сәнгать теле белән белдерелгән иң катлаулы төшенчәләре [2: 10].

Билбауның саклагыч функциясе күпкатлы: кызыл төс өстенлек итә, чөнки билбау – кояш, кояш нурлары символы; аңа аерым догалар һәм им-томнар чигеп төшерелә, алар орнаментның бер өлешен тәшкил итә; буыннан буынга тапшырыла торган төрле нәсел тамгалары, Күк атлары, сугышчыларның бөек яклаучысы Кояш-Ярила, һәркемне һәм һәрдаим яклаучы Тормыш агачы образлары, ир-ат «тәреләре» һәм хатын-кыз «түгәрәкләре», әфсенле махсус төеннәр һ. б. кулланыла.

Без күзаллаганча, билбау – костюмның өлешләрен тоташтыра торган элемент. Әмма эш шунда ки, билбауны кием өстеннән генә түгел, ә аның астыннан ялангач тәнгә дә буганнар, бу аның семиотик кыйммәтен раслый. «Пояс воплощал суть идеи “одетости”, по отношению к которой сама одежда имела дополнительный и даже факультативный смысл... В этом плане пояс расценивался как некая сверходежда, как знак в ряду тех сигналов (акустических и визуальных), которые ориентированы на установление дистанции между человеком и всеми другими существами. Не случайно именно пояс (и крест), точнее, ношение этих предметов считалось необходимым и достаточным указанием на принадлежность миру людей» [1: 5]. Халык арасына яланаяк яки баш киемсез чыгучыны түгел, ә билбаусыз чыккан кешене шелтәләгәннәр. Кешенең билбавын тартып алу, чишү аны хур итү, социаль һәм мәдәни өлкәдән чыгаруны аңлаткан.

Шунысы әһәмиятле: яңа туган баланы кеше арасына кертү нәкъ менә билбау буу йоласыннан башланган, аңарчы нарасый башка дөнья вәкиле дип саналган. Этнограф Е.В. Барсов (1836–1917) сүзләренә караганда, баланың урсай анасы аңа билбауны беренче алты атна эчендә бәйләргә тиеш булган, югыйсә сабый үләргә мөмкин икән. Шулай ук, әгәр баланың билбавы булмаса, аны бичура һәм удельницалар ешрак урлый, дип ышану да яшәгән. Бала үскән саен, урсай ана аңа билбауның зуррагын бәйләгән. Шулай итеп, дөньяга килгән кеше гомере буена талисманлы булган, соңгысы кеше белән әйләнә-тирә дөнья арасында медиатор ролен үтәгән.

Билбау кеше гәүдәсенең өске – «чиста» һәм аскы – «нәҗес» өлешләре арасында символик чик ролен үтәгәнгә күрә, кешенең аны ничек йөртүе әһәмияткә ия була. Билдән түбән чукыну гөнаһ дип саналу сәбәпле, руслар гыйбадәт кылганда, тыюны бозмас өчен, билбауларын мөмкин кадәр аскарак төшерергә тырышалар. Иске йолачыларның кайбер төркемнәрендә дә гыйбадәт вакытында билбауны салу гадәте, ихтимал, шуның белән бәйледер, ә кайбер районнарда хәтта билбау буган ир-атларга чиркәүгә керү дә тыелган [5: 230]. Аерым өлкәләрдә билбауны өскәрәк күтәреп, күкрәк астыннан ук бәйләгәннәр. Гомумән билбау буу ысуллары кешенең җенесенә, яшенә һәм җирле традицияләргә бәйле рәвештә үзгәреп торган.

Билбау буу бурычы белән беррәттән, кайбер очракларда, инде әйтеп үткәнебезчә, аны, киресенчә, һичшиксез салырга кирәк була, әйтик, теге дөнья белән бәйләнешкә керүгә бәйле тылсымлы гамәлләр кылганда: күрәзәлек иткәндә, Иван Купала бәйрәменә каршы төндә абага чәчәге эзләгәндә, эпидемияләр вакытында авыл тирәли җир сөреп чыгу йоласында, чит кешенең иген кырында спораларны юкка чыгарганда (магик караклыкның бер төре) һ. б. Шул ук вакытта билбауны үзе салучы «чит» кешегә әйләнә, ул – бөтенләй үк кеше дә түгел. Билбауның булмавы мәдәният өлкәсеннән чыгарылган вакытка күчеш халәтендә булган кешене (бала табучы, кәләш һ. б.) маркировкалый. Мәсәлән, бала табучы хатынның билбавын чишеп җибәрә торган булганнар. Бу башка дөньядан фани дөньяга күчешне җиңеләйтергә тиеш, дип ышанганнар.

Малайларга билбау буу аларның башка яшь төркеменә күчүен символлаштырган, бу аңа өйләнү хокукы да һәм социальләшү белән бәйле календарь йолаларда катнашу мөмкинлеге дә биргән. Билбау кешене хезмәт белән бәйләгән, хакимлек биргән, багышлау, үтәүне белдергән, батырлык һәм намусны символлаштырган. Һөнәр мәктәбе укучысын остага багышлау йоласы вакытында аңа билбау буу һөнәри хезмәткә әзерлекне билгели. Тора-бара билбауның кулланылыш даирәсе тагын да киңәя.

Җеназа йоласында да билбау үлгән кеше киеменең мәҗбүри элементы булган. Безнең ата-бабаларыбыз фикеренчә, үлгән кешене ансыз «теге дөньяга» кертмәүләре дә ихтимал. Мәетне өйдән алып чыкканда, туганнары, тагын да үлүчеләр булмасын дип, шулай ук хуҗа бөтен терлекне үзе артыннан «теге дөньяга» тартып кертмәсен өчен, капканы билбау белән бәйләп куйганнар.

Башка өлкәләрдә үлгән кешенең билбавын тылсым белән дәвалау вакытында куллану өчен саклаганнар яки хәерчеләргә биргәннәр. Мәет салынган арбага җигелгән атны зиратка тезгененнән түгел, аның урынына бәйләнгән билбаудан тотып алып барганнар.

Ире үлгән очракта, тагын бер тапкыр кияүгә чыгарга җыенган хатын мәрхүмгә «үлем билбавы»н бәйләргә тиеш түгел. Әгәр ул аны бәйли һәм аннары кияүгә чыга икән, аның гаилә тормышы барып чыкмаячак.

Бала мәетенә кидерелгән күлмәк өстеннән һичшиксез билбау бәйләгәннәр – «теге дөньяда» Алла яки фәрештәләр үлгән балаларга алма өләшә, алар аны куеннарына сала, дип саналган. Билбаулары булмаса, алмалар күлмәк астыннан тәгәрәп төшәчәк [5: 230].

Билбау ярдәмендә убыр һәм сихерчеләрне авызлыкларга мөмкин булган. Терлекне беренче тапкыр көтүгә куганда ук билбауны бусага астына яки каршыга куеп, күз тимәсен өчен, сыерның мөгезенә яки муенына ир-ат каешы бәйләгәннәр. Сыерны үз билбавы аша куып, хуҗабикә аны үзенә буган, һәм сыерны йортка «бәйләү» өчен, көтү кергәнче салмаган. Юрий көне алдыннан, сарыклар билбау аркылы үтсен өчен, аны утар ишеге төбенә салганнар. Убырлар сарыкларның сөтен саумасын дип, аны таң атканчы шунда калдыра торган булганнар.

Билбау авыруны башка объектка тапшыру ысулы булып та кулланылган. Бизгәкле авыру урманга барып, усак агачы эзләп табарга һәм аннан ялварып сорарга тиеш булган: «Усак, усак, минем чиремне ал һәм сәламәтлек бир». Шуннан соң билбавын усакка бәйләгән. Кешеләр, билбауны төрлечә сихерләп, кешегә зыян салып була, дип тә ышанганнар.

Билбауларны тормыш циклы белән бәйле барлык йолаларда файдаланганнар. Туй йоласында аларның әһәмияте аеруча зур булган. Борынгы традицияләр буенча, алар кызыл төстә булган. Бу төс туй вакытында кияү белән кәләшнең аерым халәтен символлаштыра дип саналган, ул яман күздән, усал көчләрдән саклаган. Кул эше осталарының һәрберсе туйга йөз һәм аннан да күбрәк билбау эшләп, аларны кияүгә, туганнарына, дусларына бүләк иткән. Кыз яшьтән үк бирнә белән бергә билбаулар да әзерләгән. Билбау буганда, кияүнең ялангач тәненә 40 төенле яки бөтерелгән, им-томлы йон җеп бәйләгәннәр. Кияү белән кәләшкә, сихерче бозмасын дип, кара билбау буып куйганнар. Билбаулар белән туй арбасының дугасын да бизәгәннәр. Кайвакыт кияү белән кәләшне бер билбау белән бәйләп куя торган булганнар. Күп җирдә кәләшне өйгә билбау ярдәмендә тартып алып кергәннәр. Рус халкында өй туе уздырганда хуҗа кеше гаиләнең калган әгъзаларын йортка билбау ярдәмендә тартып керткән.

Барлык халыкларда диярлек билбауның булмавы – теге дөньяга карау билгесе, дип ышану бар: мәсәлән, су аналары фольклорда ялангач яки ак күлмәкле итеп тасвирлана, әмма һәрвакыт аларның путасыз булуы ассызыклана.

Этнограф Н.И. Гаген-Торн чувашларның традицион киемнәрен тасвирлаганда, аларның билбау һәм билбау бизәкләре, мордва, удмурт һәм марилардагы кебек үк, милли костюмның мәҗбүри атрибуты булуын әйтә. Моннан ул шундый нәтиҗә чыгара: билбауны культ белән бәйләп карау килеп чыгышы буенча күк культына түгел, ә җитештерү үзенчәлекләре белән бәйле ыру аермасына барып тоташа. Ягъни билбауның булу-булмавы ыру аермасы буларак та кабул ителгән: билбаусызлар – чит кешеләр, ә билбау буып йөрүчеләр – үзләренекеләр.

һәм бу аерма тиздән изгеләштерелә, ә билбау аның физик маркерына әверелә.

Шулай итеп, билбауның сакраль генә түгел, мәгълүмати әһәмияте дә булган: очраган кешенең билбавына карап, аның тумышы белән кайдан, ата-бабаларының кемнәр булуын, һөнәре, гаиләсе, балалары, рухи үсеш дәрәҗәсе һ. б. бик күп нәрсәләр турында белә алганнар.

Бил каешыннан (хәрби кирәк-яракларга кергән күн каешларны шулай атап йөрткәннәр) кала бөтен билбаулар җептән эшләнгән. Билбауларны үреп, тегеп, тукып һәм чүпләмле итеп, ягъни җепләрне махсус сайлап тукып эшләгәннәр. Җепләр үзләре, эрләү процессы кебек үк, махсус сакраль мәгънәгә ия булганнар. Күп кенә мәдәниятләрдә эрләнмәгән материал хаосның прообразы булып тора, ә эрләү дөньяның ярала башлавын символлаштыра. Шул рәвешле, кеше структурасыз һичбер нәрсәдән – формадан мәхрүм йон һәм җитеннән, бөтереп һәм әйләндереп, тәртипкә салып, нәрсәдер – очсыз-кырыйсыз җеп эрли, аннары аннан ниндидер берәр әйбер, эшләнмә тукымакчы, үрмәкче була.

Җепләрдән, бөтен кагыйдәләрен саклап, билгеле бер күтәренке рух белән билбау үргәннәр, бөтергәннәр яки тукыганнар, аны саклагыч орнаментлар, төрле уңай символлар белән бизәгәннәр. Йомык боҗрасыман һәм төенләп бәйләнгән шундый билбау киемнең энергетик яктан катлаулы һәм мистик атрибутын тәшкил иткән: ул кешене якларга, эшләрендә ярдәм итәргә, аның тормышын шатлык һәм бәхеткә күмәргә сәләтле дип саналган. Нәкъ менә шуңа күрә, гадәттә, ялангач тәнгә киелә торган билбауларны салмыйча киеп йөргәннәр. Буылган билбау, кешене бербөтен итеп җыйган, һәм ул шул рухта җыелган, беркетелгән, бөтен төен булып, тышкы дөнья белән үзара бәйләнешкә керткән.

Шулай итеп, билбау традицион халык киеменең мәҗбүри элементы булган, утилитар роль башкарган, киемдә XVII гасырның икенче яртысында гына барлыкка килгән кесәне алыштырган, зур семиотик кыйммәткә ия булган. Аны йөртү үзенә күрә рухи бурыч саналган, ул җенси һәм рухи башлангычлар арасындагы чикне билгеләгән һәм кешенең статусын һәм социаль хәлен билгеләүче символ булган.

Тарихчы-этнограф С.В. Суслова билбауның борынгыдан ук традицион татар киеменең мәҗбүри атрибуты булуын билгели. «Им подпоясывали исключительно верхнюю одежду. Важная социальная, магическая и обрядовая функция мужских поясов хорошо известна со времен “всаднической культуры” золотоордынского периода татарской истории. К поясному ремню справа и слева на кожаных ремнях, как правило, подвешивались часто в орнаментированных футлярах бытовые предметы, аксессуары, ремесленный инструментарий, амулеты. Эта древняя традиция – все свое иметь при себе – в качестве рудимента дожила у кочевых в прошлом народов вплоть до XX в.» [6: 221].

Этнограф һәм сәяхәтче Иоганн Георгиның «Описание всех народов Российского государства, их быта...» (1799) дигән хезмәтендә түбәндәге юлларны укыйбыз: «Как прямые Казанские, так и вышедшие от них носят рубахи холстинныя, широкия штаны… подпоясываются же поясом или сабельною перепояскою» [4: 12].

Керәшен татарлары күлмәк өстеннән тар үрмә (яки шнур рәвешендәге) «эзәр» такканнар. Бу термин керәшеннәрдә, мөселманнардагы кебек үк, өске кием өстеннән буыла торган киң тукыма билбау мәгънәсендә дә кулланылган. Моңарда аның чагыштырмача соң функциональ дифференциациясе чагылгандыр, ягъни күлмәк өстеннән билбау буу – икенчел һәм, мөгаен, алынма күренештер [7: 69–70].

Р.Г. Мөхәммәдова белән берлектә язылган икенче бер хезмәтендә С.В. Суслова болай ди: «У богатых татар пояса служили своеобразным предметом щегольства. Их делали из дорогого цветного шелка, украшали золотой или серебряной бахромой. Любопытно, что в значении пояса в свадебном обряде татар изредка фигурирует и полотенце» [7: 69–70]. Шулай итеп, төймәләмичә киелә торган чикмән, тун, җилән, бишмәтише кием өстеннән билбау бууның татарларда күптәнге традицияләре булган. Моны, аерым алганда, Казан татарлары туй йоласында кәләшнең кияү билбавын чишү йоласы булу да раслый. Билбау анда саклагыч функция үтәгән, һәм аны чишү хатынның хокукын ныгыту символын белдергән. Моннан тыш, аның гамәли әһәмияте дә булган. Эшкә киткәндә, крестьян биленә балта кыстырган. Идел-Урал татарларында хәтта «калталы эзәр» дигән термин да булган. Ул чакматаш, шырпы, дары һ. б. тыгып йөртү өчен яссы күн сумкалы һәм тукымадан эшләнгән билбауны аңлата. Йомышлы татарлар билбауга «калта» сумкадан тыш садак, кын белән пычак та такканнар [7: 69–70].

Билбауның булуы татар теленең үзендә үк чагылыш таба: билбау (пута, кушак), каеш, бил, пута, эзәр (кушак, төсле тукымадан эшләнгән пута).

Этнограф профессор Карл Фукс, мәсәлән, татарларның киемнәрен тасвирлаганда ефәк кушакны атый [9: 17]. Аның телдә төрлечә аталуы гына да (билбау, эзәр, кушак) – билбауның булуын раслаучы факт. Күп кенә тикшеренүчеләр билбауның шулай ук костюм комплексының мәҗбүри таләбе булуын ассызыклыйлар.

Нигездә, татар киеменең билбау элементлары өйдә тукылган яки фабрикада җитештерелгән тукымадан булып, кайчакта гына йон җепләрдән бәйләнгән. Иң борынгы билбау үрнәкләре (камәр) позумент, бәрхет, көмеш пластиналардан гаҗәеп бай каптырмалар белән бизәп эшләнгән. Алар барысы да музей коллекцияләрендә борынгы шәһәр мәдәнияте үрнәкләре буларак тәкъдим ителә.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: XIX гасыр ахырларына билбаулар кулланыштан чыгып бетә диярлек. Моңа өстәп, традицион костюм комплексларының үзләрен дә акрынлап Европа киемнәре кысрыклап чыгара башлый.

### Әдәбият

1. *Байбурин А.К.* Пояс (К семиотике вещей) // Из культурного наследия народов Восточной Европы. СПб., 1992. (Сборник Музея антропологии и этнографии; т. 45). Электронная библиотека.

2. *Буткевич Л.М.* История орнамента: учеб. пособие для студ. высш. пед. учеб. заведений, обучающихся по спец. «Изобразительное искусство» / Л.М. Буткевич. М.: Гуманитар, изд. центр ВЛАДОС, 2008. 267 с., 8 с. ил. (Изобразительное искусство).

3. *Гаген-Торн Н.И.* Женская одежда народов Поволжья. (Материалы к этногенезу). Чебоксары, 1960.

4. *Георги И. Г.* Описание всех обитающих в Российском государстве народов, их быта, вероисповедания, обычаев, жилищ, одежды и остальных отличий. Ч. 2. СПб., 1799.

5. Славянские древности: Этнолингвистический словарь: в 5 т. / под общ. ред. Н.И. Толстого; Ин-т славяноведения РАН. М.: Международные отношения, 2009. Т. 4. 656 с.

6. *Суслова С.В.* Татарский костюм: историко-этнологическое исследование. Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. 239 с.: с ил.

7. *Суслова С.В., Мухамедова Р.Г.* Народный костюм татар Поволжья и Урала (середина XX – начало XX вв.). Историко-этнографический атлас татарского народа. Казань, 2000.

8. Толковый словарь живого великорусского языка: в 4 т. / В.И. Даль. М.: РИПОЛ классик, 2006. Т. 2: И–О. 784 с. (Золотая коллекция).

9. *Фукс К.Ф.* Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях / переложение на современный русский язык А.Г. Хорошавиной; науч. ред. и предисл. И.И. Бикеева; Институт экономики, управления и права (г. Казань). Казань: Изд-во «Познание» Ин-та экономики, управления и права, 2013. 108 с.

***Брусков Эдуард Владимирович,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгының экспозиция-күргәзмә бүлеге белгече*

***Брусков Эдуард Владимирович,***
*аспирант Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, специалист экспозиционно-выставочного отдела Елабужского государственного музея-заповедника*

*Locis_555@mail.ru*

УДК 930.271

***В.М. Усманов***

## БӨГЕЛМӘ ТӨБӘГЕНЕҢ ТАШЪЯЗМА ЯДКӘРЛӘРЕ

В статье расматриваются результаты выявления и изучения арабописьменных эпиграфических памятников в татарских населенных пунктах Бугульминского района Республики Татарстан. Особое внимание уделяется эпитафиям, сохранившимся в старых населенных пунктах, таких как Карабаш и Кудашево, которые находились рядом с Екатерининским трактом, где проходили торговые пути из Казани в Оренбург. В дореволюционный период в этих селах имелись каменные мечети и учебные заведения, где служили почтенные представители своего времени, некоторые из которых кроме религиозных наук, владели секретами книжного искусства, арабской каллиграфии, а также, искусством резьбы по камню.

**Ключевые слова:** татарская эпиграфика, каталоги, фотодокументация, известняк, палеография.

The article examines the results of the identification and study of Arabic-written epigraphic monuments in Tatar settlements of the Belebeevsky district of the Republic of Tatarstan. Particular attention is paid to the epitaphs preserved in old settlements such as: Karabash and Kudashevo which were located near the Ekaterininsky tract where trade routes from Kazan to Orenburg passed. In the pre-revolutionary period these villages had stone mosques and educational institutions where venerable representatives of their time served, some of whom, in addition to religious sciences possessed the secrets of book art, Arabic calligraphy, as well as the art of stone carving.

**Keywords:** Tatar epigraphy, catalogs, photo documentation, limestone, paleography.

2024 елның 16–23 сентябрендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре Бөгелмә районы татар авылларына комплекслы фәнни экспедициядә эшләп кайтты. Нәтиҗәдә, әлеге төбәкнең 12 торак пунктында (шул исәптән, Бөгелмә шәһәрендә) зиратлар тикшерелде һәм 200 гә якын эпиграфик истәлек сайлап алынып, фоторәсемгә төшерелде һәм документлаштырылды.

| Саннар тәртибе | Торак пунктлар | Дата (кайчан булу көннәре) | Исәпкә алынган кирилл (һәм латин) графикасындагы эпиграфик һәйкәлләр саны | Исәпкә алынган гарәп язулы эпиграфик һәйкәлләр саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Алга авылы | 19.09.2024 | 35 | 4 |
| 2 | Батыр авылы | 22.09.2024 | 12 | 1 |
| 3 | Бөгелмә шәһәре | 16–23.09.2024 | 15 | 8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Иркен авылы | 20.09.2024 | 10 | 3 |
| 5 | Карабаш шәһәр тибындагы посёлогы (1 нче зират) | 20.09.2024 | 0 | 12 |
| 6 | Карабаш шәһәр тибындагы посёлогы (2 нче зират) | 20.09.2024 | 0 | 11 |
| 7 | Кодаш авылы | 18.09.2024 | 1 | 10 |
| 8 | Райлан авылы | 17.09.2024 | 7 | 0 |
| 9 | Сугышлы авылы | 19.09.2024 | 10 | 3 |
| 10 | Суык Чишмә авылы | 18.09.2024 | 2 | 1 |
| 11 | Таллы-Бүләк авылы | 17.09.2024 | 5 | 0 |
| 12 | Татар Димескәе авылы | 17.09.2024 | 2 | 13 |
| 13 | Якты Ялан авылы | 21.09.2024 | 15 | 0 |
| Барлыгы | | | 114 | 66 |

Бөгелмә районында татар авыллары аз – нибары 11 торак пункт. Аларның да шактые 1927 елда гына барлыкка килгән. Аңлашыла ки, «яшь» авылларда гарәп язулы иске ташъязмалар яисә нәсел тамгалары уелган ташбилгеләр табылмый диярлек, әмма борынгы язма культура традицияләре анда да азмы-күпме яшәвен дәвам итә.



Алга авылы зиратындагы корылма

Әйтик, кабер өстенә бура рәвешендәге корылмалар урнаштыру, яисә каберне кыргый ташлар белән уратып алу, я тамгалы башбата утыртып куюкебек күренешләр белән очраштык. Совет чорында яисә соңгы 30–50 ел дәвамында ясалган эпитафияләрнең күбесе, кирилл хәрефләрен кулланып, татар телендә язылган, ул гына түгел, мәрхүмнәрнең

фотосурәтләре урнаштырылган кабер ташлары да шактый. Әлбәттә, экспедициядә катнашкан эпиграфистның төп максаты бу төбәктәге борынгы (яисә иске) ташъязмаларны табу, өйрәнү һәм фотодокументлаштырудан гыйбарәт. Биредә без Болгар, Дәште Кыпчак, Казан ханлыгы яисә Нугай Урдасы чорындагы борынгы ташъязма истәлекләргә тап булмадык. Иң әүвәлгеләре XIX гасырга карый. Аларның күбесе Карабашта (23), Татар Димескәендә (13), Кодашта (10) табылды. Шунысы әһәмиятле: Бөгелмә төбәгендәге эпитафияләр безгә кадәр дә М. Әхмәтҗанов, Җ. Мөхәммәтшин, А. Борһанов кебек галимнәр тарафыннан күпмедер дәрәҗәдә өйрәнелгән. Шулай ук 2020 елның август-сентябрь айларында Карабаш посёлогының ике зиратындагы гарәп язулы (100 гә якын) кабер ташларын төбәкне өйрәнүче белгеч В. Әхмәтов та тикшергән. Шул эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак, аның «Карабаш таш билгеләре» (Бөгелмә, 2020) дигән китабы да басылып чыккан.



Кодаш авылы зираты.
Нәсел тамгасы уелган таш

Архив чыганакларыннан күренгәнчә, борынгы авыллардан – хәзерге Бөгелмә шәһәре урынында XVIII гасырның икенче яртысында Ишмөхәммәд дип аталган торак пункт булган. Әмма биредә ул чордан бер генә гарәп язулы эпитафик язма да сакланмаган. Элеккеге мөселман һәм христиан зиратлары шәһәр уртасында урнашкан булган. Хәзер бу тирәдә базар кайный.



Кодаш авылы зираты.
Мулла Әхсән бине мулла Зәйнелгабеддин каберенә куелган таш. XIX гасыр азагы – XX гасыр башы



Карабаш посёлогы (2 нче зират).
Хаҗи Исмәгыйль бине мулла Биккол (?–1898) каберенә куелган таш



Карабаш посёлогы (2 нче зират).
Мулла Әхмәдшаһ бине мулла
Биккол (?–1902) каберенә куелган таш



Кодаш авылы зираты.
Мулла Габделвәли бине Рамазан (?–1905)
каберенә куелган таш

Бөгелмә төбәгендәге эпитафияләрне тикшерү нәтиҗәләре шуны күрсәтә: алар шушы тарафтагы кыргый ташлардан ясалган, сакланып калган иске кабер ташларындагы язулар бирéдә яшәгән кятипләр кулы белән башкарылган. Моның өчен яраклы чимал-материал (комташ, я известьташ) елга буйларыннан яисә тау битләрендәге кечкенә карьерлардан чыгарылган. Ә инде бик затлы ташларны эшләгәндә Әлмәт ягындагы «чупай ташы» кулланылган. Мәсәлән, Карабаштагы күркәм ташъязма ядкәрләрдән Габделхәлим бине мулла Бикмөхәммәд, хаҗи Ибраһим бине мулла Биккол (?–1898), хаҗи Исмәгыйль бине мулла Биккол (?–1898, Кодаштагы (мулла Әхсән бине мулла Зәйнелгабеддин) [2: 45] хөрмәтенә куелган һәйкәлләр һәм Бөгелмәдәге Шоңкар тавы (рус. *Сокольская гора*) дип аталган мөселман зиратында бер таш Риза Фәхретдиннең агасы Минһаҗеддин (1843–1931) [1: 150] кулы белән югарыда әйтелгән сыйфатлы таштан ясалган. Гомумән, бу останың дистәләгән эшләре Азнакай, Зәй, Минзәлә, Лениногорск районнары һәм Самара өлкәсендәге кайбер авылларда сакланган. Ул калку (рельефлы) ысул кулланып, нәсех вә сөлес язуына охшаш индивидуаль почерк белән гарәпчә язулар төшергән, шулай ук уйма язулы ташлары да бар.



Карабаш посёлогы (2 нче зират). Бибимәргубә (1812–1872) каберенә куелган таш. *В. Әхмәтов фотосы*

Бу төбәктәге ташъязма ядкәрләрне күздән кичереп һәм аларны башка регионнардагы эпиграфик һәйкәлләр белән (мәсәлән, палеографик үзенчәлекләрен исәпкә алып) чагыштырып, түбәндәге фикергә килдек: беренчедән, бу район биләмәсендә Троицк, Уфа, Чистай, Буа һ. б. кебекерактарак урнашкан мәдәни үзәкләрдән китерелгән кабер ташларын очратмадык; икенчедән, бередә, бөтен тирә-якта мәшһүр мәдрәсәләре белән билгеле, бай тарихлы Тайсуган, Карабаш, Кодаш кебек авыллар һәм аларның үзләренең «таш язгучы» осталары һәм (югарыда әйтеп үтелгәнчә) «чупай ташы» карьеры булган. Әлбәттә, бу фактларның әһәмиятен киметергә ярамый.

Карабаш ташъязмаларының берсе – Әюб хатыны Бибимәргубә (1812–1872) каберенә куелганы – Оренбург өлкәсе Татар Каргалысы авылы кятипләре кулы белән башкарылган.

Ә икенчесе – Гомәр мулла Иманкол угылына нисбәтлесе – Казан осталарының кайбер эшләренә охшаган дип фаразлана.

Шулай итеп, Бөгелмә төбәгендәге ташьязма һәйкәлләр борынгы болгар чорларыннан килгән бай традицияләрнең дәвамы дип кабул ителә. Галимнәр бүгенге көнгә кадәр сакланып калган «таш архив» һәм «таш язу» сәнгате әсәрләрен берәмтекләп өйрәнү эшен туктатмыйлар. Дөрес, яхшылап барланмаган Карабаш китабәләрен (ягъни язулы кабер ташларын), аерым җентекләп тикшерү сорала. Гомумән, татар эпиграфикасына бәйләнешле бу фәнни экспедиция материаллары, булган бушлыкны тулыландырып, тарих битләрендәге ак тапларны ачыкларга ярдәм итәр дигән өметтә калабыз.

**Әдәбият**


1. *Әхмәтҗанов М.И.* Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре. Казан: Мәгариф, 2000. 159 б.: рәс. б-н.

2. *Ризаэддин Фәхреддин.* Асар. 3, 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. 364 б.



***Усманов Венер Мөдәррис улы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

***Усманов Венер Мударисович,***
*научный сотрудник Центра письменного наследия Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*v.m.usmanov@mail.ru*

УДК 9 (46)

*Ә.Т. Сибгатуллина*

# «АҢА ТАТАРЛАР ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЕ КАДЕРЛЕ ИДЕ» (В.А. Гордлевский Каюм Насыйри турында)

Статья посвящена 200-летию со дня рождения выдающегося татарского просветителя Каюма Насыри (1825–1902). Видный советский тюрколог В.А. Гордлевский (1876–1956) в 1923 году в журнале «Восток», издаваемом редакцией «Всемирная литература», опубликовал рецензию на сборник статей на татарском языке, посвященных Каюму Насыри. В своей работе ученый объективно и высоко оценил вклад К. Насыри в формирование литературного татарского языка, сбор и изучение произведений народного творчества, а также его деятельность в области преподавания татарского языка в русских духовных учебных заведениях.

**Ключевые слова:** татарское просветительство, Каюм Насыри, советское востоковедение, В.А. Гордлевский.

The article is dedicated to the 200th anniversary of the birth of the outstanding Tatar educator Kayum Nasyri (1825–1902). In 1923, the prominent Soviet Turkologist V.A. Gordlevsky (1876–1956) published a review in the journal Vostok, issued by the World Literature editorial board, on a collection of articles in the Tatar language devoted to Kayum Nasyri. In his work, the scholar objectively and highly assessed Nasyri's contribution to the development of the literary Tatar language, the collection and study of folk heritage, as well as his efforts in teaching the Tatar language in Russian religious educational institutions.

**Keywords:** Tatar enlightenment, Kayum Nasyri, Soviet Oriental studies, V.A. Gordlevsky.

Атаклы совет тюркологы Владимир Александрович Гордлевский (1876–1956) – Госманлы империясенең мәдәни, тарихи проблемалары белән генә түгел, Касыйм, Казан һәм Кырым татарларының, төрки халыкларның гомуми үсеш үзенчәлекләре белән дә тирәннән шөгыльләнгән киң колачлы галим. Аның бай фәнни мирасы бүгенге көнгә кадәр тулысынча барланып бетмәгән, архивларда әледән-әле төрки халыкларның тарихы, культурасы белән бәйле яңа материаллары табылып тора. В.А. Гордлевскийның Казан татарлары мәдәниятенә караган язмалары да тулы күләмдә киң җәмәгатьчелеккә ирешмәгән дип әйтергә мөмкин (мәсәлән: [3; 5]).

Татар энциклопедист галиме Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулган бу көннәрдә В.А. Гордлевскийның үз вакытында аңа биргән бәясенә аерым тукталып үтү урынлы булыр, чөнки аның алга таба анализланачак язмасы да фәнни әйләнешкә кереп китмәгән һәм күпләргә таныш түгел. Сүз галимнең 1922–1925 елларда Петроградта «Всемирная литература» редакциясендә чыгып килгән «Восток» исемле әдәбият, фән, сәнгать журналының 1923 елгы санында (№ 3)

басылган «Сборник «Памяти Насырова» исемле язмасы турында бара [1]. Рецензия жанрында язылган бу мәкаләдә В.А. Гордлевский журнал укучыларын Казанда 1922 елда чыккан «Каюм Насыйри мәҗмугасы» исемле китап[1] белән таныштыра. Ни кызганыч, татар мәгърифәтчелеге тарихын һәм К. Насыйри мирасын өйрәнү өлкәсендәге беренче фәнни казаныш саналырдай бу җыентык үзе дә бүген киң фәнни кулланышта түгел.

В.А. Гордлевский үз язмасында, Габделкаюм Насыйриның вафатына 20 ел тулу уңаеннан, «Татарстан» һәм «Урал» коммунистик газеталарының идеясе буенча Татарстан Республикасы Халык мәгарифе комиссариатының (Наркомпрос) Академүзәге махсус комиссия төзүен, бу комиссия составына күренекле татар зыялылары С. Атнагулов, Г. Гобәйдуллин, Г. Ибраһимов кебек шәхесләр керүен хәбәр итә. Нәтиҗәдә, комиссия татарлар арасында мәгърифәтчелек хәрәкәтенә нигез салган К. Насыйрига багышланган махсус җыентык әзерли һәм бастырып чыгара. Җыентыкка К. Насыйриның Госман Арсланов кулы белән ясалган портрет эскизы да кертелә. «Редакция, – дип яза В.А. Гордлевский, – җыентыкта урын алган кимчелек һәм хаталарның (татар интеллигенциясе вәкилләренең бер өлеше тарафыннан эшләнгән «саботаж» аркасында) Каюм-бабаның якынлашып килүче 100 еллык юбилеена[2] кадәр төзәтелеп бетәчәгенә ышаныч белдерә» [1: 179]. Сигез мәкаләдән торган бу мәҗмугада Г. Ибраһимов башта К. Насыйри яшәгән чорга киң күзәтү ясый, XIX гасыр уртасында татар халкы бер «ренессанс» дәвере кичерүен билгеләп үтә. В.А. Гордлевский, «татар буржуаз культурасы вәкилләренең (мулла Х. Фәезханов – академик В.В. Вельяминов-Зерновның хезмәттәше, тарихчы Ш. Мәрҗани, К. Насыйри һәм аларның замандашлары) феодаль көнкүреш традицияләрен җимереп, халык өчен яңа юллар ачуын ассызыклый. Г. Рәхим тарафыннан әзерләнгән К. Насыйри биографиясе, В.А. Гордлевский фикеренчә, күләме һәм эчтәлеге ягыннан җыентыкның иң кыйммәтле өлешен тәшкил итә. Калган мәкаләләрдә К. Насыйриның рус әдәбияты белән бәйләнешләре (А. Гаффаров), татар мәгарифе өлкәсенә керткән өлеше (Г. Газиз), халык авыз иҗатын җыюда ирешкән уңышлары (Х. Бәдигый) хакында сүз бара. Җ. Вәлиди үз мәкаләсендә К. Насыйри татар теле өлкәсендә күтәргән проблемаларга туктала, Г. Ибраһимов исә соңгы мәкаләдә К. Насыйриның яңа татар әдәби телен формалаштырудагы ролен ассызыклый.

Җыентыкта К. Насыйриның үз хезмәте дә тәкъдим ителгән, ди галим, һәм «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары» исемле мәкаләсенең, оригиналы югалу сәбәпле, рус теленнән кире татарчага тәрҗемә итеп бастырылуын әйтә. Әлеге хезмәтнең беренче тәрҗемәсе П.П. Масловский тарафыннан башкарылуын һәм Император рус география җәмгыятенең этнография бүлеге органы «Записки»ның

[1] Каюм Насыйри мәҗмугасы: вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан: Татгосиздат, 1922. 160 б.

[2] В.А. Гордлевский Каюм Насыйриның туган елын 1824 дип күрсәтә.

VI томында басылуын хәбәр итә. П.П. Масловскийны[1] автор «Каюм Насыйриның укучысы» дип күрсәтә. К. Насыйриның бу шәхес белән дустанә элемтәсе турында мәгълүматлар бөтенләй юк диярлек.

«Насыйров рус мәдәниятенең әһәмиятен бик яхшы аңлаган һәм яшьтән үк белемгә омтылган», – ди автор, мәдрәсәдә укыганда ук ул яшерен рәвештә рус телен өйрәнә башлавын, 15 ел дәвамында рус рухани мәктәпләрендә татар теле укытуын телгә ала. Шулай ук академик В.В. Радлов (ул вакытта Казан уку-укыту округының инородец мәктәпләре инспекторы) җитәкчелегендә дә эшләп алган, ләкин тиздән алар арасында укыту ысуллары мәсьәләсендә каршылыклар килеп чыккан, дип белдерә. К. Насыйри Казан университетында лекцияләр тыңлаган һәм рус мохитендәге шәхесләр белән танышып, фәнни эшчәнлек күнекмәләрен үзләштергән. В.В. Григорьев югарыда күрсәтелгән «Записки»дагы очеркына кереш сүзендә К. Насыйриның күзәтүләрен фәннилек ягыннан мактап телгә алган, ди. В.А. Гордлевский татар галименең «Ләһҗә-и татари», «Фәвакиһел-җөласа фил-әдәбият», «Кырык вәзир», «Кырык бакча» кебек хезмәтләрен югары бәяли һәм аның эшчәнлеген «югары дәрәҗәдәге мәдәни батырлык» дип атый.

Сүзен йомгаклап, шәркыятьче галим К. Насыйрины «миллиятче иде һәм, әлбәттә, руслаштыру сәясәтенә каршы иде. Аңа татар халкы кадерле иде; аңа татар теле кыйммәтле иде; ул халыкны агарту эшенә үз гомерен багышлады, татар әдәби (милли) телен булдырырга омтылды, татар телен чыгтай архаизмнарыннан һәм «гарәп теле диктатурасыннан» (Г. Ибраһимов гыйбарәсе) азат итте», – дип яза [1: 180]. Шул ук вакытта «Каюм-баба»ның яңа методлы мәктәпләргә каршы булуын искәртә, халык өчен борчылып кайгыртса да, татар халкы аны бозык, динсез, миссионерларга сатылган кеше итеп кабул итте, ди. Әмма, бернигә дә карамый, К. Насыйриның үзе сайлаган юлны дәвам итүен һәм, ул нигез салган татар теленең хәзер матур әдәбиятта уңышлы кулланылуын, Татарстан Республикасы университетында өйрәнелә башлавын билгели.

Вафатының 20 еллыгын искә алып, Казанда «Каюм Насыйри мәҗмугасы»ның басылып чыгуы һәм В.А. Гордлевскийның аны хуплап рецензия язуы 1920 елларның беренче яртысында илдәге сәяси атмосфера белән турыдан-туры бәйле. Бу чорда әле большевистик сәясәт тулы көченә таралып өлгермәгән, репрессияләрнең иң дәһшәтле дулкыны башланмаган иде. Русия империясенең соңгы дәвереннән килгән рус шәркыять белеме үз традицияләрен тулысынча югалтмаган, галимнәрнең күпчелеге элеккеге тикшеренү юнәлешләрен дәвам итү мөмкинлегенә ия иделәр. Әлбәттә, шәркыять белгечләре дә революциядән соңгы яңа сәяси вазгыятькә яраклашырга

[1] Пётр Петрович Масловский (1827–1892) – Казан губернасындагы татарлар арасында эшчәнлек алып барган рус православие миссионеры һәм педагог. Ул галим һәм миссионер Н.И. Ильминский белән тыгыз хезмәттәшлек иткән, Идел-Урал төбәгендәге төрки халыкларны христианлаштыру максатында дини текстларны татар теленә тәрҗемә итүдә катнашкан һәм рухани уку йортларында белем биргән.

мәҗбүр булсалар да, мөстәкыйль фикер йөртү мөмкинлеге ул вакытта әле дәүләт тарафыннан тулысынча тыелмаган һәм фәнни тикшеренүләргә карата кырыс цензура урнашмаган иде. Югыйсә, 1930 елларда халәт тамырдан үзгәреп, шәркыять белгечләренең хезмәтләре дә сәяси күзлектән бәяләнә башлагач, К. Насыйри кебек татар «националистларын» мактап язган авторлар, һичшиксез, «вак буржуаз миллиятчелекне пропагандалауда» гаепләүләргә дучар булыр иде.

Билгеле булганча, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында күренекле шәркыятьчеләр Урта Азия, Кырым, Кавказ, Идел-Урал, Себер төбәкләрендә яшәгән рус булмаган халыкларның тормышын күпкырлы өйрәнү эшенә аерым игътибар бирделәр. Безнең фикеребезчә, моны патша империясенең «инородец»ларны руслаштыру, христианлаштыру сәясәте белән беррәттән, тагын 1880 елларда рус шәркыять белемендә барлыкка килгән яңа фәнни юнәлеш белән аңлатып була. Санкт-Петербург университеты профессоры Н.А. Розен (1849–1908) башлап җибәргән бу юнәлеш Россия империясенең «үз Көнчыгышын» – ислам һәм будда динендәге халыкларының тарихын, мәдәниятен, этнографиясен өйрәнүне максат итеп куя. Ул Россия шәркыять фәнен «милли нигезгә күчерергә», ягъни тикшеренүләрнең үзәгенә Россиянең «үз Көнчыгышын» куярга һәм җирле халыклар («туземец») арасыннан чыккан гыйлем ияләре, зыялылар белән якын хезмәттәшлек итәргә чакыра. Нәтиҗәдә, аның карашлары XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында рус шәркыять белеме үсешенә зур йогынты ясый, аны халыкара дәрәҗәгә, ягъни Европа шәркыять белеме белән бер баскычка күтәрә. «Розен мәктәбе» вәкилләре – В.В. Бартольд, С.Ф. Ольденбург, Н.Я. Марр, Ф.И. Щербатской кебек галимнәр чит илләр белән беррәттән үз илебездәге шәркый җәмгыятьләрнең үсеш законнарын, сәяси, икътисади, мәдәни мөнәсәбәтләрен объектив тикшереп анализлады [6].

1922–1925 елларда чыгып килгән «Восток» журналы[1] да әлеге фәнни юнәлешкә хезмәт иткән басмаларның берсе иде. Шуны да искәртик, В.А. Гордлевский «Восток» журналында бер К. Насыйри турында гына язып калмый, Г. Ибраһимов [2], Г. Тукай [4], Гыйффәт туташларның [4] китапларына да объектив эчтәлекле, тыныч рухлы рецензияләр бастыра. 1930 елларда бу төр журналлар һәм бу тип язмалар инде чыкмый, совет хакимиятенең этник-мәдәни сәясәте

[1] Журнал Петроградның алдынгы шәркыять галимнәре – Азия музее хезмәткәрләре (В.М. Алексеев, Б.Я. Владимирцев, И.Ю. Крачковский, С.Ф. Ольденбург) тарафыннан, «Всемирная литература» нәшрияты мөдире А.Н. Тихонов катнашында оештырыла. Һәм елга бер тапкыр чыга. Барлыгы биш саны дөнья күргән. Журналның төп бурычын С.Ф. Ольденбург беренче китапка язган кереш сүзендә болай дип билгели: «Без Көнчыгышны аңлы рус җәмәгатьчелегенә якынайтырга телибез, чөнки борынгы Көнчыгыш... безгә мәңгелек үрнәкләр калдырды, аларның әһәмияте кеше өчен беркайчан да югалмаячак һәм кабатланмаячак. Шул ук вакытта ... яңа Көнчыгыш та зур мөмкинлекләргә ия, анда борынгы мирас югалмаган, ләкин ул аны яңа образларга әверелдерергә, яңа казанышлар тудырырга тиеш. Без ышанабыз: Россиягә дә, Көнбатышка да борынгы һәм яңа Көнчыгышны белү кирәк, ансыз тормышыбыз ярлырак һәм берьяклырак булыр».

катгыйлаша барган саен, Н.А. Розен нигез салган фәнни агымның дә ирекле үсешенә киртәләр куела.

Шул күзлектән чыгып караганда, «Каюм Насыйри мәҗмугасы»ның басылып чыгуы һәм аңа күренекле тюркологның уңай бәя бирүе – әлеге чор өчен шактый мөһим вакыйга. Ул татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенең казанышларын тану гына түгел, ә совет шәркыять белемендә үз милли мирасыбызга объектив караш яшәп килгән чорның соңгы күренешләренең берсе дә булып тора. Төрки халыкларның мәдәни үсеше мәсьәләләрен өйрәнгән галим буларак, В.А. Гордлевский рус булмаган халыклар арасыннан чыккан К. Насыйри кебек зыялыларның үз телләрен, фольклорын, этнографиясен системалы өйрәнү эшен югары бәяләгән, аларның хезмәтләрен мөһим фәнни чыганак итеп караган һәм аларның гомумтөрки мәдәни мирас кысаларындагы әһәмиятен билгеләп үткән.

**Әдәбият**

1. *Гордлевский Вл.* [Рец.:] Сборник «Памяти Насырова» // Восток. Журнал литературы, науки и искусства. Книга третья. М., Пб.: Всемирная литература, 1923. С. 179–180.

2. *Гордлевский Вл.* [Рец.:] Г. Ибрагимов. «Из истории движения татарских студентов» // Восток. Журнал литературы, науки и искусства. Книга третья. М.; Пб.: Всемирная литература, 1923. С. 180–181.

3. *Гордлевский В.А.* Гадания татарок о женихе. (Из этнографических материалов, собранных в Уфе) // Ко дню 80-тилетия академика Василия Васильевича Радлова (1837–1917 гг.): статьи. [Вып. 2]. Л.: Изд-во АН СССР, 1917–1925. (Сборник Музея антропологии и этнографии при Академии наук СССР; т. 5, вып. 2). С. 709–716.

4. *Гордлевский В.* [Рец.:] Абдулла Тукаев. Узюльган Умид; Коза и баран…; Захида Иффат. Зора Юлдуз // Восток. Журнал литературы, науки и искусства. Книга пятая. М.; Пб.: Всемирная литература, 1925. С. 268.

5. *Гордлевский В.А.* Элементы культуры у касимовских татар. Труды общества изучения Рязанского края, 1927 г. Т. 10. С. 1–35.

6. *Тольц В.* «Собственный Восток России»: Политика идентичности и востоковедение в позднеимперский и раннесоветский период / пер. с англ. М.: Новое литературное обозрение, 2013. 336 с.

***Сибгатуллина Әлфинә Таһир кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Сибгатуллина Альфина Тагировна,***
*доктор филологических наук, профессор,*
*ведущий научный сотрудник Института востоковедения*
*Российской академии наук*

*alfina2003@yandex.ru*

УДК 9 (46)

***Ф.Г. Миңнеханов***

# КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ ХАКЫНДА ГАЛИ РӘХИМ

Статья посвящена творчеству выдающегося представителя татарского ренессанса конца XIX – начала XX в.: ученого, писателя, просветителя Каюма Насыйри. На основе анализа биографических работ, написанных Г. Рахимом к 100-летию со дня рождения Каюма Насыри в 1922–1926 гг., исследуется жизненный и творческий путь основоположника татарского литературного языка. В статье дан авторский взгляд на вопросы «Кем был Каюм Насыри»? «Является ли он просветителем, ученым-энциклопедистом или популяризатором научных знаний?».

**Ключевые слова:** Каюм Насыри, Гали Рахим, биография, просветитель, литературовед, просвещение, наука, календарь, татарский язык, татарская литература.

The article is devoted to the analysis of the work of outstanding representatives of the Tatar Renaissance of the late 19th – early 20th centuries: the scientist, writer, educator Kayum Nasyri and his first biographer Gali Rahim. Based on the analysis of biographical works written by G. Rahim on the occasion of the 100th anniversary of the birth of Kayum Nasyri in 1922–1926, the author examines the life and creative path of the founder of the Tatar literary language. The article gives the author's view on the questions: "Who was Kayum Nasyri?", "Is he an educator, an encyclopedic scientist, or a popularizer of scientific knowledge?".

**Keywords:** Kayum Nasyri, Gali Rahim, biography, educator, literary critic, enlightenment, science, calendar, the Tatar language, Tatar literature.

Күренекле галим, педагог, язучы, татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле Каюм Насыйриның тууына 2025 елның 14 (2) февралендә 200 ел булды.

К. Насыйри – XIX гасырның икенче яртысы татар рухи-мәдәни хәяты, иҗтимагый фикере тарихында аерым бер урын алган, тирән эз калдырган шәхес.

Әдәбиятта бу чор «уяну чоры», «яңарыш чоры», «татар ренессансы» дигән исем белән атап йөртелә. Бу елларда К. Насыйри да нәтиҗәле эшли, тел, әдәбият, фольклор, педагогика, география, математика һәм башка фәннәр буенча бүгенге көндә рухи мирасыбызның, хәзинәбезнең бәһаләп бетергесез җәүһәрләре булган дүрт дистәдән артык әсәр яза, 24 календарь төзи. Басылган китаплары 4 мең, календарьлары 1200 дән артык – барысы 5200 биткә җыела. Китап һәм календарьларының басма саны 100 гә тула, күләме 350 басма табактан арта [5]. Әдипнең 40 тан артык басмасы дөнья күрә, аларның кайберләре берничә тапкыр нәшер ителә, шулай да берничә дистә кулъязма

әсәре басылмыйча кала. Аның әдәби һәм фәнни мирасы – милләткә фидакярләрчә хезмәт итүнең бөек үрнәге. Татарны татар итеп танытуда, аның милли үзаңын, рухи хәтерен үстерүдә К. Насыйриның өлеше искиткеч зур.

К. Насыйриның тормышы, иҗаты турында күпсанлы мәкалә, истәлекләр, төрле характердагы документлар һ. б. бастырып чыгарылды, шул исәптән әдипкә багышланган әдәби-тарихи һәм документаль җыентык дөнья күрде [2].

К. Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан Татарстан Фәннәр академиясе М.Х. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты да әдипкә багышланган ике фундаменталь хезмәт – «Каюм Насыйри: биобиблиографик күрсәткеч» (180 бит) һәм «Каюм Насыйри: иллюстрацияле персональ энциклопедия» (500 бит) – әзерләп бастыруны үз өстенә алды. Аларда әдип бөек мәгърифәтче, энциклопедист галим, халыкка фәнни белем таратучы, популярлаштыручы, тарихчы буларак югары бәяләнә. Тел галиме, тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы, педагог, җәмәгать эшлеклесе Җ. Вәлиди «Каюм Насыйри иң элек безнең татарлыгыбызны аңлады һәм аны үзенең әсәрләре аша башкаларга да аңлатмакчы булды», дип билгели [3]. К. Насыйриның тууына 100 ел тулу уңаеннан язылган мәкаләләрендә (1925 ел) татар халкының күренекле әдибе Г. Ибраһимов аны «татар халкына Европага юл ячучы, беренче сукмакны салучы «бөек реформатор», дип бәяли [7: 71–72].

К. Насыйриның тормыш юлын һәм эшчәнлеген фәнни өйрәнү эшен башлап җибәрүчеләрнең берсе, аның беренче биографы дип без хаклы рәвештә талантлы галим, фольклорчы, әдәбият тарихчысы һәм тәнкыйтьче, археограф һәм язучы, шагыйрь Гали Рәхимне (Мөхәммәтгали Мөхәммәтшакир улы Габдерәхимов) атый алабыз.

Татар ренессансы формалашуга зур өлеш керткән, әмма үз вакытында эшчәнлеге һәм мирасына тиешле бәя бирелмәгән шәхесләребездән булган Гали Рәхим 1892 елның 4 ноябрендә Казанда сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне этисе яллаган махсус укытучылардан һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә ала, бер үк вакытта рус теле дәресләренә йөри. Соңыннан Казанның коммерция мәктәбендә укый. Коммерция училищесында уку дәверендә Гали Рәхим үзлегеннән һәм хәлфәдән гарәп, фарсы һәм төрек телләрен өйрәнә [1: 33].

Октябрь революциясеннән соң хәрби-политик курсларда, Казандагы Көнчыгыш Академиясендә, соңыннан 1920 елдан 1930 елга кадәр Көнчыгыш педагогика институтында төрки-татар тарихын һәм татар фольклорын укыта һ. б. [10: 4–6]. Болардан тыш күпкырлы фәнни һәм педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнә, күп кенә гыйльми җәмгыятьләрдә хезмәт куя. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә, Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыятендә, ТАССР Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми Үзәктә (Академцентр) әгъза булып тора. Казан

университетындагы төрки-татар һәм Шәрык кульязмаларын өйрәнү һәм эшкәртү белән шөгыльләнә. Әдәбият, сәнгать һәм тел белемнәре, татар эпиграфикасы һәм археографиясе буенча күпсанлы фәнни тикшеренүләр үткәрә. 1920–1930 елларда Гали Рәхим илледән артык фәнни хезмәт бастырып чыгара [4: 35]. Рус һәм татар телләрендә язылган бу хезмәтләрдә төрки әдәбият, яңа татар әдәбияты, тәнкыйть, фольклор, татар сәнгате турында кыйммәтле мәгълүматләр бар.

Аерым шәхесләрнең торгызылган биографияләрен Г. Рәхим мирасының иң әһәмиятле, кыйммәтле бер өлеше буларак күрсәтә алабыз. М. Мәһдиев фикеренчә, «бу яктан караганда ул тарихчы Риза Фәхреддиновның дәвамчысы булып тора. Татар язучыларының, культура әһелләренең тормыш юлын, аерым чыганакларны юллауда Г. Рәхим ару-талу белмәс галим иде» [4: 56]. Чыннан да, үзенең фәнни эшчәнлегендә Гали Рәхим фән һәм сәнгатъ әһелләренең тормыш юлларын ачыклау, шуларга караган чыганакларны барлауга зур игътибар бирә. Галим күрсәтеп калдырган чыганаклар буенча без бүгенге көндә XIX йөз әдбиятын тулырак, киңрәк беләбез. Аның бу өлкәдәге эзләнүләренең иң югары ноктасы 1920 елларга туры килә. Ул Каюм Насыйри, Мөхетдин Корбангалиев, Галиәсгар Камалларның тулы тәрҗемәи хәлләрен башлап язучылардан була. Габдрахман Ильяси, Әхмәт Уразаев-Кормашиның нәсел дәвамчыларын табып, алар хакында материал туплый һәм татар әдәбияты тарихына исемнәрен кертә [10: 6].

Билгеле булганча, Каюм Насыйриның беренче тулы биографиясен язучы да Гали Рәхим була. Тәрҗемәи хәлен бәян итүдән тыш, ул энциклопедист галимнең кульязмаларын барлый һәм 1924 елда «Безнең юл» журналының 4 нче санында аларга багышланган язма чыгара. М. Мәһдиев фикеренчә, «әдәбиятчыларыбыз моңа кадәр күпме генә дәшми килмәсеннәр, К. Насыйри мирасын бүгенге хәлдә күрүебез белән без Г. Рәхимгә бурычлы» [4: 56].

«Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле» Гали Рәхим тарафыннан 1922 елда языла башлый. Әлеге фәнни хезмәтнең эчтәлеге генә түгел, язылу тарихы да игътибарга лаек. К. Насыйриның вафатына 20 ел тулу уңае белән Татарстан Мәгариф халык комиссаиаты каршындагы Гыйльми Үзәк 1922 елның 2 сентябрен әдипне искә алу көне буларак билгеләп узарга карар кыла. Аны оештыру өчен рәисе – Г. Ибраһимов, әгъзалары С. Атнагулов, Г. Гобәйдуллин булган өч кешелек комиссия төзелә һәм галим хакында мәҗмуга (җыентык) әзерләү чарасына керешелә. К. Насыйрины белүчеләргә мөрәҗәгать ителә, кулларында галимнең тормышы һәм эшчәнлегенә караган материаллар – төрле язмалар, хатирәләр, хатлар, китаплар, рәсемнәр һәм башка әйберләр булган кешеләргә элемтә өчен адрес күрсәтелә. Әдипнең биографиясен язу, әйтеп үтелгәнчә, Гали Рәхимгә йөкләнә. Нәтиҗәдә, мәҗмуга төзелеп, шул ук елда нәшер ителә [6: 1–2].

Гали Рәхим бу чарага әзерлекнең барлык этапларында да актив катнаша. Ул катлаулы тормыш юлы узган, күпкырлы эшчәнлек алып

барган әдип, мәгърифәтче, мөгаллим, энциклопедист галимнең тулы, һәрьяктан тикшерелеп расланган тәрҗемәи хәлен кыска гына вакыт эчендә (1–2 ай) язуның мөмкин эш булмавын яхшы аңлый. Эшнең ничек башлануы һәм барышы турында Гали Рәхим үзенең «Насыйриның тәрҗемәи хәленә гыйлавә»сендә[1] болай яза: «Мәгълүм ки, шушы елның 2 сентябрендә карт язучыбыз Каюм Насыйриның үлүенә 20 ел тулу мөнәсәбәте белән Казанда аңа багышланган мәҗмуга нәшер ителде. Бу эшкә керешүчеләрнең башына бу фикер бик соң гына килеп төште. Әсәр язу комиссиясендә әйтелгәнчә, бу комиссия бары 1922 елның маенда гына сайланып эшкә кереште. Комиссия карарында бу җаваплы эш – К. Насыйриның тәрҗемәи хәлен язу минем өстемә йөкләнде. Бу эшне башкарыр өчен миңа бер ай кадәр форсат бирелгән иде» [9: 81–82].

Комиссия шартлары белән ризасызлыгын белдереп, Г. Рәхим үзенең фикерен түбәндәгечә дәлилли: «Гадәттә исә мондый җаваплы бер хезмәт берничә ел вакыт сорый. Иркенләп, ашыкмыйча эшләгәндә генә, ул тиешенчә мөкәммәл булып чыга ала. Әмма Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле кузгатылмаган бер җир төсле булып, моңа кадәр язылганы булмау гына түгел, хәтта аңар кирәкле материал да кирәгенчә җыелганы юк иде. Менә бер ай, ай ярым вакыт эчендә таркау материалларны җыярга, җыелмаганын әллә кайлардан эзләп, казып чыгарырга кирәк булды. Минем хосусый фикеремчә, мәҗмуга чыгару мәсьәләсен хәзергә калдырып торып, ел ярымнан (1925 елның февралендә) булачак Насыйриның тууына йөз ел тулу көненә туры китереп чыгару мәслихәтрәк булган булыр иде (мәҗмуга язылган вакытта әдипнең туган елы 1824 елдан исәпләнгән. – *Ф.Г.*). Язучылар да иркенләп әзерләнә алырлар, икътисади әхвәл төзәлә төшү сәбәпле, мәҗмуганы тагы да тулырак, тагы да мөкәммәлрәк итеп чыгарып булыр иде. Ләкин эш эшләнде, тәрҗемәи хәл язылды, мәҗмуга нәшер ителде» [9: 82]. Галимнең үзенә тапшырылган эшкә зур җитдилек белән каравы аның «Насыйриның тәрҗемәи хәленә гыйлавә»сендә дә ачык күренә. Гыйлавәдә Гали Рәхим моңарчы тәрҗемәи хәл язу кебек җаваплы эшкә алынганы булмавын ассызыклый һәм Каюм Насыйри биографиясенең шактый өлешенең комиссия рәисе Г. Ибраһимов тарафыннан басмадан төшереп калдырылуына ризасызлыгын белдерә: «Минем ризалыгымнан башка, яки ярым ризалыгым белән тәхрир һәйәтенең[2] рәисе Галимҗан иптәш Ибраһимов тәрҗемәи хәлнең байтак урыннарын төшереп калдырды. Кайбер урыннар басылган вакытта гына сызылганга, мәгънә ачык аңлашылмастай булып калган җирләр бар» [9: 82]. Алга таба, Гали Рәхим «төшереп калдырган әйберләрнең әһәмиятлерәкләрен өстәп, аңлашылмаслык урыннарга изах[3]» биреп үтә [9: 81–88]. Гыйләвәнең дүртенче өлешендә генә галим егермедән артык аңлатма, төзәтмә тәкъдим итә.

[1] Гыйлавә – өстәмә, кушымта.

[2] Тәхрир һәйәте – редколлегия.

[3] Изах – аңлатма.

Алар К. Насыйриның холкындагы һәм тормыш рәвешендәге башкалар өчен аңлашылып бетмәгән кайбер хәл-сыйфатларга, тәрҗемәи хәленә ачыклык кертәләр. Аларның кайберләрен санап үтик: әдип кулъязмаларының эчтәлеге, сакланылышы; төрле кешеләрдән алынган шифаһи[1] мәгълүмат, Каюм Насыйриның «учительлекне» ташлавының сәбәбе; «Насыйриның ашау-эчү, хатыннар белән мөнәсәбәте турында төшеп калган сүзләр»; «Насыйриның әсәрләрен санаган җәдвәлдә[2] киткән хаталарны төзәтү» һ. б.) [9: 83–85].

1923 елда «Безнең юл» журналында галимнең К. Насыйрига багышланган мәкаләләре һәм әдипнең ул әзерләп тапшырган кулъязмалары тупланып, «Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле» дигән исем белән дөнья күрә. 1925 елның 15 февралендә Татар дәүләт театрында әдипнең 100 еллыгына багышланган тантаналы утырышта Гали Рәхим Каюм Насыйриның фәнни һәм мәгърифәтчелек эшчәнлегенә багышланган доклад белән чыгыш ясый. Тантаналы утырыш материаллары Гали Рәхим редакциясендә «Каюм Насыйриның басылмаган әсәрләре һәм тантаналы утырыш материаллары» дигән гомуми исем белән Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыятенең «Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте хәбәрчесе» басмасында (1925 ел, 1–2 саннар) нәшер ителә. 1926 елда Гали Рәхим кулына К. Насыйриның фәнни әйләнештә булмаган кулъязмалары килеп керә һәм шул материаллар нигезендә ул «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм йөзьеллык бәйрәме материаллары» дигән китап чыгара [7].

Тупланмада К. Насыйриның тормышы һәм иҗат юлына багышланган төп өлеш – «Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле» – дүрт бүлектән тора [8: 42]. Беренче бүлектә Гали Рәхим үзе бөртекләп җыйган материалларга, әдипнең кулъязмаларына, аның замандашларының истәлекләренә, матбугатта басылган мәкаләләргә һ. б. таянып, К. Насыйриның рәсми тәрҗемәи хәлен, аның тормышында булган үзгәрешләр һәм әһәмиятле вакыйгалар турында яза. Икенче бүлектә сүз К. Насыйриның «мактаулы сыйфатлары: төсе, кыяфәте, холкы, табигате, гадәтләре һәм хосусый хәяты» турында бара. Өченче бүлек аның иҗтимагый хәле, «ягъни халыкның, кешеләрнең аңа һәм аның кешеләргә мөнәсәбәте»нә багышлана. Дүртенче бүлектә әдипнең әдәби мирасына, шул исәптән календарьларына анализ бирелә, әсәрләренең хронологиясе күрсәтелә. Тәрҗемәи хәлнең бу өлешендә Гали Рәхим К. Насыйриның «иң фәгалиятле һәм җимешле дәверенә (1880–1890 еллар)» аерым туктала һәм аңа зур бәя бирә. Галимнең тикшеренүләре буенча, әлеге елларда К. Насыйри «ифрат күп эшли, әсәрләренең иң күп кыйсемен шушы чор эчендә яза. Бу дәвердә бик еш, бер ел эчендә (календарьларны да кушып) 5–6 китап басыла...» [8: 73]. Әдипнең шушы елларда бастырылган әсәрләре һәм хезмәтләренең Гали Рәхим тарафыннан ачыкланган һәм гомуми санын

[1] Шифаһи – телдән сөйләнгән.

[2] Җәдвәл – исемлек.

күрсәткән мәгълүматлар ул заманда галимнәр, язучылар һәм киң җәмәгатьчелек өчен зур яңалык була. Фикерен йомгаклап, галим болай ди: «Насыйри үз гомерендә бик күп язган, бик «җимешле» язучылардан. Аның язган әсәрләренең басылганнарының гына бит хисабы, календарьларын исәпләмәгәндә, 4000 биттән артыграк. Календарьлары үзе 1228 бит җыела» [8: 78].

Гали Рәхим әлеге язмасында әле бүген дә актуаль «Кем ул Каюм Насыйри?» дигән сорауга җавап бирергә омтыла. Ул, беренчеләрдән булып, К. Насыйрины «энциклопедист» дип атый. Үз фикерен әдип болай дәлилли: «Насыйри нинди язучы булган дигән сөальгә, ул бер энциклопедист булган дип җавап бирергә туры килә. Аның әсәрләре арасында дини китаплардан башлап, халис[1] әдәби китапларына хәтле бар. Шуларның ике арасына әнвагъ[2] гамәли һәм нәзари фән вә һәм белемнәргә даир[3] әсәрләр керә. Бу ягы белән Каюм Насыйри безгә чыгтай әдәбиятыннан Мир Галишер Нәваи яки соңгы зур язучылардан Әхмәд Мидхәт шикелле язучыларны хәтерләтә. Нәваи үз гомерендә шулай ук һәртөрле бабтан утызлап китап язган булса, Насыйриның язган китаплары кырыкка тула» [8: 78]. (Бүгенге көнгә Каюм Насыйриның аерым китап булып басылып чыккан дүрт дистәдән артык әсәр һәм хезмәте мәгълүм, ә мәкаләләре берничә дистә тәшкил итә. – *Ф.М.)*

Гали Рәхим тарафыннан К. Насыйриның биографиясен, аның әдәби һәм фәнни иҗатын барлау, тупламаны системалаштырып аерым басма – мәҗмуга рәвешендә тәкъдим итү әдипнең үзенчәлекле тормышы, күпкырлы эшчәнлеге белән танышу, шул эшчәнлеккә бәя бирү өчен зур мөмкинлекләр ача. Әлеге басма К. Насыйри шәхесен һәм иҗатын өйрәнү-ачыклауга хәлиткеч этәргеч була, дип әйтү дә дөрес булыр. Бу биографик тикшеренү нигезендә соңгы йөз ел дәвамында дистәләрчә китап, монографияләр, фәнни җыентыклар төзелде, диссертацияләр якланды. Әле бүген дә, әдипнең тууына 200 ел тулуны билгеләп үткән көннәрдә, әлеге җыентыкның һәр нигезләмәсе дистәләрчә яңа эзләнүләргә һәм табышларга башлангыч бирә ала. Гали Рәхим тарафыннан бөек мәгърифәтче, әдип, энциклопедист галимгә бәя биреп әйтелгән: «Каюм Насыйри татар халкын чын күңелдән сөюче, аны кайгыртучы, аның алга китүен теләүче һәм шул юлга хезмәт итүче кеше булган» [8: 65], дигән фикер, милләтебез яшәгәндә, гомерен аның рухи саулыгын кайгыртуга багышлаган улының онытылмаячагына, олыланачагына ышаныч бирә.

**Әдәбият**

1. *Губайдуллин С.* О моем дяде Гали Рахиме // Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык. Казан: Җыен, 2008. Б. 23–32.

[1] Халис – саф.
[2] Әнвагъ – төрле.
[3] Даир – караган.

2. Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль җыентык / төз. Р.Ф. Исламов. Казан: Җыен, 2017. Б. 812–816.

3. «Каюм Насыйри эзләре буенча» / [Электрон ресурс]. https://vk.com/wall-174654620_2552 (мөрәҗәгать итү көне: 27.01.2025).

4. *Мәһдиев М.* Ерактан яңгыраган аваз // Гали Рәхим: тарихи документаль, әдәби һәм биографик җыентык. Казан: Җыен, 2008. Б. 33–62.

5. Мәшһүр татарлар. Каюм Насыйри / [Электрон ресурс] https://sabantuyjournal.ru/news/iat/kayum-nasyyri (мөрәҗәгать итү көне: 27.01.2925).

6. Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан: 6-я Гос. тип., 1922. 162 б.

7. *Рәхим Г.* Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм йөз еллык материаллары. Мәҗмуга / Г. Рәхим карамагында. Казан: Татгиз, 1926. 135 б.

8. *Рәхим Г.* Насыйриның тәрҗемәи хәле // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар – Духовное наследие: поиски и открытия / редкол.: И.Г. Гомәров, З.З. Рәмиев, А.М. Ахунов; төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова. Казан: ТӘһСИ, 2020. 9 нчы чыг. Б. 42–81.

9. *Рәхим Г.* Насыйриның тәрҗемәи хәленә гыйлавә // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия / редкол.: И.Г. Гомәров, З.З. Рәмиев, А.М. Ахунов; төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова. Казан: ТӘһСИ, 2020. 9 нчы чыг. Б. 81–88.

10. Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие и открытия / редкол.: И.Г. Гомәров, З.З. Рәмиев, А.М. Ахунов; төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова. Казан: ТӘһСИ, 2020. 9 нчы чыг. 304 б.

***Миңнеханов Фидаил Гыймран улы,***
*тарих фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Энциклопедистика үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Миниханов Фидаиль Гимранович,***
*кандидат исторических наук, доцент, старший научный сотрудник Центра энциклопедистики Института татарской энциклопедии и регионоведения имени М. Хасанова АН РТ*

*fidail1956@mail.ru*

УДК

*Э.Х. Кадирова*

# ДИАЛЕКТОЛОГ ГАЛИМӘ
## (Зидә Садыйкова тууына 90 ел булу уңаеннан)

Зиде Рашидовне Садыковой (10.04.35–3.05.2015), посвятившей сорок шесть лет своей жизни науке в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова и оставившей после себя многочисленные научные труды в области татарского языкознания, 10 апреля 2025 года исполнилось бы 90 лет. В данной статье анализируются результаты научных трудов ученого, относящихся к области диалектологии, лексикологии татарского языка.
**Ключевые слова:** Зида Рашидовна Садыкова, татарский язык, диалектология, юбилей.

Zida Rashidovna Sadykova (10.04.35–3.05.2015), who devoted forty-six years of her life to searching for the pearls of science at the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov and left behind numerous articles and monographs in the field of Tatar linguistics, would have turned 90 on April 10, 2025. This article analyzes the results of the scientist’s works related to the field of dialectology and lexicology of the Tatar language.
**Keywords:** Zida Rashidovna Sadykova, Tatar language, dialectology, anniversary.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тел белеме бүлегендә 46 ел хезмәт куйган филология фәннәре кандидаты, хезмәт ветераны Зидә Рәшит кызы Садыйковага бу елның 10 апрелендә 90 яшь тулган булыр иде.

Зидә Рәшит кызы 1935 елның 10 апрелендә Башкортстанның Салават районы Нәсибаш авылында дөньяга килә һәм урта белемне үз авылында ала. Зидә мәктәптә укыганда ук татар һәм рус телләрен кызыксынып өйрәнә. Яраткан укытучысы Мәсгудә Сөләйманова да анда татар теленә, мәдәниятенә ихтирам тәрбияли. Абыйсы Рашат Гайнанов, сугыштан яраланып кайтып бераз тернәкләнгәч, Казан дәүләт университетының татар бүлегенә укырга керә (сүз Г. Тукай, Г. Ибраһимовларның томлыкларын әзерләгән, Г. Гобәйдуллин, Н. Думавиларның иҗатын текстологик өйрәнгән атаклы татар әдәбияты галиме Рашат Рәшит улы Гайнанов турында бара). Шул вакытта ул авылдагы туганнарына татарча кызыклы китаплар җибәреп тора, сеңелләре – Зидә, Лена (Г. Исхакый әсәрләрен милләтебезгә кайтаруда зур хезмәт куйган галимә, текстолог, Гаяз Исхакый премиясе лауреаты Лена Гайнанова), Флоридага Казан турында сөйли. Алар да, Казанга килеп, югары белем алу хакында хыялланалар.

Зидә Рәшит кызы 1954 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына татар теле һәм әдәбияты бүлегенә

укырга керә. Ул Гаяз Ишмөхәммәтов, Якуп Агишев, Хатыйп Госман, Диләрә Тумашева һ. б. танылган галимнәрдән белем ала. Зидә Гайнанова татар диалектологиясе дәресләрендә зур галим Латыйф Җәләйнең мавыктыргыч лекцияләрен тыңлый. Аның тәкъдиме белән, ул җәйге каникуллар вакытында авылдашларыннан туган ягының җырларын, әкиятләрен язып ала, үз ягы гореф-гадәтләренә караган материалларны туплый, гомумән, туган төбәгенең тарихы, сөйләме белән кызыксына. Студент кызның кызыксынулары бушка китми. Өлгер һәм саф күңелле, эшкә иҗтиһатлы кызны Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләре дә абайлап алалар, җәй көне диалектологик экспедицияләрдә катнашырга чакыралар. Соңрак Латыйф ага аңа «Башкортстанның Нәсибаш төбәге татарлары сөйләше» дигән темага диплом эше язарга тәкъдим итә. Зидә Садыкова җитәкчесе турында аңа атап язган истәлекләрендә җылы фикерләрен җиткерә: «Латыйф ага Җәләй минем язмышым хәл ителүгә дә сәбәпче булды. Лаеш районына укытучы булып китәргә билгеләнгәч, тел секторына чакырып, миңа диалектологик экспедициягә чыгарга һәм, теләсәм, эшкә калырга мөмкинлек булуын әйттеләр. Мин шатланып риза булдым» [6: 145]. Шулай итеп, Зидә Рәшит кызы 1960 елның җәендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тел секторына өлкән лаборант итеп эшкә алына.

60 нчы еллар башында институтның тел секторы диалектологлары үз эшчәнлекләрендә зур планнар коралар: төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып Диалектологик атлас төзү эшенә керешәләр. Әлбәттә, яшь белгеч Зидә Рәшит кызы да гаять катлаулы эшкә тотына: секторда тупланган диалекталь лексиканы фәнни эшкәртүдә катнаша, картотека төзи, җәен башка диалектологлар белән экспедицияләрдә йөри. Шулай итеп, ул бай тәҗрибә туплый. Тирәнтен уйлап эш итә, сүзләрнең нечкә мәгънәләрен тоя белә торган Зидә ханым Г.К. Якупова, Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова кебек тәҗрибәле өлкән галимнәр белән бергә «Татар теленең диалектологик сүзлеге»н (Казан, 1969, 643 б.) төзүдә автордаш буларак катнаша.

Зидә Садыйковага тел секторының мәртәбәле галимәсе Н.Б. Борһанова җитәкчелегендә «Оренбург татарлары сөйләше» дигән кандидатлык диссертациясе темасы бирелә. Галимә моңа кадәр беркем тарафыннан да өйрәнелмәгән җитмешләп авылны монографик планда да, Атлас төзү өчен лингвистик география алымы белән дә җентекләп өйрәнә. 1985 елда аның «Говоры оренбургских татар» [10] дигән китабы басылып чыга. Хезмәт җәмәгатьчелек кулына кереп әйбәт бәяләмә алгач, автор 1986 елда шул ук темага кандидатлык диссертациясен яклый. Аны ул аспирантура курсы үтмичә, төп эшеннән аерылмыйча яза. Автор, Мәскәү, Оренбург һәм Уфа архивындагы күп чыганакларны, экспедиция материалларын өйрәнеп, бу зур территориядә татар теленең ике диалекты (урта һәм мишәр) сөйләшләре таралган булуын ачыклый. Шулай итеп, Зидә Рәшит кызы татар теленең богырыслан, каргалы, шарлык сөйләшләрен ачыклап, алардагы

әһәмиятле үзенчәлекләрне, үзенең яңалыгы буларак, фәнгә кертә, тәҗрибәле галим булып җитешә.

Зидә Садыйкова диссертациясен уңышлы яклаганнан соң да диалектология юнәлешендә тикшеренүләрен дәвам итә. Галимәнең татар сөйләшләренең лексик байлыгын туплаган диалектологик сүзлекләрне төзүдә өлеше зур. 1969, 1993, 2009 елларда тел секторының шул чорлардагы диалектологлар төркеме (авторлар рәтендә З.Р. Садыйкова да бар) төзегән татар теленең диалектологик сүзлекләре дөнья күрә. 1989 елда төзүчеләре бер төркем диалектолог галимнәребез (Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова һәм Т.Х. Хәйретдинова) булган «Урта Идел буе һәм Урал төбәге татар сөйләшләренең атласы» (I, II томнар) һәм аңа аңлатма басылып чыга. Бу хезмәттә дә Зидә Садыйкованың лаеклы өлеше бар. 2008 елда басылган ике китаптан торган «Татар халык сөйләшләре» (авторлар коллективы: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова, З.Р. Садыйкова, Р.С. Барсукова) [15; 16] җыентыгында аның оренбург сөйләшләре төркеме, шулай ук камышлы, темников, мәләкәс, шарлык, чүпрәле сөйләшләре хакында тирән эчтәлекле мәкаләләре урын ала.

Галимә «Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре өчен кыскача урысча-татарча сүзлек»не [2] төзүдә катнаша, «Хайванчылык» һәм «Кортчылык» бүлекләрен эшли, «ЗАГС хезмәткәрләре һәм ритуаль хезмәт күрсәтүчеләр өчен русча-татарча сүзлек-минимум»ның [3] фәнни редакторы була.

Зидә Рәшит кызы Садыйкова Институтта 46 ел эшләү дәверендә иллегә якын экспедициядә катнаша. Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, Удмуртия, Мордовия республикаларында, Киров, Оренбург, Пермь, Ульяновск, Түбән Новгород, Новосибирск һәм Төмән өлкәләрендә йөреп, анда яшәүче татарлар сөйләшләренә кагылышлы материаллар туплый. Ул чорларны хезмәттәше Д. Рамазанова инде үзе филология фәннәре докторы булгач та сагынып искә ала: «Миңа аспирантурага кергәч, материал туплау, диалектологик экспедицияләр оештыру һәм уздыру методикасын Зидә ханым өйрәтте, үзе белән мине экспедициягә алып чыкты, җирле үзенчәлекләрне табу өчен әңгәмә оештыру юлларын күрсәтте, диалекталь сүзләрне язып алу өчен әби-бабайларга нинди сорауны ничек бирү серләренә төшендерде. Институтта 46 ел эшләү дәверендә уздырылган һәр экспедициядә (алар минем 150 дән артык) мин Зидәнең киңәшләрен һәрчак истә тота идем» [1].

80 нче елларда диалектолог галимнәребез төп эшчәнлекләрен диалекталь лексиканы, аның төрле лексик-семантик төркемнәрен тикшерүгә юнәлтә. Зидә апа Садыйкованың бу елларда татар телендәге һәм татар сөйләшләрендә булган кыргый һәм өй хайваннары, балыклар, бөҗәкләр атамаларын өйрәнгән мәкаләләре (1988, 1989, 1990) басыла һәм 1994 елда Татарстан китап нәшриятында «Зоонимическая лексика татарского языка» [11] дигән монографиясе дөнья күрә.

Авторның җентекле анализында татар сөйләшләреннән җыелган бай материал башка төрки телләр, тарихи чыганаклардагы мәгълүматлар белән чагыштырып бирелә, этимологик күзәтүләр дә урын ала. Мәсәлән, бөҗәк атамаларын туплау барышында Зидә Садыйкова татар сөйләшләрендә камканы атаган ике дистәдән артык лексеманы терки, әлеге атамаларның таралу ареалын билгели: пермь сөйләшендә қойаш қорт, красноуфим – қойашымбақ, минзәлә – тәти әби, кама тамагы – әңкәтүтәй, казан арты керәшеннәре – қандый әби, сергач – алла бабай таwыгы / әби-бабай таwыгы, линта борын, байкыбаш – күземкүз, турбаслы – күзмәкүз, казан арты – балтач – ғәйшәбану, казан арты-арча – ғәйшәбикә, дөбьяз, лаеш – Фатыйма, казан арты – мамадыш – тимерғәли, златоуст – қатқантун, бөре – қызылтун, нократ – әрмәнүч, каргалы – тәти қашық һ. б. [11: 91]. Автор әлеге атамаларны кызыклы мисаллар белән раслап бара: Камка-тутка, оч-оч, анаң салма пешерә, атаң ашап бетерә (тмн.) [11: 91]. Башка мәкаләләрдә дә бай материал, тәфсилле анализ китерелә.

Борынгы заманнардан ук кешелек җәмгыятендә озынлыкны, авырлыкны, күләмне, зурлыкны билгеләү өчен үлчәү берәмлекләре булган. Хәзерге татар әдәби телендә кулланылышта булган, шулай ук борынгы язма истәлекләрдә, сүзлекләрдә теркәлгән, татар сөйләшләрендә сакланып калган үлчәү атамалары турында Зидә Садыйкованың «Татар сөйләшләрендә кайбер озынлык үлчәме берәмлекләре» [5: 375–388], «Тукучылык белән бәйләнешле озынлык үлчәме атамалары» [7: 131–132], «Татар телендә кайбер авырлык үлчәү берәмлекләре атамалары» [8: 96–98] кебек мәкаләләрендә кыйммәтле тел материаллары урын ала.

Институтта эшләвенең соңгы елларында З.Р. Садыйкова татар әдәби телендә һәм татар сөйләшләрендә йорт-каралты һәм хуҗалык инвентарьлары атамалары турында монографик эзләнүләр алып бара. Аның бай фактик материалга нигезләнеп язылган «Названия родника, колодца и пруда в татарских говорах (Татар сөйләшләрендә чишмә, кое һәм буа атамалары)» [12], «Понятия «улица» и «двор» в татарских говорах (Татар сөйләшләрендә «урам» һәм «ишегалды» төшенчәләре)» [13], «Татар телендә капка» төшенчәсе һәм аны белдерә торган сүзләр» [4: 100–105] һ. б. мәкаләләре Институтның төрле елларда басылган җыентыкларында дөнья күрә. Галимә 2003 елда «Названия хозяйственных построек и инвентаря (Татар телендә йорт-каралты һәм хуҗалык инвентарьлары)» [14] исемле монографиясен рус телендә бастыра. Татар материаль мәдәниятенең шактый зур катламын тәшкил иткән бу тематик төркем татар халкының көнкүреше, гореф-гадәтләре үзенчәлекләре һәм тарихи тәҗрибәсе белән тыгыз бәйләнгән. Китапта татар телендә һәм сөйләшләрендә кулланылган йорт-каралты һәм хуҗалык инвентарьлары лексикасы тәкъдим ителә. Автор диалектологик һәм лексикологик экспедицияләрдә тупланган биш йөздән артык сүзне, сөйләшләрдәге фонетик вариантларын, алардан ясалган кушма сүзләрне үз эченә алган бай материалга синхрон һәм диахрон аспектларда якын килә: иске татар язма әдәби теле

истәлекләреннән, хәзерге татар теле һәм башка төрки, төрки булмаган телләрдән мисаллар белән чагыштырып, әһәмиятле нәтиҗәләр ясый. Мәсәлән, урам һәм аның аерым өлешләре төшенчәләрендә йөргән сүзләрне өйрәнү барышында Зидә Садыйкова бу төркем лексиканың (урам, тыкырык, тыгырык, оч, чук, аймак, аумак, аумак, төбәк, җыйын, курмыйш, кисәк, атау, канат, аwыл, улча) халыкның тарихы, этнографиясе, тормыш-көнкүреше белән бәйле икәнлеген ассызыклап, тарихчы, этнограф галимнәрнең дә хезмәтләренә мөрәҗәгать итә, сүзләрнең этимологиясенә туктала, монгол, төрки, фин-угор телләрендә очраганлыкларына мисаллар китерә, татар сөйләшләрендә кулланылу ареалларын ачыклый [13: 12–16].

Галимә озак еллар Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (соңрак Тел, әдәбият һәм сәнгать) институтында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшләп 2007 елда лаеклы ялга китә.

Филология фәннәре кандидаты Зидә Рәшит кызы Садыйкованың татар диалектологиясенә караган күпсанлы мәкаләләре, монографияләре бай, кызыклы фактларга нигезләнгән, һәр очракка төгәл аңлатма, җентекле анализ булуы белән аерылып торалар. Аларда татар сөйләшләренә караган кыйммәтле материаллар урын ала һәм алар татар тел белемендә, татар диалектологиясендә булган аерым мәсьәләләрне ачыклауда зур әһәмияткә ия.

**Әдәбият**


1. *Баязитова Ф.С., Рамазанова Д,Б., Хәйретдинова Т.Х.* Хезмәте барның хөрмәте бар // Мәдәни җомга. 2010. 30 апрель.

2. Краткий русско-татарский словарь для работников сельского хозяйства / сост.: Ф.Ф. Гаффарова, З.Р. Садыкова. Казан: Татар. кн. изд-во, 1995. 192 с.

3. Русско-татарский словарь-минимум для работников ЗАГСа и ритуальных услуг / сост. Ф. С. Баязитова. Казань: Татар. кн. изд-во, 1994. 71 с.

4. *Садыйкова З.Р.* Татар телендә капка төшенчәсе һәм аны белдерә торган сүзләр // Актуальные вопросы татарского языкознания. Вып. 3. Казань, 2004. Б. 100–105.

5. *Садыйкова З.Р.* Татар сөйләшләрендә кайбер озынлык үлчәме берәмлекләре // Инсани фәннәр: эзләнү һәм табышлар. Казань, 2004. Б. 375–388.

6. *Садыйкова З.Р.* Л. Җәләй. Аңа килгән хатлар // Актуальные вопросы татарского языкознания. Вып. 4. Казань, 2005. С. 145–149.

7. *Садыйкова З.Р.* Тукучылык белән бәйләнешле озынлык үлчәме атамалары // Материалы VIII Межрегиональной науч.-практ. конф. (г. Тобольск, 12–13 мая 2005 г.). Тюмень: ИПЦ Экспресс, 2005. С. 131–132

8. *Садыйкова З.Р.* Татар телендә кайбер авырлык үлчәү берәмлекләре атамалары // «Сулеймановские чтения – 2006»: материалы IX Всерос. науч.-практ. конф. (г. Тюмень, 18–19 мая 2006 г.). Тюмень: ИПЦ Экспресс, 2006. С. 96–98.

9. *Садыкова З.Р.* Формирование говоров оренбургских татар (по данным фонетики) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Казань, 1979. С. 73–104.

10. *Садыкова З.Р.* Говоры оренбургских татар. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 159 с.

11. *Садыкова З.Р.* Зоонимическая лексика татарского языка. Казань: Татар. кн. изд-во, 1994. 128 с.

12. *Садыкова З.Р.* Названия родника, колодца и пруда в татарских говорах // Татар теле һәм этносы тарихы мәсьәләләре. Казан, 2000. Б. 67–74.

13. *Садыкова З.Р.* Понятия «улица» и «двор» в татарских говорах // Актуальные вопросы татарского языкознания. Казань, 2002. С. 123–129.

14. *Садыкова З.Р.* Названия хозяйственных построек и инвентаря в татарском языке. Казань: Печ. Двор, 2003. 210 с.

15. Татар халык сөйләшләре: ике китапта: беренче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ. б. Казан: Мәгариф, 2008. 463 б.

16. Татар халык сөйләшләре: ике китапта: икенче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ. б. Казан: Мәгариф, 2008. 463 б.

***Кадирова Энҗе Хәнәфи кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Кадирова Энзе Ханафиевна,***
*кандидат филологических наук, доцент, старший научный сотрудник отдела общей лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*enge@inbox.ru*

УДК 792.2

***Г.Р. Әюпова***

# СОВЕТ ИЛЕННӘН КИЛГӘН ИЛЧЕ

В данной статье рассматривается деятельность и жизненный путь одного из основоположников дипломатии, первого дипломата Советского Союза на арабском Востоке Карима Габдрауфовича Хакимова (1892–1938). Автор статьи дает достаточно ёмкую информацию о ключевых фактах из биографии К. Хакимова, раскрывает роль семьи в становлении его как личности. Также описывается спектакль «Красный паша» (2024) Оренбургского государственного татарского драматического театра имени М. Файзи по пьесе Р. Аюпова и Р. Абянова, представляющий собой жизнеописание интересующей нас личности. При оценке самого спектакля основное внимание направляется на определение оригинальных режиссерских решений, отличавших постановку от предыдущих и поспособствовавших раскрытию духовного мира героев, углублению идейного содержания и погружению зрителя в разворачивающиеся действия, также дается оценка игры актеров и выделяется идейно-нравственная значимость спектакля.

**Ключевые слова**: Карим Хакимов, татарские дипломаты, иммерсивный театр, документальный спектакль.

The article is review of the activities and life path of one of the founders of diplomacy, the first diplomat of the Soviet Union in the Arab East, Karim Gabdraufovich Khakimov (1892–1938). The author of the article provides sufficient information about the key facts from the K. Khakimov's biography of the character, reveals the role of the family in the formation of his personality. The play "Krasny Pasha" Orenburg State Tatar Drama Theater named after M. Faizi based on the play by R. Ayupov and R. Abyanov, which is a biography of the personality we are interested in, is also described. When evaluating the performance itself, the main focus is on identifying original directing decisions that distinguished the production from previous ones and contributed to the disclosure of the spiritual world of the characters, deepening the ideological content and immersing the viewer in the unfolding actions, as well as evaluating the actors' performance and highlighting the ideological and moral significance of the performance.

**Keywords:** Karim Khakimov, Tatar diplomats, immersive theater, documentary performance.

Соңгы вакытта Россия белән Көнчыгыш илләре арасында дустанә мөнәсәбәтләр һәм икътисади элемтәләр ныгыды. Күптән түгел генә Казанда булып узган БРИКС илләренең саммиты моңа ачык мисал булып тора. Татарстан Республикасы башкаласы 30 дан артык илнең дәүләт башлыкларын, хөкүмәт җитәкчеләрен кабул итте.

Әлеге ныклы элемтәләрнең чишмә башында торган, моннан 100 ел элек үк инде дипломатиягә нигез салган күренекле шәхесләребезнең берсе Кәрим Габдерәүф улы Хәкимовның тормышы һәм эшчәнлеге аерым игътибарга лаек. Ул – Советлар иле белән Көнчы-

гыштагы гарәп илләре арасында эшлекле хезмәттәшлек урнаштырган беренче дипломат.

Кәрим Хәкимов 1892 елда Башкортстанның Бишбүләк районы Дүсән авылында туа (бүгенге көндә әлеге авылда аның музее эшли). Яшьли авыр эшләрдә – тимерьюлда, шахтада эшли. Инкыйлаб елларында большевиклар партиясе эшчәнлегендә актив катнаша, давыллы көрәш елларын Оренбургта каршылый, Халык мәгарифе комиссариатын җитәкли, Гражданнар сугышында Төркестан фронтында хәрби комиссар була. 1921 елдан башлап Чит ил эшләре комиссариатында хезмәт куя [4: 12–13].

Коммунистик идеяләр белән янып яшәсә дә, К. Хәкимовның дини белемле булуы, ислам кануннарын үтәп яшәргә тырышуы мәгълүм. Бу факт аның дипломатлык эшенә дә йогынты ясаган, күрәсең. 1921 елда В. Куйбышев тәкъдиме белән тулысынча дипломатлык эшенә күчкәч, ул РСФСРның Ирандагы генераль консуллыгына җитәкчелек итә. 1924 елда СССРның Хиҗаз патшалыгындагы тулы хокуклы вәкиле итеп билгеләнә. Шул ук елны К. Хәкимов Гомрә хаҗы кыла. 1929–1932 елларда Йәмәндә генераль консул вазифасын башкара һәм бер үк вакытта «Ближневосторг» оешмасы вәкиле була. «Шул вазифасын башкарган вакытта Кәрим Габдерәүф улы Хәкимов тырышлыгы белән Габделгазиз ибне Сауд СССРның стратегик партнёрына әйләнә, үзара мөнәсәбәтләр яхшыра һәм совет товарларына яшь ил базарына киң юл ачыла. Гарәп халкы, яратып, «Кызыл паша» дип атаган милләттәшебез 1926 елда мөфти Риза Фәхреддин җитәкчелендәге ислам дине әһелләренең Мәккә каласында үткән Беренче бөтендөнья мөселманнар конгрессында катнашуын оештыра һәм бер елдан халык өчен беренче чиратта кирәкле он, шикәр, керосин төялгән диңгез судноlары белән тәүге өч партиянең Одессадан Җиддәгә җибәрелүенә ирешә [3: 8–9].

К. Хәкимов Россия тарихында, төрки халыкларда, мөселман дөньясында, гарәп илләрендә иң мөһим сәяси һәм икътисади мәсьәләләрне хәл итүдә шактый тирән эз калдырган легендар зат буларак билгеле.

Әлбәттә, һәр кешенең шәхес буларак формалашуына күптөрле факторлар йогынты ясый. К. Хәкимовның киң карашлы күренекле дипломат булып җитешүендә, бер яктан, яшьтән иҗтимагый-сәяси тормыш үзәгендә кайнавы, эшлеклелеге, активлыгы этәргеч булса, икенче яктан, җәмәгате Хәдичә Нугаеваның да роле гаять зур була.

Кәрим белән Хәдичә 1920 елда Төркестанның Фирганә шәһәрендә танышалар. Хәдичә агитбригада белән фронтовикларга концертлар куеп йөри. Кәримнең үткен күзе чибәрлеге һәм чаялыгы белән аерылып торган кызны тиз эләктереп ала. Танышып бераз вакыт узгач, кавышып та куялар. Аңа гашыйк булган комиссар К. Хәкимов, кайнар хисле, харизмалы кеше буларак, Хәдичәгә тәкъдимне дә көтелмәгәнчә ясый. Кобурасыннан наганын чыгарып: «Хәдичә, чык миңа кияүгә! Әгәр дә сиңа берәрсе якын итеп кул тидерсә, шушы кулым белән

икегезне дә атып үтерәм!» – ди. Бу аның мәхәббәт аңлатуы була [1]. Хәдичә ризалык бирә.

1924 елда К. Хәкимов гаиләсе белән Көнчыгышка, чүлләр иле Гарәбстанга юл тота. Миләрне кыздырырлык эссе кайнар һавасы белән көйдергән җиде ят илгә Хәдичәнең бер дә күңеле тартмый, әмма Кәриме артыннан калмый. Ил өчен, идея өчен янган К. Хәкимовның күңел омтылышын ул аңлап кабул итә.

Чүлләр иле яшь гаиләгә олы сынаулар әзерли: хаҗ сәфәре вакытында уллары Шамил дизентериядән вафат була. Кәримен тирән мәхәббәт белән яраткан Хәдичә бу олы хәсрәтне дә кичерергә үзендә көч таба, хәтта әлеге вакыйга аның иҗтимагый эшчәнлегенә юнәлеш тә бирә: ул Советлар Союзыннан Гарәбстанга медицина хезмәте күрсәтүче белгечләр китертүне, медикаментлар алып килүне оештырып йөри башлый. Гомумән, Хәдичә иренә дипломатлык эшендә зур терәк, зирәк киңәшче була, аның белән эшлекле очрашуларга да йөргәли.

Гарәпләр К. Хәкимовны, яратып, Совет иленнән килгән илче буларак үз итеп, «Кызыл паша» дип йөртәләр. Хәкимовлар гаиләсе ул вакыттагы Гарәбстан короле Абдел Газиз ибне Сауд белән дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыра.  К. Хәкимовка һәм аның гаиләсенә король тирән хөрмәт белән карый. Хәкимовларның Җиддәдә җирләнгән уллары Шамилнең каберен карап, тәрбияләп торуны да корольлек үз өстенә ала.

Легендар дипломатның тормыш юлы һәм эшчәнлеге төрле чорларда тикшеренүчеләрне, иҗат әһелләрен кызыксындыра: К. Хәкимовка багышланган спектакльләр куела, фәнни эшләр языла, соңгы вакытта аның шәхесенә игътибар артканнан-арта бара.

Кәрим белән Хәдичә мәхәббәтен сюжет үзәгенә куйган «Кызыл паша» спектакле (пьеса авторы – башкорт драматургы Нәҗип Әсәнбаев) 1982 елда Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театрында режиссёр Лек Вәлиев тарафыннан сәхнәгә чыгарыла һәм зур уңыш казана. Күп кенә тарихи вакыйгаларны эченә алган спектакль классик вариантта куела. Лек Вәлиев һәм Кәрим Хәкимов образын уйнаган артист Әхтәм Абушахманов Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булалар.

«Кызыл паша» спектакле Кәрим Хәкимовның тууына 130 ел тулу уңаеннан 2022 елда Уфада кабат яңартып куела. Ул 1982 елда сәхнә күргән спектакльгә нигезләнә, шул ук вакытта режиссер Айрат Абушахманов аны эчтәлек ягыннан тагын да баета. Беренче вариантта геройның балачагы, үсмер вакыты күрсәтелмәгән була. Яңартылган спектакль Кәрим Хәкимовның балачагы һәм аның хакында моңарчы билгеле булмаган яңа тарихи фактлар белән тулыландырыла. Спектакль классик формада сәхнәләштерелә.

2024 елның 5 октябрендә М. Фәйзи исемендәге Оренбург Татар дәүләт драма театры сәхнәсендә күрсәтелгән «Кызыл паша» спектакле исә Башкорт академия театрыныкыннан иммерсив формада

куелуы белән аерылып тора: тамашачылар актёрлар белән бер яссылыкта, ягъни сәхнәдә түгәрәк ясап утыралар.

Югарыда телгә алынган Башкорт академия театрының 2022 елда яңартып куелган (режиссёры А. Абушахманов) һәм Оренбург татар драма театрының иммерсив (режиссёры Р. Әюпов) спектакльләрендә уртаклык шуннан гыйбарәт: аларның икесендә дә документаль фактларга басым ясала, легендар шәхеснең дипломатлык таланты һәм күпкырлылыгы гәүдәләндерелә.

М. Фәйзи исемендәге Оренбург татар дәүләт драма театрында сәхнәләштерелгән спектакльдә җырлар, символик эчтәлеккә ия булып, геройларның язмыш борылмаларын тасвирлап бирүдә, аларның күңел дөньяларын ачуда төп алымнарның берсе булып китәләр. Әйтик, «Ком бураны» җыры нәкъ менә шушы максатка хезмәт итә:

Ком бураны, ком бураны,
Оренбурның урамы.
Илдә давыл булган чакта
Өйдә торып буламы.

Әлеге җыр юллары аша К. Хәкимовның гарәп илләрендә дәрәҗәле илче вәкаләтен үтәве, Совет иле өчен башкарган эшләренең ком бөртекләре кебек җилгә очуы, аның тарихка кереп калган игелекле гамәле: илебездә яшәүче мөселманнарга хаҗ кылырга юл яруы, беренче булып Мәккәгә китертүе, тынгысыз җаны, фаҗигалы ачы язмышы – барысы да бер-бер артлы күз алдыннан уза.

Хәдичә башкаруындагы «Каз канаты» җыры аша исә Кәрим белән Хәдичәнең ерак чит җирләрдә туган илләрен сагынулары, авыр көрәш юлларын узулары, Хәдичәнең репрессия корбаны булган Кәримне көтүе, аны юксынуы, үзе дә каты режимлы АЛЖИР хатын-кызлар лагеренда сигез ел буе газап чиккәндә, кызы Флораны, мәрхүм улын сагынып сызуы җан авазы булып яңгырый. Спектакльгә режиссёр Р. Әюпов тарафыннан кертелгән бу җыр аша түбәндәге фикер кызыл җеп булып сузыла: уңышка ирешер өчен ныклы терәк – ике канатың булу кирәк. Җыр сүзләрендәге каз образы («Каз канаты кат-кат була...») спектакльнең идея-юнәлешен билгеләүдә әһәмиятле роль уйный. Казлар, гомумән, очар кошлар, бер-берсен сөйгән бу ике ярның мәңгегә аерылу сагышын да, газаплы тормыш юлларын да тамашачы күңеленә үтемле җиткереп, спектакльнең тәэсир көчен тагын да ныграк арттыра. Коммунист булса да, диненнән ваз кичмәгән Кәрим Хәкимов, Мәскәүгә чакыру килгәч, илдәге яңа идеологиянең үзе кебекләрне кабул итмәвен яхшы аңлый, шуңа күрә дә үзен упкынга атлаган кебек хис итә.

Спектакльнең сценография авторы яшь рәссам Елизавета Буланкина, шартлы эчтәлекле күчәрле тәгәрмәч кулланып, дипломатның гел юлда булуына ишарәли. Тәгәрмәчләр, поездга, автомобильгә әйләнеп, бер ил белән икенче ил арасындагы дипломатик күперләр

салынуны да аңлата. Иммерсив спектакльдә түгәрәк сәхнәнең әйләнүе юл хәрәкәтен, динамиканы тоярга мөмкинлек бирә, киңрәк масштабта карасак, җир шарының шулай шартлы рәвештә тасвирлануы аңлашыла. Төп герой, канатларны түгәрәккә тезеп, хаҗ кылучы мөселманнарның киләчәктә Мәккәгә барачагын күрсәтә. Спектакльдәге канатлар – Аллаһтан баш тарткан илдә рухилык символы да.

Сәхнә түренә ике агач куелган, алар шулай ук самолётның ике канатын, поезд рельсын, Хәдичә утырган АЛЖИР лагерен уратып алган коймаларга ишарәли.

Спектакльнең сценографиясе минимализм һәм символизм форматында эшләнгән. Спектакль ахырында геройны атып үтерү күренеше реалистик формада түгел, ә символлар аша гамәлгә ашырыла. Мылтыктан ату тавышы ишетелгәч, сәхнәгә күпсанлы кечкенә кызыл шарчыклар ишелеп тәгәриләр. Режиссёрның бу алымы Совет системасында хөкем сөргән шәхес культы елларында илебезнең төрле төбәкләреннән бик күп талантлы, зыялы шәхесләрнең бер гаепсезгә каннары түгелүне аңлата. Сәхнәдә кан төсендәге шарлар һәм кызыл ут Кызыл паша, ягъни Кәрим Хәкимов образының шәхси драмасын тагын да көчәйтә.

Пьесаның авторлары – Г. Кариев исемендәге театрның баш режиссёры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ренат Әюпов һәм Россия Диния нәзарәтенең (Мәскәү) мәдәният департаменты җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, тарихчы Ренат хәзрәт Абянов. Алар Кәрим белән Хәдичәнең олы мәхәббәтен, гаиләдә дә, эштә дә, көрәштә дә бергә һәм бердәм булуларын пьесада зур осталык белән тасвирлый. Ренат хәзрәт Абянов, үзе дә дин әһеле буларак, бу ике шәхеснең кичерешләрен, психологик халәтләрен тирәнтен ачып бирә.

Спектакльдә Хәдичә ролен театрның талантлы актрисасы Рәзифә Хәйруллина башкара. Ул образның рухи драматизмын, хисләр тирәнлеген, ихласлыгын үтемле җиткерә. К. Хәкимов ролендә – Татарстанның атказанган артисты Марсель Рәхмәтуллин. Алар, сәхнәдә илләренә һәм мәхәббәтләренә тугры пар буларак гәүдәләнеп, тамашачы күңелен яулыйлар. Пьесада Хәдичә образының казлар турында әкият сөйләве аша хатынның ирен һәм кызын сагыну сагышы сурәтләнә.

Лагерьдан аяклары җәрәхәтләнеп кайтса да, Хәдичә көчле рухлы булып кала. Кызы Флора тәрбиясендә гомер кичерә. Аллаһы Тәгалә аны озын гомер белән бүләкли. Каһарман ханым иренең һәм үзенең исемнәре аклану хәбәрен сабыр гына көтеп яши һәм аңа ул көнне күрү насыйп була. Милләтебезнең мәшһүр улы Кәрим Хәкимов һәм аның батыр хатыны Хәдичә Нугаеваларның бер үк вакытта Ватанга да, мәхәббәткә дә тугрылык белән сугарылган катлаулы язмышлары тарихы әлеге спектакльдә көчле чагылыш таба. Бу ике шәхеснең мәңгелек мәхәббәт тарихы – безнең өчен тугрылык һәм батырлык үрнәге.

**Әдәбият**

1. *Вәлиев Р.* «Кызыл Паша» Кәрим Хәкимовның үз кулы белән милләтен «татар» дип күрсәткән дипломатик анкетасы бар // Интертат [Электрон ресурс]. – 2019. – 29 окт.) URL: https://intertat.tatar/news/rimzil-v-liev-kyzyl-pasha-k-rim-h-kimovny-z-kuly-bel-n-mill-ten-tatar-dip-k-rs-tk-n-diplomatik-anketasy-bar?ysclid=m6et4gmxhl631130026 (дата обращения:24.01.2025)

2. *Гадилов Л.З.* Карим Хакимов: (революционер и дипломат, 1892–1937): историко-биографический очерк / Л.З. Гадилов, Ф.Х. Гумеров. Уфа: Башкир. кн. изд-во, 1960. 84 с.

3. *Зарипов Р.* Кызыл Паша: дипломат һәм разведчик: (СССРның Шәрык илләрендәге тышкы сәясәтенә зур өлеш керткән Кәрим Хәкимов турында) // Мәдәни җомга. 2018. 23 март (№ 11). Б. 8–9.

4. *Хәсбиуллина Г.* «Кызыл Паша» Кәрим Хәкимов: (Согыд Гарәбстанында беренче совет дипломаты Кәрим Габдерәүф улы Хәкимов (1892–1938)) // Мәдәни җомга. 2020. 10 гыйнвар (№ 1). Б. 12–13.

***Әюпова Гөлшат Рафаэль кызы,***
*ТР ФА М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Энциклопедистика үзәге фәнни хезмәткәре*

***Аюпова Гульшат Рафаэловна,***
*научный сотрудник Центра энциклопедистики Института татарской энциклопедии и регионоведеня им. М. Хасанова АН РТ*

*gulshat-2773@mail.ru*

УДК 908

*Н.Р. Вахитов*

# ТИФЛИСТӘН ТӨШКӘН МӘГЪРИФӘТ НУРЫ...

В Тифлисе, культурном центре Кавказского региона, в 1903–1905 годах издавалась газета «Шарки Рус», выходившая под управлением видных азербайджанских писателей Мухаммед-ага Шахтахтинского (1846–1931) и Джалила Гусейнгулу оглу Мамедгулузаде (1866–1932). Через эту газету выражали свои мысли и татарские публицисты и писатели. В этот период, когда еще не зародилась периодическая печать на татарском языке, достаточно свободолюбивая «Шарки Рус» завоевала внимание и симпатию и на Волго-Уралье. Один за другим в центральных городах России у газеты появились свои корреспонденты, писатели и подписчики.

Среди них был и один из уважаемых лиц Оренбурга Фатих Карими. В 30-м номере «Шарки Рус» за 1904 год была опубликована его аналитическая статья, посвященная рассказу Закира Хади «Бәхетле кыз» («Счастливая девушка»). В ней, после упоминания о современном состоянии татарского общества и сложностях становления молодой татарской литературы, кратко излагается содержание рассказа и затрагиваются проблемы, поднятые в произведении (невежество отдельных представителей духовенства, состояние образования, судьба женщин и т. д.).

В заключительной части, написанной в просветительских традициях, делается вывод: «невежество – смерть, знание – жизнь»; обязательность служения Отечеству, нации и человечеству для того, чтобы стать счастливыми.

Вниманию читателей впервые представлена эта статья Фатиха Карими на кириллице.

**Ключевые слова:** «Шарки Рус», Фатих Карими, Закир Хади, просветительство.

In Tbilisi, the cultural center of the Caucasus region, in 1903–1905, the newspaper “Sharqi Rus” was published under the direction of prominent Azerbaijani writers Muhammad-aga Shakhtakhtinsky (1846–1931) and Jalil Huseyngulu oglu Mammadguluzade (1866–1932). Tatar publicists and writers expressed their thoughts through this newspaper. During this period, when periodicals in the Tatar language had not yet been born, the rather freedom-loving Sharky Rus gained attention and sympathy in the Volga-Urals. One by one, the newspaper gained its own correspondents, writers, and subscribers in the central cities of Russia.

Among them was one of the respected figures of Orenburg, Fatih Karimi. In the 30th issue of Sharky Rus in 1904, his analytical article on Zakir Hadi’s short story “The Happy Girl” was published. In it, after mentioning the current state of Tatar society and the difficulties of the formation of young Tatar literature, the content of the story is briefly outlined and the problems raised in the work are touched upon (ignorance of individual representatives of the clergy, the state of education, the fate of women, etc.).

The final part, written in the enlightenment traditions, concludes: “ignorance is death, knowledge is life”; the obligation to serve the Fatherland, nation and humanity in order to become happy.

This article by Fatiha Karimi in Cyrillic is presented to the readers for the first time.

**Keywords:** “Sharqi Rus”, Fatih Karimi, Zakir Hadi, enlightenment.

*Кавказ төбәгенең мәдәни мәркәзе Тифлис каласында 1903–1905 елларда күренекле каләм ияләре Мөхәммәд ага Шахтахтинский (1846–1931) һәм Җәлил Мөхәммәдколыйзадә (1866–1932) җитәкчелегендә чыгып килгән «Шәркы Рус» газетасы Идел буенда да киң таралган. Татарның зыялы мөхәррирләре шушы басма аша уй-фикерләре белән бүлешкән, милли проблемаларны күтәргән. Эчке Русиядә вакытлы матбугат әле оешеп кына килгән чорда, кыю сәясәтле, шактый иркен мәсләкле, үз сәхифәләрендә төрле фикер яктыртырга тырышкан «Шәркы Рус» тиз арада игътибар казанган. Мәмләкәтнең үзәк калаларында бер-бер артлы газетаның үз мөхбирләре, язышучылары һәм абунәчеләре барлыкка килгән.*

*Ике ел чамасы гына (300 ләп сан) чыгып калган газетада дистәләрчә татар авторының язмаларын күрәбез. Һәрбер санда диярлек Габдрәшид Ибраһим (Санкт-Петербург), Риза казый Фәхреддин (Уфа), Камил Мотыйгый (Җаек), Мөхәммәдфатих Күлтәси (Әстерхан), Насреддин Хуҗаши (Казан), Габдрахман Гомәри (Әстерхан), Вәгыйзь Нәүрузов (Мәскәү), Шакир Мөхәммәдьяров (Оренбург), Фатих Кәрими (Оренбург), Гаяз Исхакый, Мөхәммәдсадыйк Каргалый, Хәлим Сабит Лабити һ. б. кебек төрле катлаудан чыккан, төрле иҗтимагый-сәяси карашларга ия булган бик күп зыялыларның мәкалә-фельетоннары дөнья күрә. Тәрәккыйпәрвәр муллалар, җәдитче мөгаллимнәр, алдынгы фикерле җәмәгать хадимнәренең хатлары басыла. Бу язмалар арасында тел-әдәбият проблемалары (алфавит реформасы, әдәби тел нормалары турында бәхәсләр, яңа басылган китапларга, дәреслекләргә рецензияләр, сәяхәтнамәләр, мәшһүр затларның биографияләре һ. б.), иҗтимагый-сәяси бәхәсләр (җәмгыяте хәйрияләр, хатын-кыз хәле, мәдрәсәләр торышы, ысулы кадим-ысулы җәдид гаугалары, милли бердәмлек, сүз ирege һ. б.), дини, тарихи мәсьәләләр (садака, бәдәл хаҗ, кыяс, гарәпләр ясаган ачышлар, милли һәм дини кыйммәтләр һ. б.) алгы планга чыга.*

*Шулар рәтендә Оренбургның мөхтәрәм затларыннан милләт хадиме, әдип һәм мөхәррир Фатих Кәримине искә алырга кирәк. Тиздән үзе дә мәшһүр «Вакыт»ның нашире булган әлеге шәхес инде шушы чорда ук хосусый матбагасында милли әсәрләр бастырып тарата башлый. «Шәркы Рус»ның 1904 елгы 30 нчы санында аның Закир Һадинең (1863–1933) «Бәхетле кыз» хикәясенә багышланган аналитик язмасы дөнья күрә. «Каләм» имзасы белән басылган бу мәкаләдә яшь татар әдәбиятының яралу баскычлары, әдип-мөхәррирләребезнең кәйфияте, руханиларның тәрәккыятькә каршылыгы искәртеп кителгәннән соң, «Бәхетле кыз» хикәясенең кыскача эчтәлеге бәян ителә һәм әсәрдә күтәрелгән проблемалар (надан, эшкә яраксыз руханиларның халык тормышына, мәгариф торышына, хатын-кыз язмышына*

*салган зыяны һ. б.) берәмләп санап кителә. Мәгърифәтчелек традицияләре рухында язылган йомгаклау өлешендә «җаһиллек – үлем, гыйлем – хәяттыр» дигән нәтиҗә ясалып; ике җиһанда бәхетле булу, дөньяда яхшы ат калдырып киту өчен ватанга, милләткә һәм гомум инсаниятkә хезмәт иту тиешлеге; тормыш сазлыгыннан котылып, гали хиссиятләр белән тулы рухани хәят мәртәбәсенә күтәрелү зарурлыгы; уку-укыту, тәгълим-тәрбия эшләрен заман таләпләренә тәңгәл китереп тәрәккый иттерү фарызлыгы бәян ителә.*

*Укучы игътибарына Фатих Кәриминең шушы язмасы беренче тапкыр кирилл хәрефләренә күчереп тәкъдим ителә.*

***Фатих Кәрими***

## Яңа китаплар – «Бәхетле кыз»

*Фельетон. Оренбургтан.*

Биш-ун елдан бирле безнең Казан вә Оренбург матбагаларында төрки телендә әдәбият башлангычы дип каралырга лаек бер иш вак-төяк рисаләчекләр[1], әдәби вә фәнни әсәрләр басылып килмәктәдер. Боларның бер өлеше – тарих, җәгърафия, хисап кебек гыйлем вә фәннәргә караган дәрес вә уку китапларыдыр, икенче өлеше исә – асыл әдәбият дип аталырлык нәрсәләр, иҗтимагый тормыш хәлләрен бәян иткән хикәя вә романчыклардыр. Дөрес, һәр ике аланда да әлегә тәрәккый вә камиллеккә ирешкәнебез юк, кимчелекләребез исә санап бетергесез күптер. Дәрес вә уку китаплары тәртип иту өчен, бик күп гыйлемнәр вә фәннәрдән хәбәрдар булу өстенә, педагогика һәм психология кагыйдәләрен белү тиеш булган кебек, хикәяләр вә романнар язып, каләм ярдәмендә җәмәгать фикерен дөрес тарафка юнәлдерү өчен дә бик күп мәгълүмат вә белем иясе булу кирәктер. Безнең мөхәррирләребез дә, әдип вә педагогларыбыз да – низамлы[2] тәгълим-тәрбия күргән, төпле уку йортларында камил белем алып чыккан затлар түгел, бәлки үзләрен мең бәла вә йөз төрле гайрәтләр илә мәдрәсә баткагыннан, схоластика дәрьясыннан коткарып, иркен сулыш алыр-алмас каләмгә ябышкан адәмнәрдер. Шуңа күрә, хәзергә алардан артыгын таләп иту вә кимчелекләре өчен хисапка тарту инсафка сыймас. Киресенчә, җәмгыять вә милләт файдасына хәл кадәре кылган хезмәтләре сәбәпле аларга рәхмәт белдерү тиештер. Һәр эшнең башы шулай була, һәр милләтнең тәрәккыйсе шул юл белән башлана. Өстәвенә, бу яңа әсәрләр арасында шактый әһәмиятле вә укылырга лаек булганнары да аз түгел. Аларның кайберләрендә киная юлы белән милләтебезнең мәгариф вә мәдәният, фикри тәрәккыят[3] җәһәтеннән артта калганлыгы, бу аяныч хәлдә катып яту ярамаган-

---

[1] Рисалә – җыентык.

[2] Низамлы – тәртипле.

[3] Фикри тәрәккыят – алдынгы фикер.

лыгы, заманга карап хәрәкәт итү зарурлыгы әйтелә. Ләкин һәртөрле яңарыш вә тәрәккый фикерләренә руханиларыбыз аяк терәп каршы торганга, яңа рисаләләрнең һәммәсендә дә диярлек руханилар хакында сүз чыкмый калмый. Бу хәл бер бездә генә түгел, башка милләтләрдә дә нәкъ шул төследер.

Менә шушы рисаләләр җөмләсеннән соңгы арада Оренбургта Мөхәммәдфатих Кәримов матбагасында «Бәхетле кыз» исемендә бер китап басылып чыкты. Язучысы З.Һ. хәрефләре артына яшеренгән. (Бу рисалә кечкенә буйда 100 бит булып, бәясе 14 тиен, сатылган җире – Оренбургта Кәримов матбагасыдыр).

Рисаләнең кыскача эчтәлеге шуннан гыйбарәт: Уфа вилаятендәге авылларның берсендә имам булып торган Нургаян әфәнде вафат була. Бер микъдар акчасы да булганга, имамның тол калган хатынына һәр тарафтан яучылар килеп торса да, бу ханым берсенә дә ризалык бирми. Мәхәллә озак вакыт башсыз торганга авыл халкының эчләре пошып, бер мәдрәсәдән Сәлимҗәүһәр исемле шәкертне китертеп имамлык вазифасын тапшыралар һәм мәрхүм имамның тол хатынына өйләндерәләр. Көннәрдән бер көнне яңа имам мәхәллә халкыннан берәүгә кунакка бара. Шунда ул, очраклы рәвештә, өй хуҗасының алма җимешедәй пешеп өлгергән, чәчәк төсле ачылган, фәрештәдәй гүзәл уналты яшендәге Гайшә исемле кызын күреп кала. Имамның сылу кызга күзе төшә, башы әйләнә, ничек булса да бер юлын табып, бу кызыкайны үзенеке итү әмәленә керешә.

Имам кебек изге кыяфәтле кеше сорагач, ата-ана күнәләр, ләкин кызның күңеле яшь, чибәр, фикерле вә мәгълүматлы, әле укуын да тәмамлап өлгермәгән Габбас исемле шәкерттә була. Имам үзе карт, кыяфәте чирканыч булудан тыш, ничә еллар бергә гомер иткән хатыны өстенә, әле яше дә тулып җитмәгән кызны алырга кызыгуы – бары хайвани теләкләре котырганнан гына булганга, Гайшә туташ аңа нәфрәт кылып елый да елый. Ләкин ата-анасына итагатеннән һәм, бигрәк тә, безнең татар кызлары арасында үз фикерен әйтү гадәте булмаганлыктан, никах көнендә ризалыгы соралганда дәшми кала. «Дәшмәү һәм елау – ризалык галәмәтедер» дип, бер шәех әфәнде никахны укып та ташлый, Сәлимҗәүһәр хәзрәт чәч-сакалындагы агара башлаган төкләрне йолкып, кыз куенына керергә әзерләнә башлый. Ләкин һич көтелмәгән бер хәл килеп чыгу сәбәпле, Сәлимҗәүһәргә кыз насыйп булмый. Ул мәче кебек иреннәрен генә ялап кала, никах бозыла. Кыз үзе сөйгән Габбас әфәндегә иргә бара. Хикәянең асылы менә шуннан гыйбарәт.

Моннан тыш, әсәрдә Уфа вилаятендәге башкорт вә типтәр авылларының көнкүреш хәлләре дә сурәтләнә. Имамлык мәкаменә кунаклаган бер иш булдыксыз вә яраксыз адәмнәрнең халык арасында ялгыш фикерләр, хорафатлар таратып ятуы; дин, белем, тәгълим-тәрбия мәсьәләләрендә кабилиятсез шыр надан хәлфә кисәкләренең халыкны ялкаулык вә эшсезлек чокырына төртеп төшерүләре; сөрсеп беткән мәгънәсез сөйләк-риваятьләрнең шәригать кагыйдәләреннән

өстен куелуы фаш ителә. Хатын-кызның мәгълүматлы вә тәрбияле булуы гаилә вә җәмгыять тормышына күркәм йогынты ясый, диелә. Укымышлы, төзек фикерле имамнарның мәхәллә халкын тәрәккый вә сәгадәт юлына алып чыгу өчен ни тиклем олы хезмәтләр итә алуы күрсәтелә. Аларның ни рәвешле хәрәкәт итәргә вә ни төсле вәгазьләр сөйләргә тиешлеге рисаләнең авторы тарафыннан тәфсилләп бәян ителә. Укучыларны ялыктырмас өчен, әсәрнең күп кенә урыннарына көлке-мәзәк элементлары кертеп җибәрелә.

Заман вә мәдәният тәэсире белән безнең тормыш вә көнкүрешебездә зур үзгәрешләр көтелә. Хәзерге хәлләребезне шундый рисаләчекләргә вак-вак хикәяләр итеп язып, киләчәктәге әдипләребез һәм язучыларыбызга ядкәр калдыру – бик күркәм эш. Алар күп рәхмәтләр әйтерләр. Укырга, язарга, өйрәнергә һәм белергә кирәк. Я булмаса бу дөньяда бөтенләй яшәмәскә. Җаһиллек – үлем, гыйлем – хәяттыр. Кешенең җисмани тормышы – бик кыска һәм вакытлы бер нәрсәдер. Мәңгелек рухани хәяты исә – милләтенә, диненә, ватанына вә гомум инсаниятkә эчкерсез хезмәт нәтиҗәсендә калдырып киткән изге исемедер. Ашап-эчү һәм ятып йоклаудан гыйбарәт булган хайвани тормыш белән чикләнмичә, башыбызда олы фикерләр, кальбебездә[1] гали[2] хиссиятләр хасил итеп, рухани тереклеккә һәм мәңгелек бәхет-сәгадәткә ирешергә тырышыйк.

Заман – тәрәккый заманы,
Җиһан – гыйлем җиһаны.
Бармы надан җәмгыятьнең
Исән-аман калганы?

*Каләм*

*Басмага әзерләде:*
***Вахитов Наил Ринат улы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

*К печати подготовил:*
***Вахитов Наиль Ринатович,***
*аспирант Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*bigey4052@gmail.com*

[1] Кальб – күңел.
[2] Гали – бөек.

УДК 821.512.145

*Л.Ш. Галиева*

## ФАТИХ ӘМИРХАН ӘСӘРЛӘРЕ ЯҢА БАСМАДА

*(алты томлы академик басманың 1 нче томы басылу уңае белән)*

(Әмирханов М.-Ф. М.-З. Әсәрләр: 6 томда / Фатих Әмирхан. – Академик басма. 1 т. : хикәяләр һәм повестьлар (1907–1911) / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Э.М. Галимҗанова, Ф.Г. Фәйзуллина; кереш сүз авторы Д.Ф. Заһидуллина]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. – 509 б.)

Статья представляет собой рецензию на первый том шеститомного академического издания классика татарской литературы Фатиха Амирхана (1886–1926), подготовленного сотрудниками отдела текстологии Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. В ней приведен краткий анализ материалов тома, что позволяет определить научную новизну издания. Краткая характеристика к тому включает рассмотрение ключевых произведений Ф. Амирхана, отражающих его уникальный стиль и актуальные социальные темы, которые были важны для татарского общества начала XX века.

**Ключевые слова:** татарская литература, Фатих Амирхан, академическое издание, текстология, история татарской литературы.

The article is a review of the first volume of the six-volume academic edition of the classic of Tatar literature Fatih Amirkhan (1886–1926), prepared by the staff of the textual Department of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. The review analyzes the materials of the volume, which makes it possible to determine the scientific novelty of the publication. A brief description of this includes a discussion of Amirkhan’s key works reflecting his unique style and current social themes that were important to Tatar society at the beginning of the 20th century.

**Keywords:** Tatar literature, Fatih Amirkhan, academic publication, textual criticism of F. Amirkhan’s works.

XX йөз башы яңа татар әдәбияты нигезен тәшкил иткән күренекле язучы, драматург, публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе, җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәтфатих Мөхәммәтзариф улы Әмирхановның (1886–1926) күпкырлы иҗатын иңләгән тулы мирасын дөньяга чыгару күптән көтелә иде. Моңа кадәр иң тулы басма дип саналган 1984–1989 елларда чыккан дүрт томлы «Әсәрләр» Ф. Әмирхан иҗатын барлык тулылыгында тәкъдим итә алмады. Төрле сәбәпләр, шул исәптән совет идеологиясе йогынтысында, әдипнең әсәрләре, публицистик мәкаләләре укучыга тулы килеш килеп ирешмәде: кайберләре томлыклардан төшереп калдырылды, шактыйлары кискәләнгән рәвештә дөнья күрде.

Ниһаять, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология

бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан әдипнең алты томлы академик басмасы әзерләнеп, Татарстан китап нәшриятында аның 1 нче томы басылып чыкты.

Филология фәннәре докторы, профессор Д.Ф. Заһидуллинаның томга кереш буларак тәфсилле язылган «Фатих Әмирханның “кайтуы”. Алтытомлык “Әсәрләр” турында берничә сүз» мәкаләсендә Ф. Әмирханның татар әдәбиятын яңа баскычка күтәрүдәге роле күрсәтелгән. Автор әдип иҗатының башлангыч чорыннан алып соңгы дәвердә язылган әдәби әсәрләренә кадәр яңача тулы фәнни бәя birә, укучыларда Ф. Әмирхан иҗатына кызыксыну уята.

Академик басманың 1 нче томында Ф. Әмирханның 1907–1911 елларда язылган хикәяләре һәм повестьлары урын алган. Тормыш агышын, шул исәптән татар җәмгыятенең үсешен, яңарыш юлларын уен-көлке, сызлану-борчылулар аша тасвирлаган әлеге әсәрләр бүгенге укучының да игътибарын җәлеп итә.

Гомере буе рус әдәбиятын, төрек һәм рус телләренә тәрҗемә ителгән Европа матур әдәбиятын яратып укыган әдип иҗат эшчәнлеген 1907 елда «Гарәфә кич төшемдә» хикәясе белән башлап җибәрә. Үз көнкүрешенең артталыгын һәм ирешү мөмкин булган Европача яшәү үрнәген тасвирлаган бу әсәр бүгенге көн укучысында да кызыксыну уята. Аның «Милләт тәрәккый иттерү» (1908), «Бәйрәмнәр» (1908), «Рәхәт көн» (1910), «Көндезге сәхәр яки рузасызлар» (1911) кебек хикәяләре дә яңалыкка өндәп иҗат ителгәннәр. Язучы беренче хикәяләрендә үк үзен оста психолог итеп таныта.

Чынбарлык һәм идеаль тормышны капма-каршы кую Ф. Әмирханның сатирик әсәрләренең үзәгендә тора. «Фәтхулла хәзрәт» (1909) повестенда мавыктыргыч тасвирланган 20 шәр катлы йортлар, зур мәчете, китапханә-музейлары булган Казан шәһәре, сөйләшүче кешене бөтен гәүдәсе белән күрсәтә торган көзгеле телефоннар, югарыга менгезә торган машиналар, үлгән кешене терелтү баскычына аяк баскан фән дөньясы, ягъни, әдипнең алдан күрә белү осталыгы, бүгенге укучыны да сокландыра.

«Хәят» (1911) повесте Ф. Әмирхан прозасында гына түгел, гомумән татар әдәбиятында мөһим урын тоткан әсәр. Ике бүлектән торганлыгы билгеле булган әлеге повестьның моңа кадәрге басмалардан беренче бүлеге белән генә танышырга мөмкин иде. Әлеге томга беренче мәртәбә әсәрнең югалган дип исәпләнелгән икенче бүлеге дә (тәмамланмаган рәвештә булса да) кертелгән. Повестьның ике бүлеге бергә тәкъдим ителү томның яңалыгы булудан бигрәк, Хәят образының бөтен тулылыгында ачылуына ярдәм итә.

Ф. Әмирхан эшчәнлегендә тәрҗемәчелек аерым бер юнәлеш тәшкил итә. Әдәбият-мәдәният әһелләренең белемен арттыру, фикерен киңәйтү максатыннан, 1908 елда ул «Әлислах» каршында хәтта тәрҗемәчеләр түгәрәге дә оештыра. Аның «Мәхәббәтсез үрдәк баласы» (1907), «Гөл бакчасы һәм әкәм-төкәм» (1907), «Асылган җиде кешеләр хикәясе» (1909) исемле тәрҗемә әсәрләре томда аерым бүлек

буларак урын алганнар. Ф. Әмирхан иҗатына зур тәэсир ясаган рус язучысы Леонид Андреевның (1871–1919) тирән психологизм белән сугарылган «Рассказ о семи повешенных» әсәренең тәрҗемәсе томлыкларга беренче мәртәбә кертелгән.

Томга хронологик тәртиптә урнаштырылган хикәя-повестьлар әдипнең фикер үсешен, язучы буларак формалашуын эзлекле рәвештә күзалларга ярдәм итә. Ф. Әмирханның замандашлары тарафыннан язылган рецензия-бәяләмәләрнең шушы ук томда урын алуы әлеге әсәрләрнең кыйммәтен, һәм, гомумән, әдипнең шул чор әдәбиятында тоткан урынын билгеләүдә мөһим роль уйныйлар. XX йөз башы вакытлы матбугатында дөнья күргән әлеге бәяләмәләр укучылар игътибарына кириллицада беренче тапкыр тәкъдим ителәләр. Алар томның әһәмиятен һәм фәнни дәрәҗәсен тагын да арттыралар.

Томны төзүче текстолог-галимнәр Э.М. Галимҗанова һәм Ф.Г. Фәйзуллинаның хезмәте югары бәяләнүгә лаек. Томга текстларның язучы үзе исән вакытта дөнья күргән соңгы басмаларыннан һәм кулъязма хәлендә сакланып калган нөсхәләреннән алып урнаштырылулары текстолог-галимнәрнең үз эшләренә җитди караулары турында сөйли.

Томда текст белән эшләүгә караганда да күп вакыт, көч һәм белем таләп итә торган фәнни аппарат булдырылган. Бит астында текстларда очраган киң катлау укучы өчен аңлашылмаган гарәп-фарсы, төрек яки башка телләрдән кергән сүзләргә сүзлекчәләр бирелгән, «Искәрмә һәм аңлатмалар» бүлегендә әсәрләрнең язылу тарихлары ачыкланган, төрле басмалары хакында мәгълүмат тупланган. Укучыга текстларны үзләштерүне җиңеләйтү өчен, әсәрдә очраган реаль шәхесләргә, вакыйгаларга, тарихи урыннарга, төрле гыйбарәләргә һ. б. аңлатмалар язылган.

Фатих Әмирханның әлеге алты томлы академик басмасы аша әдипнең гүзәл иҗаты, бай мирасы укучыга тулысынча җиткерелер. 140 ел тулган көненә әлеге басма әдип иҗатына рухи һәйкәл булыр дип ышанасы килә.

***Галиева Ләйсән Шәүкәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Галиева Лейсан Шаукатовна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела литературоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*nisanbedri@mail.ru*

**2024 елның 18 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Фәнни Татарстан» журналына 10 ел тулуга багышланган «Россия халыклары телләрендә фәнни журналлар: проблемалар һәм перспективалар» дигән темага түгәрәк өстәл оештырылды. Түгәрәк өстәл эшендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты Айнур Тимерханов, Татарстан Республикасы Рәисенең эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы Данил Мостафин, галимнәр, фәнни учреждениеләр, нәшрият һәм фәнни журналлар редакцияләре хезмәткәрләре катнашты. Журналның баш мөхәррире, филология фәннәре докторы Ким Миңнуллин «Фәнни Татарстан»ның 10 еллык эшчәнлеге белән таныштырды. Россия халыклары телләрендә чыга торган төбәк фәнни журналлары вәкилләре филология фәннәре докторы, Чуваш дәүләт гуманитар фәннәр институты директоры, «Развитие образования» журналының редакция коллегиясе әгъзасы Юрий Исаев, тарих фәннәре кандидаты, «Финно-угроведение» журналының баш редакторы Марина Ипакова, филология фәннәре кандидаты, «Новые исследования Тувы» журналының баш редакторы Чимиза Ламажаа, филология фәннәре кандидаты, Хакас тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты директоры, «Научное обозрение Саяно-Алтая» журналын оештыручы Нина Майнагашева, филология фәннәре кандидаты, Мордовия Республикасы Хөкүмәте каршындагы Гуманитар фәннәр фәнни-тикшеренү институтының фән эшләре буенча директор урынбасары Алексей Чернов тулысынча татар телендә чыгып килә торган фәнни журналны алга таба да саклап калу зарурлыгын ассызыкладылар. Чарада түбәндәге сораулар буенча фикер алыштылар: Россиянең фәнни киңлегендә милли телләрдәге фәнни журналлар, фәнни дискурсны үстерүдә милли телләрдәге журналларның роле, РФ халыклары телләрендәге фәнни журналлар һәм милли телләрдә белем бирү мәсьәләләре, «Фәнни Татарстан» журналы: модернизация юллары, милли телләрдәге фәнни журналларны үстерүдә фәнни-тикшеренү учреждениеләренең роле, милли телләрне фән теле буларак саклауда журналларның роле.

**2024 елның 24 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә күренекле татар язучысы, шагыйрь, драматург, галим-филолог һәм фольклорчы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты һәм Татарстанның Халык язучысы Нәкый Исәнбәтнең (1899–1992) тууына 125 ел тулуга багышланган «Гуманитар фәннәр контекстында Нәкый Исәнбәт мирасы» темасына түгәрәк өстәл уздырылды. Чыгышларда XX гасырның беренче яртысында иҗтимагый-тарихи, мәдәни мохит һәм Нәкый Исәнбәт шәхесе, Н. Исәнбәт иҗаты һәм традицияләре, Н. Исәнбәт – фольклорчы галим, Н. Исәнбәт һәм татар театры, Татарстан сәнгатен үстерүдә Исәнбәт династиясенең роле, Н. Исәнбәт тормышын һәм эшчәнлеген өйрәнүнең бүгенге торышы һәм бурычлар кебек сораулар күтәрелде. Чарада Нәкый Исәнбәтнең татар әдәбияты, мәдәнияте һәм фәне үсешенә керткән зур өлеше билгеләнде.

**2025 елның гыйнварында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы, Мәдәният, Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык, Урман хуҗалыгы министрлыклары, Туристлык буенча дәүләт комитеты, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының коллегия утырышларында катнашты. Үз чыгышларында Рифкать Миңнеханов һәр тармакка кагылышлы фәнни проектлар белән таныштырды, проблемаларны хәл итү юллары һәм үсеш перспективалары хакында сөйләде.

**2025 елның 16 гыйнварында** Казан федераль университеты каршындагы 2 нче номерлы татар гимназиясендә Шиһабетдин Мәрҗани музее ачылды. Чара Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында уздырылды. Музейның фәнни концепциясе Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре Бәхтияр Измайлов тарафыннан эшләнде.

**2025 елның 20 гыйнварында** Алабуга дәүләт музей-тыюлыгының Хәзерге заман этносәнгате музеенда Татарстан Республикасының халык рәссамы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Михаил Кузнецов иҗатын яктырткан «Михаил Кузнецов. Дорога домой» альбомы (Казан: Заман, 2024) презентацияләнде. Альбом белән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Сәнгать белеме үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Ольга Улемнова һәм «Заман» нәшрияты җитәкчесе Марат Гарифҗанов таныштырды.

**2025 елның 24 гыйнварында** узган Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының йомгаклау коллегиясендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты хезмәткәрләре тарафыннан күргәзмә тәкъдим ителде. Күрәзмәдә иске Казан – Тукай, Мөштәри һәм Островский урамнарындагы казу эшләре вакытында табылган ядкәрләр, Болгар һәм Биләр шәһәрлекләреннән уникаль табылдыклар урын алды, шулай ук Татарстан Республикасы һәм аннан читтә археологик истәлекләрне казу һәм өйрәнү нәтиҗәләре, планлаштырылган тикшеренүләр белән таныштырылды.

**2025 елның 31 гыйнварында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә узган елның көзендә булып үткән беренче Республика лаборатория мөдирләре мәктәбе эшенә нәтиҗәләр ясалды. Чарада Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, министрлык, төрле ведомство һәм оешма җитәкчеләре катнашты. Лаборатория мөдирләре мәктәбендә университет һәм тикшеренү институтларының табигый фәннәр һәм инженерия-техник юнәлеше буенча урта звено җитәкчеләре белем алды, уку процессы проектлар яклау белән тәмамланды. Республика Рәисе ярдәмчесе Альберт Гыйльметдинов киләсе мәктәпне социаль-гуманитар һәм иҗтимагый фәннәргә багышлау планлашырылганын искәртте.

**2025 елның 5 февралендә** Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетында Татарстанның фәнни-технологик үсеш нәтиҗәләре һәм перспективаларына багышланган брифинг үткәрелде. Үзенең докладында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов академиядә иҗтимагый-гуманитар фәннәргә караган фундаменталь һәм гамәли эзләнүләргә өстенлекле роль бирелүен әйтте, «Татарлар Ватанга хезмәттә» дип исемләнгән фәнни проект эшчәнлеге, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе каршында оештырылган Халыкара Евразия далалары халкы тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге турында, шулай ук Россия, Кыргызстан, Монголия һәм Үзбәкстандагы археологик тикшеренүләр хакында сөйләде, Татарстан районнары энциклопедияләрен нәшер итү, татар телен саклауда мәгълүмати технологияләрне куллану, дөнья югарылыгындагы Фән-мәгариф үзәге төзү буенча планнар белән уртаклашты.

**2025 елның 7 февралендә** Казан Кремлендә фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премияләрен тапшыру тантанасы узды. Бүләкләрне Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов тапшырды. Премиягә «Төрки-татар дөньясының этногенезын һәм этномәдәни мирасын комплекслы тикшерү тәҗрибәсе» циклы хезмәтләре авторы – филология фәннәре докторы, профессор, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Лев Толстой мирасын өйрәнү фәнни-мәгариф үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре М.Х. Бакиров, «Вируслы авыруларны дәвалауның патогенетик юнәлешен булдыру һәм мондый авырулардан соң өзлегүләрне профилактикалау» проекты авторлары – Кулланучы хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек Федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе җитәкчесе, медицина фәннәре докторы М.А. Патяшина, медицина фәннәре докторы, КФУның балалар инфекцияләре кафедрасы мөдире В.А. Анохин, химия фәннәре докторы, КДМУның Үзәк фәнни-тикшеренү лабораториясе баш фәнни хезмәткәре Р.И. Жданов, медицина фәннәре докторы, ТР Фәннәр академиясенең гамәлдәге әгъзасы, КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры А.П. Киясов, медицина фәннәре докторы, КДМУның эпидемиология һәм дәлилле медицина кафедрасы мөдире Г.Р. Хәсәнова, медицина фәннәре докторы, Гомуми патология һәм патофизиология фәнни-тикшеренү институтының (Мәскәү) системалы эндотоксинемия һәм шок лабораториясе мөдире М.Ю. Яковлев һәм «Россия Федерациясенең медицина, биологик һәм дарулар куркынычсызлыгын тәэмин итү максатында комплекслы фәнни-техник карарлар эшләү һәм массакүләм җитештерүгә махсус медицина җиһазларын кертү» эше буенча проектны тормышка ашыручылар – Серго исемендәге заводның җитештерү берләшмәсе баш инженеры, техник үсеш буенча генераль директор урынбасары И.В. Драгунских, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы Республика кан үзәге баш табибы Р.Г. Тураев, Серго исемендәге заводның стратегик маркетинг буенча генераль директоры урынбасары Б.Р. Хәсәнов, Серго исемендәге заводның медицина техникасын маркетинглау һәм сату департаменты башлыгы Т.И. Фәхретдинов, Серго исемендәге заводның инновацион-техник

үзәге башлыгы, баш конструктор И.Ш. Мифтахов лаек булды.

«Безгә бергәләп Россиянең фәнни-технологик үсешенең яңартылган стратегиясен үтәүне, фәнни-техник өлкәдә илнең амбициоз илкүләм максатларына ирешүне, шулай ук күптән түгел кабул ителгән технологик лидерлык проектларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә кирәк. Ышанам ки, Дәүләт премиясе лауреатлары һәм аларның хезмәттәшләре безнең алда торган бурычларны хәл итүдә алда барырлар һәм республиканың фәнни даирәләре өчен үрнәк булырлар», – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов.

**2025 елның 3–8 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире Ләйлә Дәүләтшина һәм бүлекнең баш фәнни хезмәткәре Лилия Мөхәммәтҗанова Якутия (Саха) Республикасының Нерюнгри шәһәрендә узган «Ысыах Олонхо: эпостан – мәдәниятләр диалогына» дип аталган XV региональ фәнни-методик конференциядә катнаштылар.

Әлеге чара якут халкының 2025 елда узачак чираттагы Ысыах Олонхо милли бәйрәмен оештыру алдыннан гыйльми фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу максатыннан оештырылган иде. Галимнәр Якут (Саха) Республикасына Татарстаннан эксперт буларак чакырылдылар.

**2025 елның 8 февралендә** Казан федераль университетында күренекле татар галиме, энциклопедисты Каюм Насыйри тормышына һәм мирасына багышланган «Соединяющий миры» документаль фильмының ябык күрсәтүе оештырылды. Чара университетның император залында узды һәм галимнәрне, студентларны һәм мәгърифәтче иҗатын хөрмәт итүчеләрне җыйды.

«Россия Культура» телеканалы заказы буенча режиссер Андрей Лысяков төшергән фильм К. Насыйри шәхесенең күпкырлылыгын, аның фәнгә, мәдәнияткә һәм мәгърифәткә керткән өлешен ача. Аның бер өлеше КФУның Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә төшерелгән. Китапханәдә галимнең кульязмаларының уникаль коллекциясе: дини хезмәтләре, географик тикшеренүләре һәм фольклор язмалары саклана.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Исламны өйрәнү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Илдус Заһидуллин, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре филология фәннәре кандидаты Азат Ахунов фильмның фәнни консультантлары буларак катнашты.

«Россия-Мәдәният» телеканалында «Соединяющий миры» фильмының премьерасы 14 февральдә булды.

Элегрәк шулай ук Рөстәм Миңнеханов инициативасы белән Россия Банкы 2025 елның 15 гыйнварында әйләнешкә «Россиянең күренекле шәхесләре» сериясеннән «Галим-мәгърифәтче Каюм Насыйри тууга 200 ел тулу уңаеннан» 2 сум номиналлы истәлекле көмеш тәңкә чыгарды.

**2025 елның 10 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты Айнур Тимерханов, Иранның Казандагы консулы Давуд Мирзахани чакыруы буенча, Иранда Милләт көне һәм Ислам революциясе җиңүен

бәйрәм итүгә багышланган тантаналы чарада катнашты.

**2025 елның 11 февралендә** Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов Россия фәне көненә багышланган чараларның спикерлары белән очрашты. Очрашу Бәшир Рәмиев исемендәге IT-паркта узды. Очрашуда катнашучылар математика һәм химияне популярлаштыру, Татарстан Республикасында «Физик-математик алгарыш» («ФизМат прорыв») проектын гамәлгә ашыруның арадаш нәтиҗәләре һәм башкалар турында фикер алыштылар. Рөстәм Миңнеханов фән әһелләрен һөнәри бәйрәмнәре – Россия фәне көне белән котлады. Татарстан Рәисе шулай ук төбәктә тәмамланган фәнни-технологик үсеш елына йомгак ясалуын искәртте һәм фән-мәгариф өлкәсендә кадрлар мәсьәләсе аеруча мөһим булуын белдерде, Татарстанда талантлы яшьләрне тикшеренүләр һәм эшләнмәләр секторына җәлеп итүгә һәрвакыт аерым игътибар бирелүен әйтте.

Шушы ук көнне IT-паркның конференцияләр залында Россия фәне көненә багышланган тантаналы чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан игълан ителгән «Научный прорыв. Фәнни алга китеш» премиясе тапшырылды. Премия 11 номинация буенча бирелде.

**2025 елның 11–13 февралендә** В.И. Качалов исемендәге Казан дәүләт академия рус Зур драма театрында халык артисты Василий Качаловның 150 еллыгына багышланган «Рус психологик театры: традицияләр һәм хәзерге заман» исемле Качалов укулары узды. Чараны В.И. Качалов исемендәге Казан дәүләт академия рус Зур драма театры, А.А. Бахрушин исемендәге Дәүләт үзәк театр музее һәм Мәскәү академия сәнгать театры музее оештырды.

Качалов укулары кысасында М.С. Щепкин исемендәге Югары театр училищесы ректоры Борис Любимов, сәнгать белеме докторы, МХАТ мәктәп-студиясенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Ольга Егошина белән иҗади очрашулар, Россиянең атказанган артисты Павел Ващилинның мастер-классы оештырылды.

**2025 елның 13 февралендә** «Татар-информ»да Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Миллиард.татар» басмасы белән берлектә Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышлап оештырган фотоконкурс темасына пресс-конференция булды. Чарада Институт директоры Илгиз Халиков һәм М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, тарихчы Искәндәр Гыйләҗев катнашты.

«День Победы – страницы памяти / Хәтер битләрендә Җиңү көне» фотоконкурсы Ватанны саклаучылар истәлегенә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү, гражданнарның ил, шәһәр, район, авыл тарихы белән кызыксынуын көчәйтү, патриотизм хисе формалаштыру һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең ролен өйрәнү максатыннан оештырылды.

**2025 елның 18 февралендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының утырышлар залында татар һәм башкорт шигърияте классигы Шәехзадә Мөхәммәтзакир улы Бабичның (1895–1919) тууына 130 ел тулуга багышланган түгәрәк өстәл узды.

Фикер алышуда иҗат һәм фән әһелләре катнашты.

Түгәрәк өстәл Шәехзадә Бабич истәлегенә һәм мирасына багышланган мөһим вакыйгага әверелде, аның татар һәм башкорт әдәбияты һәм мәдәнияте үсешенә керткән өлешен ассызыклады.

**2025 елның 25 февральдә** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре кандидаты Илгиз Халиков Мәскәүдә Россия халыклар дуслыгы университетының Рус теле институты оештырган «Телләргә өйрәтүнең этнопедагогик контекстлары: Россия һәм чит ил тәҗрибәсе» утырышында катнашты. Әлеге чара «Социомәдәни адаптация һәм мәдәниятара багланышлар: фәнни тикшеренүләрнең дисциплинарара яссылыгында рус теле» дигән темага даими эшләп килә торган фәнни семинар кысаларында оештырылды.

Утырышта телләрне этноориентлаштырып өйрәтүнең актуаль мәсьәләләре, шул исәптән әлеге өлкәнең проблемалары, заманча методлары һәм үсеш перспективалары турында фикер алыштылар. Катнашучылар белем бирү процессына инновацион методикалар һәм технологияләр кертү тәҗрибәсе белән уртаклаштылар. Семинар этник белем бирү өлкәсендә яңа алымнар эзләү мәйданчыгына әверелде.

**2025 елның 3–5 мартында Татарстан** Республикасы Фәннәр академиясендә «Дала Евразиясенең урта гасыр шәһәрләре археологиясе» дигән фәнни конференция үтте.

Чарада Россия, Казакъстан, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Үзбәкстан һәм Монголия экспертлары катнашты. Галимнәр шәһәрләрне һәм җирлекләрне өйрәнү, комплекслы дисциплинаара тикшеренүләр һәм фәнни экспедицияләр үткәрү, археологик коллекцияләрне кабул итү һәм исәпкә алу, реставрацияләү мәсьәләләре турында фикер алыштылар. Конференция ачылышында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» дәүләт программасы кысаларында төрки-татар шәһәрләре планлы рәвештә өйрәнелүен сөйләде, соңгы елларда Монголия, Кыргызстан, Үзбәкстан территорияләрендәге урта гасыр калалары тикшерелүен әйтте. «Әлеге тикшеренүләр безгә Евразиянең мәдәни һәм сәяси ландшафтын формалаштыруда төрки-татар халкының ролен аңларга ярдәм итә», – дип ассызыклады Рифкать Миңнеханов.

**2025 елның 11 мартында** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының йомгаклау конференциясе уздырылды. Чараны Институт директоры, филология фәннәре кандидаты Илгиз Халиков ачты. Ул Институтның 2024 ел йомгаклары һәм алдагы елга перспектив планы белән таныштырды.

Институтның фәнни бүлекләре хезмәткәрләре Институтта алып барыла торган төп фәнни юнәлешләр һәм перспективалар, гамәлгә ашырыла торган проектлар белән таныштырдылар.

Чыгышлардан соң катнашучылар бүлекләрнең планнары һәм эш нәтиҗәләре турында фикер алышты.

**2025 елның 13 мартында** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Татар

әдәбияты: бүгенгесе һәм киләчәге» дип аталган темага түгәрәк өстәл утырышы үткәрелде. Чарада Институт директоры Рәдиф Җамалетдинов җитәкчелегендә татар әдәбияты кафедрасы укытучыгалимнәре һәм Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Илгиз Халиков һәм институтның әдәбият белеме мәсьәләләрен өйрәнү юнәлешендә эшләүче галимнәр катнашты. Утырышта вуз һәм фәнни оешманың әдәбият гыйльмиятен үстерү юнәлешендәге перспектив юнәлешләр, бәйләнешләр, уртак проектлар булдыру хакында сөйләшү алып барылды.

**2025 елның 13–14 мартында Казанда** «Дөньяда кар барсын өйрәнү һәм саклау. Көчләрне берләштерү» дип аталган фәнни конференция узды. Конференциянең идея авторы – Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов. Ул сирәк очрый торган хайваннарны саклау мәсьәләләре белән шәхсән үзе шөгыльләнә. Конференцияне Татарстан Республикасы Хөкүмәте, «Ирбис «кар барсын өйрәнү һәм саклау үзәге» төбәкара ассоциациясе һәм Россия Табигать министрлыгы оештырды.

Территорияләрендә кар барсы (ирбис) яши торган 12 (Әфганстан, Бутан, Кытай, Һиндстан, Казахстан, Кыргызстан, Монголия, Непал, Пакистан, Россия, Таҗикстан һәм Үзбәкстаннан) илнең вәкилләре беренче мәртәбә Татарстан башкаласына җыелды. Татарстан өчен кар барсы – республика символларыннан берсе. «Кар барсы безнең территориядә элек-электән яшәмәсә дә, без атрибутларыбызны саклап калу һәм хайваннарның сирәк төрләрен саклау юнәлешендәге эшне зур мәртәбә дип саныйбыз», – диде ТР экология һәм табигый ресурслар министры Александр Шадриков.

**2025 елның 18 мартында** ТР Фәннәр академиясендә ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышы узды. Төп доклад белән ТР Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов чыгыш ясады. Ул Татарстан Республикасында фәнни-технологик үсеш елы нәтиҗәләре һәм якын киләчәккә планнар турында сөйләде. Утырышта шулай ук ТР Мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Андрей Поминов һәм ТР Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Гущин чыгыш ясады.

**2025 елның 19 мартында** Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре белән эшлекле очрашу булды. «Татар теле белеменең хәзерге торышы һәм уртак эшчәнлек мөмкинлекләре» дигән темага багышланган түгәрәк өстәл форматында үткән очрашуда телче галимнәр үзләренең эш тәҗрибәләре, фәннисметодик тикшеренү юнәлешләре турында фикер алыштылар.

## Авторлар өчен мәгълүмат

Журналда татар фәненең төрле өлкәләренә караган яңа эзләнүләрне чагылдырган татарча оригиналь мәкаләләр басыла. Аерым очракларда тюркология, Казан һәм татар халкы тупланып яшәгән башка төбәкләрнең тарихы, мәдәниятенә кагылышлы мәсьәләләргә караган мәгълүматны үз эченә алган мәкаләләр рус телендә дә кабул ителә.

Журналда мәкаләләр түләүсез бастырыла.

Елына журналның 4 саны чыга. Күләме – 180 бит. Иллюстратив материалны урнаштыру өчен төсле кушымта каралган.

Журналда мәкалә бастыру өчен f_tatarstan@mail.ru электрон адресына автор үзе турында белешмә (татар, рус һәм инглиз телләрендә авторның тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, эш урыны, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме, вазифасы; шулай ук телефон номеры һәм электрон почта адресы), журнал таләпләре нигезендә әзерләнгән мәкаләнең кульязмасын, әлеге өлкәдәге белгечнең (фәннәр кандидаты яки докторы) рецензиясен (Microsoft Wordта җыелган) һәм рецензиянең имза һәм мөһер сугылган вариантының скан-копиясен җибәрү сорала. Мәкаләнең күләме 10–15 бит. Мәкаләне басмага биргәндә, авторлар түбәндәгеләр белән килешүләрен белдерәләр:

1) тәкъдим ителгән материал элек беркайда да басылып чыкмаган һәм башка басмаларга бастырырга тәкъдим ителмәгән;

2) авторлар өчен кагыйдәләр белән таныш;

3) авторларның бу басма белән бәйле мәнфәгатьләр конфликты юк (әгәр авторлар ике һәм аннан күбрәк булса);

4) авторлар бастырылган мәкаләне тулы текстлы мәгълүматлар базаларында урнаштыруга ризалык бирәләр;

Түбәндәге мәкаләләр журналга кабул ителми:

1) мәкалә техник яктан куелган таләпләргә җавап бирми;

2) фәнни стильдә язылмаган;

3) плагиат һәм үзплагиат элементлары, тупас грамматик хаталар табылган, шулай ук файдаланылган әдәбият исемлеге һәм текст эчендә аларга сылтамалар дөрес формалаштырылмаган.

Мәкаләләрнең кульязмалары рецензияләнә. Мәкаләне бастырып чыгару турындагы карар редколлегия тарафыннан рецензент бәяләмәсе нигезендә кабул ителә. Редакция мәкаләләрне редакцияләргә, экспертлар тискәре бәя биргән очракта бастыруга кабул итмәскә хокуклы. Мәкаләнең кульязмасы рецензияләү этабында да, редакцияләү этабында да кире кагылырга мөмкин.

Элемтә өчен мәгълүмат:

420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһ., К. Маркс ур, 12.
ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Тел.: (843) 590-61-11
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Тулы мәгълүмат белән журнал сайтында таныша аласыз:

https://ft.antat.ru/

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2025. № 1

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 26.03.2025. Басылды: 09.04.2025.
Офсет кәгазе. Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Гарнитура «Times».
Басма табак 12. Тираж 100 данә. Заказ

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-61-11
E-mail: f_tatarstan@mail.ru
Сайт: https://ft.antat.ru/

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
нәшриятында басылды
(нәшрият һәм типография адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал Татарстан, Башкортстан Республикаларында, Самара, Ульяновск,
Оренбург, Әстерхан, Төмән өлкәләрендә бушлай таратыла

## Б.Л. Хәмидуллинның «Казан ханлыгы халыклары – Александр Гваньининың (1534/1538–1614) “Европа Сарматиясе хроникасы”нда» мәкаләсенә




«Европа Сарматиясе хроникасы»ның тышлыгы




Энтони Дженкинсон картасы. 1562

## «Каюм Насыйриның тууына 200 ел» рубрикасына



Альменов Б.М. Каюм Насыйри. 1952. Кәгазь, тушь, кисть, ак буяу. 19,7×14,3.
*Рәссамның гаиләсе тупламасыннан*

## Д.Ф. Заһидуллинаның «Фатих Әмирхан: татар халкы өчен янып яшәү» мәкаләсенә



Фатих Әмирхан.
Черек күл бакчасында.
1915 ел

## Э.Х. Кадированың «Диалектолог галимә (Зидә Садыйковның тууына 90 ел булу уңаеннан)» мәкаләсенә



Зидә Садыкова



ТӘһСИнең тел белеме бүлеге хезмәткәрләре. Зидә Садыкова – беренче рәттә уңнан беренче. 1987 ел

## А.К. Җәләлиеваның «Татарстанда нәфис керамика сәнгате үсешенең төп тенденцияләре» мәкаләсенә



Питрәч керамикасы.
Сөт чүлмәге. 1910–1920.
*ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее. № 8890031*



Борис Шубин. Пәрәмәч салу өчен савыт. 1960–1970. *Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәби музей-тыюлыгы. № 23453023*



Нина Кузьминых. «Балачак», «Карт кыз» скульптуралары. 2007–2008



Лилия Григорьева.
Су чүлмәге. 2019



Гүзәл Шакирова.
«Зөбәрҗәттәй яфраклар» керамик тәлинкәсе. 2022



Юлия Айтуганова.
«Диңгез» вазасы. 2020

## А.Ю. Алекберованың «Азәрбайҗанда мәдәни туризмны үстерүдә ачык һавадагы музейларның роле» мәкаләсенә



«Ичери шехер» дәүләт тарихи-архитектура тыюлыгы

## Г.Р. Әюпованың «Совет иленнән килгән илче» мәкаләсенә





«Кызыл паша» спектакленнән күренешләр

## М.Р. Булатованың «Татар теленең хвалын, карсун, мәләкәс сөйләшләренең үзенчәлекләре (йола фольклоры текстлары мисалында)» мәкаләсенә




Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Ульяновск өлкәсендә комплекслы экспедициядә. 2017 ел

## Яңа китап



## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗГА ФОТОКҮЗӘТҮ




«Гуманитар фәннәр контекстында Нәкый Исәнбәт мирасы» темасына түгәрәк өстәл.
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе. 2024 ел, 24 декабрь



«Исыах Олонхо: эпостан – мәдәниятләр диалогына» XV регионара фәнни-методик конференция. Якутия (Саха) Республикасы, Нерюнгри шәһәре. 2025 ел, 3–8 февраль




«Рус психологик театры: традицияләр һәм хәзерге заман» темасына Качалов укулары. 2025 ел, 11 февраль



Татар һәм башкорт шигърияте классигы Шәехзадә Мөхәммәтзакир улы Бабичның тууына 130 ел тулуга багышланган түгәрәк өстәлдә катнашучылар.
ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. 2025 ел, 18 февраль





Казанның Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче гимназиясендә Шиһабетдин Мәрҗани музеен ачу. 2025 ел, 26 гыйнвар

ТР Рәисе Р.Н. Миңнехановның «Научный прорыв. Фәнни алга китеш» премиясен тапшыруы. 2025 ел, 11 февраль



Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитетының ТР Фәннәр академиясендә уздырылган күчмә утырышы. 2025 ел, 18 март



КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Татар әдәбияты: бүгенгесе һәм киләчәге» темасына түгәрәк өстәл утырышы. 2025 ел, 13 март